Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

3

март 2021

ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

Кемнәр алар типтәрләр?
22 бит

Минзәлә сөйләше
64 бит

ҺАДИ ТАКТАШ
ҺӘМ МИРХӘЙДӘР ФӘЙЗИ

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС

12 +

3
(327)
март 2021

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рүзәл Мөхәммәтшин
Григорий Родионов (Гәрәй Рәхим)
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Ирек Шәрипов
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Алмаз Фәйзуллин
(843) 222-09-83 (17-92)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал
(на татарском и русском языках)

Эчтәлек

БЕЗ – ТАТАРЛАР!

2 Г.Тукай, Р.Фәхреддин, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Дәрдемәнд, Н.Фәттах

2021 ЕЛ – ТУГАН ТЕЛЛӘР һӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

4 Минтимер Шәймиев: «Телне саклап калуга һәркайсыбыз тиңсез өлешен кертә ала»

10 Мин – татар!

ТАРИХИ МИРАС

12 Тимербәкнең ил-йортына сәяхәт (1404-1406) көндәлеге. *Руи Гонсалес де Клавихо*

20 Кыпчаклар ничек сугышкан? *Л.Гобәйдуллин*

22 Кемнәр алар типтәрләр? *А.Чанышев*

28 Башкорт-мещеряк гаскәрендә татарлар. *Р.Әминев*

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

32 Кама аръягы төбәге татарлары тарихыннан. *Н.Гафиятов*
38 Актанышта Беренче бөтендөнья сугышы сәхифәләре. *Л.Габдрафикова*
44 «Жырлаулары белән сихерләндем». *М.Фәйзи*
50 Коточкыч ачлык. *Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин*
55 Ибраһим Хәлфиннең Казан тарихына багышланган хезмәте. *Р. Мәрданов*
58 Метрика язмаларында Актаныш төбәге. *Э.Сәлахова*

ТАТАР ГАМЕ

62 Туган тел – изге тел
64 Минзәлә сөйләше. *О.Хисамов*
69 И.Һадиуллин: «Татар кешесе үзенең кыйбласын сакларга тиеш»
70 Җәүһәр иясе Җәүһәриягә. *Ә.Зарипов*
76 Хаҗи Абдулла Дубин

ДИНИ МИРАС

78 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

84 «Тарихын белгән халык – теп-тере бер милләттер». *Х.Миңнегулов*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

88 Кара тәкъдир. *Р.Батулла*
90 Истә, һаман да истә!

СӘНГАТИ МИРАС

92 Затлы дәвам фестивале. *Г.Сафиуллина*
100 Чал тарихка бер караш. *М.Хәбибуллин*
110 Татар җырчылары. Кадерле мизгелләр. *З.Гыйльметдинова*
112 «Галиябану» җыры

ШАЯН МИРАС

114 Көлке куа килә...

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Март*

Заказ №Е-641. Тираж – 2550 данә. Формат 70x100 1/16
Басарга кул куелды: 01.03.2021. Чыгу көне: 05.03.2021.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән әзерләнде.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә: Һади Такташ (сулда) һәм Мирхәйдәр Фәйзи. Фото Диләрә Мөхәммәдьярова архивыннан алынды.

Габдулла Тукай,
бөек татар шагыйре:

Татарларның бөеклеге, даны сигез кат күкләргә китсен, мәңге, һәрвакыт бу милләтне Ходаем бәхетле итсен!

Ризаэддин Фәхреддин,
дин әһеле, тарихчы, мәгърифәтче:

Ата-анагызны, якын кардәшегезне ничек сөйсәгез, милләтегезне дә шулай сөегез, милләтегез өчен хезмәт итүне җаныгызга зур табыш дип санагыз. Халыкка хезмәт итү дәүләткә дә хезмәт итү булыр.

Гаяз Исхакый,
мәшһүр татар язучысы:

Безнең шактый кешеләр төрек булып китте, хәзер әйбәт торалар. Хәтта үз кызым да инде мине: «Ни дип татарга шулкадәр ябышып ятасың», – дип шелтәли. Татар булуы авыр. Әмма мин татар булдым һәм теләсә нинди шартларда да татар булып калырмын.

Фатих Әмирхан,

мәшһүр татар әдибе:

Меңьеллык тарихы булган, башкаларныкыннан бер дә калышмаслык кабилияте булган, тырышып, сакланып килгән дине, гадәтләре булган, үзенең язуы, әдәбияты, җыры, көе булган, гасырлар буенча мәктәп һәм мәдрәсәләре булган бер милләтнең бер нәрсәсе дә бервакытта чүпкә чыкмый, чыга алмый.

Дәрдемәнд,

күренекле татар шагыйре:

Татарлыктан татар һич гарь итәрме,
Кеше исемене инкяр итәрме?!
Татарлыкта татар углы татармын,
Татар түгел, димә – башың ватармын!

Нурихан Фәттах,

Татарстанның халык язучысы:

Безнең үз җиребез, үз йортыбыз – Татарстаныбыз бар. Идел-Урал төбәгендә генә дә без инде ике мең ел чамасы яшәп ятабыз. Безгә менә шушы йортны торгызырга, шушы җирне бизәргә һәм, бер адым чигенмичә, бер адым тайпылмыйча, үз татарыбызны, үз халкыбызны саклап калырга, үстерергә, көчәйтергә кирәк. ■

Минтимер Шәймиев: «Телне саклап калуга һәркайсыбыз тиңсез өлешен кертә ала»

(ТРның Дәүләт Киңәшчесе, «Яңарыш» Республика фондының Попечительләр Советы Рәисе, ЮНЕСКОның мәдәниятара диалог буенча Махсус илчесе Минтимер Шәрип улы Шәймиев белән «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон әңгәмәсе)

– Хөрмәтле Минтимер Шәрипович, мәгълүм булганча, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов 2021 елны Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан итте. Әйтегез әле, Сезнең өчен туган тел ата-бабалардан калган әманәтме, әллә тагын да киңрәк төшенчәме?

– Туган тел – ана теле, чөнки ул һәркемгә тумыштан бирелә. «Тел – ананың теләге, тел – ананың баласына иң кадерле бүләге», – ди татар халык мәкале. Аны ата-бабаларыбызның васыяте дип тә, әманәте дип тә әйтеп була. Ана телен саклау, аны буыннан-буынга җиткерү – әниләребезне ярату, ата-бабаларыбызны ихтирам итү билгесе. Шуңа күрә кешене үз теленнән, милләтеннән, диненнән мәхрүм итәргә беркемнең дә хакы юк.

– Сез ничек уйлыйсыз, ана телебезне саклап калу өчен безгә, беренче нәүбәттә, нәрсәләр эшләргә кирәк?

– Туган телебез язмышы иң элек һәрберебезнең аны саклап калу өчен ни дәрәҗәдә тырышуыннан тора. Бу турыда республикабыз Президенты Рөстәм Нургали улы

Миңнеханов һәрвакыт искәртеп килә. Телне саклап калуга безнең һәркайсыбыз үзенең тиңсез өлешен кертә ала, чөнки, әйтик, гаиләдә үзара татарча сөйләшергә, балаларыбызга туган телне ана сөте белән сеңдерергә һичнәрсә һәм һичкем комачау итә алмый, моның өчен нindидер өстәмә чыгымнар яки рәсми карарлар кирәкми. Ата-аналардан башлап, балалар, яшьләр, җәмәгать эшлеклеләре, дәүләт җитәкчеләре һ.б. – һәркем үз урынында татарча мөмкин кадәр күбрәк сөйләшә, аралаша ала. Һөнәре нинди генә булмасын, һәркайсыбыз үз тормышында туган телгә кагылышлы мәнфәгатьләрне яклау мөмкинлегенә ия. Һәм бу, барыннан да бигрәк, яшь буын өчен бик үтемле үрнәк булыр иде.

Икенчедән, бүгенге көндә телебезнең сакланып калуы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституцияләрендә язылган хокукларыбызга ни дәрәҗәдә ирешә алуыбыздан тора. Мәгълүм ки, без республикада әлеге юнәлештә егерме ел диярлек Россия Конституциясе һәм Татарстан Конституциясе нигезендә эш иттек. Әмма тиешле нәтиҗәләргә ирешә алдык дип әйтеп булмый. Чөнки хәзерге вазгыять шундый: илебезнең төп законында каралса да, күпмилләтле Россиядә халыкларның туган телләрен саклау һәм үстерү сәясәте инде ике дистә ел дәвамында тиешле дәрәҗәдә тормышка ашырылмый, бу өлкәдә федераль һәм җирле идарә органнарының бердәм эшчәнлеге каралмаган. Моның белән шөгыльләнергә тиешле федераль органнар, соңгы вакытта әлеге мәсьәләгә игътибар көчәюгә карамастан, гамәли чаралар күрергә ашыкмый. Күптән түгел илебез Конституциясенә төзәтү-өстәмәләр кертү буенча тавыш бирдек, төзәтмәләр кертелгән Конституциянең һәр статьясы төгәл үтәлер дигән ышаныч нигезендә, яхшылап әзерләнеп, законлы, цивилизацияле барлык ысулларны кулланып, хәзерге заман технологияләрен эшкә җигеп, туган телгә хокукыбызны чынбарлыкка ашыруга ныклап тотынырга кирәк.

Шунысын да онытмыйк: 90 нчы елларда, бигрәк тә СССР таркалган чорда, Россия Федерациясендә икътисадны аякка бастыру иң мөһим бурычка әйләнде, чөнки, беренче чиратта, халыкны азык-төлек белән тәэмин итәргә кирәк иде. Мәгарифкә игътибар җитмәде. Федераль органнарга бу мөһим тармак күпмедер вакыт элеккечә – ничек көйләнгән, шул рәвешле барыр кебек тоелды. Шул ук вакытта милли республикалар үзләренең дәүләт суверенитеты турындагы декларация һәм карарларында әлеге мәсьәләләрне кичектермәстән хәл итү бурычын куйдылар. Татарстан Республикасының яңа Конституциясе Россиянең яңа Конституциясеннән иртәрәк кабул ителде һәм гамәлгә керде. Шушы шартларда Татарстан, милли республика буларак, ана телен, рус теле белән беррәттән, дәүләт теле статусында төп законыбыз – Конституциябездә аерым статья итеп беркетте. Әйткәнемчә, ул чорда илдә төп игътибар икътисадка юнәлтелде, чөнки көндәлек тормыш шуны таләп итә иде. Ә менә элеккеге союздаш республикаларда, СССР таркалгач, ана теле ничек бар – шул килеш дәүләт теле булып сакланып калды, чөнки алар мөстәкыйль дәүләтләргә әверелделәр.

Билгеле булганча, РСФСРда бу мәсьәләгә тиешле әһәмият бирелмәде. Һәм Татарстан үзенең Дәүләт суверенитеты турындагы декларациясе һәм яңа Конституциясе нигезендә дәүләт теле булган татар телен укытуны торгызуга керәште. Исегездәдер, үзгәртеп кору чорында безнең республикада латин алфавитына күчү таләпләре яңгырый башлагач, федераль үзәкнең ана теленә, аны укытуга карашы, нигездә, үзгәрде. Шуннан бирле милли республикаларда уку-укыту системасын үзгәртү иң катлаулы мәсьәләгә әйләнде һәм хәзергәчә катлаулы сәяси проблема булып тора.

Шуның чагылышы буларак, федераль дәүләт органнары ана телендә белем бирү барышына прокуратура аша басым ясап, федераль мәгариф органнары аркылы яңа дәүләт мәгариф стандартлары булдырып, ана телендә укытуны атнага өч сәгатькә калдырдылар. Сүз дә юк, бу хәл барыбызны да борчый. Республика матбугат чараларында

күпләр, бигрәк тә бу өлкәдә хезмәт иткән галимнәр-мөгаллимнәр еш кына әлеге хәлгә үз мөнәсәбәтләрен, үз фикерләрен белдерәләр, тәкъдимнәр кертәләр.

Шуларның берсе – Казанда Татар гуманитар университеты ачу. Мәгълүм ки, без әлеге мәсьәләне тормышка ашыруга вакытында, гаять катлаулы сөйләшүләр аша керештек. 2004-2005 нче елларда Казан үзәгендә тиз арада, Казан университетының тарихи бинасына охшатып, мәһабәт комплекс төзедек. Янында Салих Сәйдәшев һәйкәле ачтык. Ике бөек шәхес – Габдулла Тукай һәм Салих Сәйдәшев Болак елгасының ике ярын үзәк күпер аша бәйләп-бизәп торалар.

Билгеле булганча, ул елларда Россиядә алты федераль университет оештырып, аларны ил күләмендә фән һәм мәгариф белән шөгыльләнергә тиешле зур үзәкләргә әйләндерү буенча эш башланды. 200 еллык тарихы булган Казан университеты шушы алты университет сафында үзенең лаеклы урынын алып, үзенең данлы исемен саклап калды. Бу университетыбызны ныгыту һәм үстерү юлында гаять җитди адым булды, һәм ул, әйтергә кирәк, җиңел бирелмәде. Татар гуманитар университеты да аның составына керде. Хәзерге вакытта Казан федераль университеты фән-мәгариф өлкәсендә киң колачлы эшләр алып барырга сәләтле көчле, заманча үзәккә әйләнеп бара. Аның составында бүгенге көндә 15 институт, 2 югары мәктәп, 2 лицей, 1 мәктәп эшли, ике филиалы бар, яңа, алга киткән медицина тармагы барлыкка килде. Гомумән, КФУның дөньякүләм рейтингы күтәрелә бара, димәк, киләчәге дә ышанычлы. Хәзерге вакытта КФУда туган телдә уку-укыту һәм милли фәнне үстерү юнәлешендә зур эшләр башкару күздә тотыла.

Без еш кына совет чорындагы мәгариф системасын сагынып искә алабыз. Чыннан да, әлеге чорда балаларны мәктәптә укыту һәм тәрбияләү ысулларының тәэсире заман таләпләренә күбрәк туры килә иде. Күпмилләтле Россия Федерациясендә яшәүче халыкларның ихтыяҗын да яхшырак канәгатьләндерә иде ул. Соңгы елларда берьяклы тәкъдим ителгән федераль дәүләт белем бирү стандартлары (ФГОС), гомумән, илдә укыту-тәрбия системасын какшатты. Урыннарда милли ихтыяҗны исәпкә алып укыту-тәрбия алымнары, ана телендә укытучы мөгаллимнәр, дәрес саннары бихисап кыскартылды, милли мәктәпләр саны да кимеде һ.б.

Бу юнәлештә республика җитәкчелеге һәм ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан җитди эш бара, һәрхәлдә, федераль органнар белән эш итүдә хәрәкәт сизелә. Мәсәлән, «Туган (татар) тел», «Туган телдә белем бирүче оешмалар өчен туган (татар) тел», «Татар теле – Татарстан Республикасы дәүләт теле» фәннәре буенча башлангыч һәм гомуми белем бирү өчен якынча программалар эшләнеп, федераль реестрга кертелде. Тагын бер мөһим адым – 2020-2024 нче елларга татар теленә тәрҗемә ителгән уку басмаларын федераль дәреслекләр исемлегенә кертү буенча юл картасы эшләнде, аны гамәлләштерү эше башланды. Республика мәктәпләрендә татар теленә тәрҗемә ителгән 79 басма кулланыла. 2020 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан 38 уку басмасын федераль исемлеккә кертү өчен тиешле акча бирелде.

Уку-укыту мәсьәләләре берьяклы гына хәл ителә алмый. Монда югары дәрәҗәдә килешү-аңлашу бик мөһим. Инде хәрәкәт бар икән, ниндидер каршылыклар булуы да мөмкин. Бер-береңә ихтирамны югалтмыйча, милләтләрне һәм телләрне бер-беренә каршы куймыйча, кешенең эчке дөньясына кагылмыйча, үзара аңлашып эш итү зарур. Шуның бер рәвеше – Татарстан Республикасы Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе төзү. Бу комиссия инде бер елга якын эшләп килә. Аның җитәкчесе – ана телебезне камил белгән, тәҗрибәле, республикада билгеле шәхес – Марат Готыф улы Әхмәтов – ТР Дәүләт Советы Рәисенең беренче урынбасары белән без даими элемтәдә. Шунысын әйтергә кирәк, ул ышанычыбызны аклап

килә. Хәзерге вакытта комиссия эзлекле эш алып бара, Марат Әхмәтов үзе һәм комиссия әгъзалары районнар буйлап йөриләр, мәктәпләрдә татар телен укыту мәсьәләләре белән шөгыльләнәләр. Әлеге юнәлештә татар теленә игътибарны көчәйтә торган берничә кызыклы конкурс үткәрелде һ.б. Бер генә мисал китерәм: Комиссия тәкъдиме белән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы 2020 ел азагында «Татарстан Республикасы муниципаль бюджет гомуми белем бирү оешмаларында туган телләрдә (татар, чуваш, удмурт, мари, мордва) белем бирүнең иң яхшы тәҗрибәләре» һәм «Туган (татар, чуваш, удмурт, мари, мордва) телләрдә белем һәм тәрбия бирүне оештыра торган иң яхшы балалар бакчасы» дигән республика конкурслары үткәрде. Бу өлкәдә тормыш җанланып китте дияр идем.

Безнең барыбызга да, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларына да бу комиссия эшенә ярдәм итәргә кирәк. Хәер, «Безнең мирас» инде болай да әлеге юнәлештә шактый уңышлы эшләп килә, чөнки журналның исеме үк алдыгызга мөһим бурычлар куя. Сезнең эшчәнлегегез соңгы елларда республикада бик активлашып киткән тарихи-мәдәни мирасны тергезү хәрәкәтенә аваздаш. Телебез-мәдәниятебезне саклауның тагын бер юлы бу. Моны «Яңарыш» Республика фонды башлап җибәрде һәм аның төп әһәмияте – кешеләрдә тарихи мираска карата кызыксыну уяту. Соңгы елларда җәмгыятьтә республикабызның күпмилләтле халкының тарихы, рухи һәм матди мирасы, шул исәптән авыллар-шәһәрләр тарихы, гаилә шәҗәрәләре белән кызыксыну көчәйде. Хәзерге заманда моның өчен мөмкинлекләр җитәрлек, архивлар ачык. Үз нәселең җепләрен эзләү-өйрәнү балаларга үрнәк күрсәтү генә түгел, аларның теләк-омтылышларына тиешле юнәлеш бирү, үз тамырларына ихтирам, горурлык тудыру дигән сүз дә.

Телебезне саклау юнәлешендә Татарстан Республикасы Диния нәзарәте алып бара торган эшчәнлекне дә билгеләп үтәр идем. Мәсәлән, алар мәчетләр каршында татар теле дәресләре оештырдылар, вәгазьләрне, нигездә, татарча алып баралар. Бу гамәл ислам диненең төп кануннарына туры килә, чөнки безнең динебез белемгә омтылышны хуплый. Хәдисләрнең берсендә болай диелгән: «Гыйлем иясе, яки гыйлем алучы, яисә гыйлемне тыңлаучы бул. Ләкин дүртенчесе булма, һәлак булырсың».

Милләтне саклап калуның юнәлешләре күп, алар барысы да бер максатка – телгә ихтыяҗны арттыруга хезмәт итәргә тиеш.

– Сез нигез салган күптелле мәктәпләр бүгенге көндә уңышлы гына эшләп килә. Күпләребез моны туган телебезне саклап калуның бер юлы дип кабул итте...

– Дөньяда интернет-сан технологияләре (цифрлы технологияләр) алга киткән заманда безгә, әйткәнемчә, туган телебезне саклауда яңа ысулларны киң кулланып, җиң сызганып эшләргә кирәк. Күп телдә белем бирү комплекслары булдыру – шуның бер уңай чагылышы. Бу бөтен яктан да отышлы һәм барлык кануннарга, стандартларга туры

килә торган гамәл. Хәзер ата-аналарга балаларының кайсы телдә белем алуын сайлау хокукы бирелгән. Баласын белемле һәм булдыклы итеп тәрбияләргә тырышкан ата-ана, аның үсешен чикләп, телләрнең кайсысыннан булса да баш тартуга бармас дип уйлыйм, чөнки ул – замана таләбе.

Бу – мәктәпләрдә һәр телгә тигез шартлар тудырыла, димәк, татар телен укытуга да тиешенчә игътибар бирелә, нәтиҗәле ысуллар кулланыла дигән сүз. Әйе, безнең мәктәпләр телебезне, мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калу юнәлешендә җитди адым булып тора. Шуны аңларга кирәк: хәзерге заманда без балаларыбызны бары тик татарча гына укыту кысаларына кертеп утырта алмыйбыз... Төп максат – балаларны дөнья күләмендә көндәшлеккә сәләтле итеп әзерләү. Кимендә өч тел – рус, татар һәм инглиз телләрен белү баланың мөмкинлекләрен арттыра, үз сәләтен тормышка ашыру өчен киң юллар ача. Мин гел әйтеп киләм: бүген дөнья ачык, шуңа күрә күп телдә белем бирү мәктәпләренә ихтыяҗ зур һәм ул арта барачак. Быел Казанда һәм Алабугада ачылган мәктәпләребездә укырга теләүчеләрнең гаять күп булуы шул хакта сөйли. Әлбәттә, мондый мәктәпне тәмамлаучылар барысы да Татарстанда калмас, үз сәләтләре һәм мөмкинлекләре буенча төрле эш урыннары сайлар. Иманым камил, алар, яхшы укып, көндәшлеккә сәләтле булып чыгалар икән, димәк, кирәкле белгечләр сыйфатында, яхшы урыннарда эшләячәк. Башка илләр тәҗрибәсен карагыз, чит илләрдә укып-эшләп, лаеклы урынын тапкан балалар шул илләр белән үз илләре арасында икътисадый элемтәләр коруда бик яхшы арадашчылар була ала. Шунысын да онытмыйк: татар телен белү төрки дөнья белән бәйләнешләр өлкәсендә эшләү мөмкинлекләре ача. Мөселман дөньясында да, төрки халыклар арасында да татарлар гыйлемле халык буларак танылган. Безнең киләчәк буын татар егет-кызлары да шушы традицияне дәвам итәр, башка төбәкләрдә, чит илләрдә дә үз илен, үз республикасын, үз милләтен лаеклы күрсәтер дип өметләнәбез.

– Минтимер Шәрипович, сентябрь аенда ил буйлап халык исәбе алыначак. Соңгы вакытта бу вакыйгага тирәсендә төрле сәяси ыгы-зыгы кузгалды. Сезнең әлеге мәсьәләгә мөнәсәбәтегез ничек?

– Бөтенроссия халык исәбен алу – илнең бөтен халкы катнаша торган, ил үсеше өчен кирәкле, даими үткәрелүче гамәл. Мәгълүм булганча, безнең ил биләмәсендә беренче җанисәп 1718-1727 нче елларда алынган. Бу ниндидер сәясәт чагылышы да, закон белән мәҗбүр итү дә түгел. Җанисәп – ирекле гамәл, һәркемнең үз ихтыярында.

Безнең өчен исә үз сүзебезне, үз карашыбызны турыдан-туры белдерү мөмкинлеге. Телне, милләтне саклау күзлегеннән караганда, җанисәп – безнең ни дәрәҗәдә татар булуыбызның иң ачык күрсәткече. Аны хәтта сынау дип тә атарга буладыр, мөгаен.

Безнең телебездә бик матур, тирән һәм күп мәгънәле **«хак»** дигән сүз бар. Халык исәбендә катнашу ул – безнең хакыбыз. **Хак-бәһа,** кыйммәт мәгънәсендә алсак, без никадәр күбрәк булсак, ил күләмендә бәһабез-дәрәҗәбез дә шулкадәр югарырак дигән сүз. Димәк, безнең белән шул дәрәҗәдә санлашалар. **Хак-бурыч** мәгънәсе, аңлашыла ки, киләчәк буыннар алдында җаваплылыгыбызны күздә тота. **Хак-дөреслек** исә хаклык мизгелен аңлата, ягъни җанисәп чынлыкта ни хәлдә икәнебезне чагылдырачак. Минем фикеремчә, әлеге сүзнең җанисәпкә иң туры килгән мәгънәсе – **хак-хокук.** Әлбәттә, бу очракта сүз законда язылган хокуклар турында гына түгел, тумыштан, тарихыбыздан килгән хокуклар турында бара. Без шушы хакыбыздан тулысынча, кем әйтмешли, күкрәк киереп, горурланып файдаланырга тиешбез. Татар булып тугансың, үзеңне татар дип саныйсың икән, бернинди чит фикерләргә бирелмичә, курыкмыйча җанисәпкә кереп каласың һәм милли үзаңың ни дәрәҗәдә икәнен чынлыкта күрсәтәсең. Әгәр дә кемдер ниндидер өндәүләргә-үгетләүләргә бирелеп башкача эшли икән, димәк, бу – аның татар булырга йә ихтыяры җитми, йә ихтыяҗы юк дигән сүз. Андыйларны, «татар булып языл», дип, милләт исәбенә кертергә тырышуның мәгънәсе бармы икән?! Әйтик, җанисәпкә татар булып кереп тә, милләтне саклап калуга үз өлешен кертү теләге белән балаларына ана теле өйрәтеп, милләтнең киләчәген кайгыртучы ата-аналар исәбенә кермәсә, моннан ни файда? Шуңа күрә җанисәп тирәсендә ниндидер сәяси уен кузгатып йөрүләрне өнәп бетермим. Әйткәнемчә, бу – һәркемнең үз эше, намус эше. Әгәр үз милләтеңнең санын арттыруны чын күңелдән кайгыртасың икән, ул көндәлек тормышта чагылсын. Әйтик, дәүләт һәм төбәк җитәкчеләре балалар санын арттыруны тирән уйланылган сәясәткә әйләндереп, эзлекле-нәтиҗәле эш алып барырга тиешләр.

– Сез республикабыз белән җитәкчелек иткәндә, Татарстаныбыз төрле милләт, төрле дин вәкилләре янәшә дус-тату яшәгән республика буларак танылды. Толерантлык, ягъни тигез караш дигәндә бүген Татарстанны дөнья күләмендә дә үрнәк итеп китерәләр. Татарстан әлеге юнәлештә алга таба да үрнәк төбәк булып калырмы?

– Безнең башка юлыбыз юк, башкача булу мөмкин дә түгел. Чөнки республикада яшәүче барлык халыкларга да тигез караш, мәнфәгатьләр тигезлеге – Татарстандагы югары казанышларның нигезе. Кемнеңдер мәнфәгатьләрен кимсетү исәбенә башка берәүнең мөмкинлекләрен арттыруга беркайчан да юл куярга ярамый. Бездә бит күпме милләт вәкиле, төрле дин тотучылар яши, шуңа күрә хәтта республикадагы районнар тормышы да, шул сәбәпле, бер-берсеннән күпмедер дәрәҗәдә аерылып тора. Болар бит барысы да гасырлар дәвамында туган үзенчәлекләр. Болар – бик нечкә җисем һәм төшенчәләр. Үз мәдәниятенә, гореф-гадәтләренә, шул исәптән туган теленә карата мөнәсәбәткә һәр кеше бик сизгер, шуңа күрә бик ипләп, уйлап эш итәргә кирәк. Республика җитәкчелеге төп игътибарны һәрвакыт шуңа юнәлтә. Исегезгә төшерим, 1990 елда кабул ителгән ТРның Дәүләт суверенитеты турындагы декларациядә үк, «башка милләтләрнең телләрен саклау һәм үстерү гарантияләнә», дип яздык. 1992 елда республикада, ТР Законы нигезендә, Туган тел көне кертелде. Беләсез, ул һәр ел 26 апрельдә – Г.Тукай туган көнне үткәрелә. Шул ук елда «Татарстан Республикасы телләре» турында закон кабул ителде. 2021 елны Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан итү дә шушы максатка – бездә яшәүче милләтләрнең телләрен саклап калуга эшли. Тагын бер мисал: алда телдә алынган күптелле белем бирү комплексларын без «Адымнар – белемгә һәм килешүгә юл» дип атадык. Бу исем очраклы гына сайланмады, ул белем аркылы тынычлыкка-татулыкка атлау дигәнне аңлата. ■

Мин – татар!

Миргазиян Юныс,
күренекле язучы:

Туган телне саклау бүгенге көндә кешелек экологиясен саклау дәрәҗәсендә тора. Тел – кеше рухының формасы, эчтәлеге һәм аның яшәү шарты. Тел – рухи экология. Туган телдә – мең еллар буенча гореф-гадәтләр хәзинәсенең сөземтәсе, әдәп һәм әхлак кануннары, мең еллар туктаусыз язылып торган тарихның хакыйкый эчтәлеге.

Аяз Гыйләҗев,
Татарстанның халык язучысы:

Татар кешесе!
Иң беренче – үз телеңне бел! Аңа зур хөрмәт белән кара, башкаларны шуңа өйрәт. Онытма: синең телең – дөньядагы 14 телнең берсе. Телеңнән йөз чөергәннең теле көяр!
Җиде буын бабаларыңның исемен бел, шәҗәрәсен сакла, алга таба балаларыңа һәм оныкларыңа калдыр. Бабасын оныткан – алдагысын оныткан!

Роальд Сәгъдиев,

академик:

Мин татар халкының улы булуым белән горурланам. Без, татарлар, үзебезнең милли бердәмлегебезне сакласак иде.

Илдар Юзеев,

Татарстанның халык шагыйре:

Сан алуны көткәндә

Без башкорт та,
Без мишәр дә,
Керәшен дә, типтәр дә...
«Мин – татар!» – дип аваз бирәм
Сан алуны көткәндә.

Сарык булма,
Балык булма,
Тавык булма, бел, татар:
Даның сүнәр,
Җаның түнәр,
Калсаң әгәр мең татар.

Һич ышанма,
Әйтсәләр дә:
«Гадәттәге сан алу».

Аң бул,
Җан бул,
Бу – татардан
Сан киметеп җан алу.

Аю булма, бүре булма,
Аерылма, бүленмә!
Бердәмлек илгә – яшәүгә,
Таркалулар – үлемгә.
Уйла, татар:
«Булмасын, – дип, –
Соңгы тапкыр тын алу...»
Бу – тарлыкка,
Татарлыкка,
Бөеклеккә сыналу! ■

Тимербәкнең ил-йортына сәяхәт (1404-1406) көндәлеге

Руи Гонсалес де Клавихо

Бу җирләргә килгән татарларның чыгытай дип аталуының сәбәбе шунда: ул дәвердә Тарталиянең Дөргенче исемле ханы (Дөнья хәзинәсе) татар шәһәрендә туган була. Дөргенче, бик күп җирләрне яулап алып, дүрт улын калдырып дөнья куя: беренчесе – Габуй, икенчесе – Чыгытай, өченчесе – Исбәк, дүртенчесе – Черкәс. Болар барысы да бер анадан туган булалар. Үлем алдыннан әтиләре үзе биләгән мәмләкәттән һәр улына үз өлешен бүлеп бирә. Чыгытай исемле улына исә Сәмаркандны һәм шул тирәдәге өлкәләрне тәгаенли. Ул бөтен улларына да тату-тынычлыкта яшәргә васыять әйтеп калдыра. Бер-берегезгә ачу тоткан көннән бетәчәксез, ди.

Чыгытай батыр, кыю йөрәкле ир була. Тора-бара туганнар арасында көнчелек башлана, алар үзара низаг-сугышка кадәр барып җитәләр. Моны күреп-сизеп торган Сәмарканд халкы баш күтәрә һәм, Чыгытайны юк итеп, аның урынына үз кавеменнән бүтән кешене куя.

Чыгытай үтерелсә дә, аның монда җир биләгән, йортлар тоткан, мал-мөлкәтле кавеме кала. Шуннан соң җирле халык биредәге татарларны чыгытай дип атап йөртә башлый. Тимербәк шушы татар-чыгытай ыруыннан. Аңа хезмәт итүче, баш орып яшәүче сәмаркандлыларның күбесе башка кавемнән булса да, танылган чыгытай атамасы аларга да тагылып кала.

Илчеләр Кеш шәһәрендә җомга көн кичենә кадәр калдылар, аннан соң бер авылга барып кундылар. Икенче көнне, 30 августта, Тимербәккә караган зур йортка төшке ашка килделәр. Гаҗәеп зур бакча эчендәге бу йорт елга ярында утыра. Төштән соң илчеләрне Сәмаркандтан ярты көнлек юл ераклыгындагы Мисыр авылында кунарга калдырдылар. Илчеләрне озатып йөрүче егет, бүген үк Сәмаркандка барып җитәргә мөмкин, әмма бөек хакимебезгә сезнең килүегез хакында алдан хәбәр итәргә кирәк, дип, төнгә каршы чапкын җибәрде.

Таң беленгәндә чапкын кайтып җитте, Тимербәк испан илчеләрен һәм алар белән килгән Бабил солтанын да шушы авылдан ерак түгел генә бакчага алып барырга һәм аның әмерен шунда кәтәргә боерган.

Дәвамы. Башы журналның 2 нче (2021) санында.

Якшәмбе иртәсендә, 1 сентябрь көнне, илчеләрне кирпеч дивар белән уратып алынган, чакрымнарга сузылган зур бакчага алып килделәр. Бакчаның уртасыннан ургып су ташкыны ага, һәртөрле җимеш агачлары бихисап, тын сулы алты бассейн. Мәһабәт агач күләгәсеннән сузылган аллеялар бассейннарны бер-берсе белән тоташтыра. Юлына таш җәелгән зур аллеялар янәшәсеннән таррак сукмаклар тармаклана, алардан аркылыга-буйга бөтен бакчаны тамаша кылып чыгарга була.

Бакча уртасында казык койма белән уратып алынган җиртүбә өеп эшләнгән. Шуның иң биек ноктасында искиткеч матур сарай балкып күренә. Җиртүбәне тирән сулы канау аерып тора. Ике якта күпер бар. Шул күпер түрендә капкалар. Капка аръягында сарайга менү өчен баскычлар китә. Бакчада бәк кушуы буенча җибәрелгән шактый күп боланнар, фазаннар күренә. Бакчадан сәмән кирпеч белән әйләндереп алынган йөзем кырына күчә торган аралык бар. Йөзем кырының дивары буйлап утыртылган биек агачлар бик матур күренә.

Сарайлы бакча Талисия дип атала, алар телендә – Гөлстан. Монда инде илчеләргә бөтен шартларны тудырдылар. Мул табында ит ризыгы, җиләк-җимеш бихисап иде. Аннары арык янәшәсендәге болында чатыр корылды.

4 сентябрьдә, атнакич көнне, илчеләр янына бер егет килде. Ул бәкнең туганы икән, Туктамыш ханның кешеләрен озату мәшәкате аркасында, Тимербәк әлегә илчеләрне кабул итә алмый, ди. Кәефләре төшмәсен, күңелләре күтәрелсен, дип, ул Бабил солтанына һәм илчеләргә бәйрәм, аш мәҗлесе оештыру өчен шушы егетне юллаган. Күп бәрәннәр китертеп, суеп, аны тәмләткеч үләннәр белән пешереп, елкы ите кыздырып, әллә ничә төрле дөге ризыклары, пылау әзерләп, җиләк-җимешләр куеп, илчеләргә табын әзерләделәр. Мәҗлестән соң ике ат, ефәк күлмәкләр, бүрекләр бүләк иттеләр. Илчеләр бу бакчада дүшәмбегә, 8 сентябрьгә кадәр тордылар.

Шул көнне бәк илчеләрне алып килергә дип кешеләр җибәртте; гадәттә, ул яңа килгән илчеләрне биш-алты көн үткәч кенә, дәрәҗәлерәкләрне, гомумән, озаграк тотып кабул итә икән.

Шулай итеп, 8 сентябрь көнне илчеләр Сәмәркандка кузгалдылар. Бакчалар, үзәнлекләр, бихисап йортлар рәте, базарлар аша өч сәгать чамасы баргач, кала читендәге бакчалы сарайга килеп җиттеләр.

Шунда ук аларны янәшәдәге бинага алып керделәр. Ул арада ике егет кереп, илчеләр бәккә дип алып килгән бүләкләрне чыгарырга кушты. Алар бу әйберләрне тәртипкә китереп, бәкнең яраннары – морзаларга тапшырачаклар икән, тегеләр исә билгеле бер җай белән бүләкләрне бәк катына куячаклар, имеш. Бабил солтанының да бүләкләрен алдылар. Шуннан соң илчеләрнең кулыннан тотып алып киттеләр.

Бакчага керә торган ишек биниһая биек, зур итеп, алтынлап бизәкләп, искиткеч матур эшләнгән. Ишек катында чукмар тоткан сакчылар шактый күп, боларга якын килергә бирәү дә базмый. Илчеләр эчкә үтүгә, сыртына агачтан бизәкләп эшләнгән манаралар куелган, очына икешәр байрак эленгән алты фил хайванын күрделәр. Фил сыртына атланган кешеләр, мәзәкләр күрсәтеп, җыелган халыкның күңелен ача иде. Илчеләрне арырак алып киттеләр, шунда ук үзләренең бүләк әйберләрен беләкләренә пөхтә итеп салып баручы егетләрне искәрделәр. Аннары илчеләргә үзләренең бүләкләре турына басып бераз көтәргә куштылар, тагын кузгатып алып киттеләр. Илчеләр янәшәсендә гел теге ике егет булды. Тимербәк Кастилия короленә җибәргән илче дә безнең белән иде, каршыга очраган бере аңа карап көлеп китә, чөнки ул кастильчә киенгән иде.

Илчеләрне югарырак урында утырган өлкән кеше катына китерделәр. Ул Тимербәкнең кайсыдыр кыз туганының улы икән. Илчеләр аңа баш иделәр; шулай ук югарырак урында утырган угланнарга да, – алар хакимнең оныклары икән, – баш иделәр.

Шул мәлдә корольнең Тимербәккә юлланган хатын сорадылар. Угланнар арасыннан берсе – хакимнең иң олы варисы – Мираншаһ (Гыймраншаһ. – **Тәрҗ. иск.**) улы хатны алды, шуннан соң өч углан бергәләп хатны бәккә алып китте. Алар артыннан илчеләр дә кузгалды. Бәк үзе искиткеч матур йортка үтәсе ишек төбендә, калку урында утыра иде; каршында – су агымын биеккә сиптереп торучы фонтан, суында кызыл алмалар йөзеп йөри. Ул чигүле ефәк көрпә өстендә утыра, түгәрәк мендәрчеккә терсәге белән таянган. Бизәксез генә елтыр ефәк күлмәк кигән, башында – энҗе, асылташлар белән бизәлгән биек ак бүрек, очында якут таш җем-җем килеп балкып тора.

Илчеләр, аны күргәч, кулларын күкрәкләренә кушырып, уң тезләренә таянып баш иделәр, шуннан соң, якынрак килеп, тагын бил бөктеләр, аннары килеп баш иделәр дә тезләнгән килеш катып калдылар. Тимербәк торырга һәм якынрак килергә боерды. Баядан бирле озата килгән егетләр, якынга килергә базмыйча, арткарак чигенделәр, каршыда торган өч морза, бәкнең иң якыннары (Шаһ Малик морза, Борынтай морза, Шәех Нуреддин морза), якын килеп, илчеләрнең кулыннан тотып, бәк катына китереп тезләндерделәр. Тимербәк тагын да якынрак килергә боерды, чөнки ул картаю аркасында начар күрә, күз кабакларын да авыр гына күтәрә иде. Ул үптерергә дип кулын сузмады, бу гадәт аларда юк, үзе дә бөек илбашларының кулын беркайчан да үпми, үзен югары куя белә икән.

Безгә ул шундый сорау белән мөрәҗәгать итте: «Минем улым галиҗәнап король ничек яши, хәл-әхвәле, сәламәтлеге аманмы?» Илчеләр аңлатып, килү максатын сөйләп бирделәр. Бәк аларның бөтен фикерләрен игътибар белән тыңлады. Сүз төкәнүгә, Тимербәк аяк очында утырган егетләргә эндәште. Аларның берсе – Тарталия ханы Туктамыш улы, икенчесе – Сәмәрканд әмирләре нәселеннән, калганнары исә бәкнең үз нәсел-ыруыннан чыккан мәртәбәле адәмнәр иде.

«Күз салыгыз бу илчеләргә, аларны минем улым – Испания короле җибәргән, кайсыдыр ки җир читендә яшәүче франк корольләре арасында ул – беренче. Алар, чынлап та, бөек халык, мин үземнең улыма – Испания королենә – фатиха бирәм. Бүләкләр җибәрмичә, хат кына юллаган булса да, шөкер итәр идем. Аның сәламәтлеге, кылган эшләре хакында белү минем өчен бүләк алудан кадерлерәк».

Король җибәргән хатны Тимербәкнең оныгы аның каршында югары күтәреп торды; дин өйрәтмәләре магистры шул мизгелдә тылмачка әйтте: «Бәккә җиткерегез, аның улы – король җибәргән хатны миннән башка беркем дә укый алмый, галиҗәнапка кайчан уңай, шул чакта укып бирермен», – диде.

Тимербәк шул мәлдә оныгы кулыннан хатны алып ачты, җәеп карады да хәзер укырга кирәклеген әйтте. Мин сезнең ихтыярда, әзер, диде магистр. Шулчак Тимербәк, соңыннан, ялгызым гына калгач, мин сезне дәштерермен, диде.

Аннары илчеләрне, күтәреп китереп, бәкнең уң ягына утырттылар. Аларның урыны элек ел саен түләп барылган ясакны таләп итәргә килгән кытай императоры Чәйсхан илчесенекеннән түбәндәрәк иде. Бәк, испан илчеләренең урыны кытай илчесенекеннән түбәнрәк икәнен күргәч, урыннарын алыштырырга дип әмер бирде. Ул арада яран, кытай илчесенә килеп, бәкнең улы – Испания короленең илчеләреннән син, юлбасар, дошманыбыз илчесе, түбәнрәк урында утырырга тиеш, яңадан мондый ният белән йөрмәс өчен сине Ходай ихтыяры белән асып куярга кирәк, диде. Шуннан соң бәк үткәргән бәйрәм-мәҗлесләрдә илчеләрне гел шул тәртиптә утырттылар.

Испан илчеләре турында бәкнең әнә шулай кайгыртуын тылмач аша җиткерделәр.

Кытай хакиме Чәйсхан атлы икән, ягъни тугыз мәмләкәт императоры дигәнне аңлата, ә чыгытайлар аны, мыскыллап, Дуңгыз хан дип йөртәләр. Ул күп җирләр биләп тора, Тимербәк аңа ясак түләп килгән, хәзер инде бирәсе килми икән.

Төрле тарафтан килгән илчеләрне җайлап утырткач, мәҗлес башланды. Какланган, пешкән, кыздырылган бәрән, елкы ите бихисап иде. Түтәрәм-түтәрәм итне, ике яктан тоткалы күн җәймәләргә салып, тартып алып киләләр, күтәрсәң, ит авырлыгыннан бу җәймәләр шартлап ярылырга мөмкин. Хезмәтчеләр бәккә егерме адым кала туктадылар, күн җиңсә кигән, күн алъяпкыч бәйләгән бавырчылар чыгып тезләнделәр дә, итне бүлгәләп, алтын-көмеш һәм чүлмәк фарфор (анысы бик кыйммәтле санала) савытларга салдылар. Иң тәмле саналган ризык елкының ял ите санала икән, аны ун төрле алтын-көмеш табаларга салып, янәшәсенә сөякле бәрән ите (аяк-тез сөякләре куелмый), елкы бөерен йодрык чаклы түгәрәк итеп кисеп, һәр савытка тагын бәрән башы куйдылар. Шундый ук тәртиптә бүтән савытларга да ит бүлеп салдылар. Һәммә кунакка да җитәрлек булгач, савытларны рәт-рәт тезделәр.

Аннан соң хезмәтчеләр шулпалы мискиләр алып чыктылар, аңа тоз салып болгаттылар да әз-әзләп ит өстенә йөгерттеләр. Юка ипи камырын, дүрткә бөкләп, ит өстенә куйдылар. Бар да әзер булгач, бәкнең иң якыннары, яраннары табаларны икешәр, өчәр кеше тотып, – бер генә кеше моны күтәрерлек түгел, – бәк каршысына китереп куйдылар. Ул исә аерым бер хөрмәт йөзеннән үз алдында торган ике табаны испан илчеләренә илтергә кушты. Итле савытларны алга кую белән шунда ук кире алып та киттеләр. Боларда шундый гореф-гадәт икән: мәҗлестә ашыйсы ризык төрен өеңә җибәрү – бу инде санга санау, хөрмәтләү билгесе була. Алга өелгән ул итнең күплегенә хәйран калырлык иде. Барысын да өйгә илтсәләр, ярты ел ашарга җитәрлек.

Табынга парда пешкән, кыздырылган иттән, төрле-төрле умачлы шулпа ризыкларыннан соң, кавын, йөзем, шәфталу кебек бакча нигъмәтләре мулдан китерелде. Алтын һәм көмеш тустаганнарда таратылган бия сөте бик татлы иде, аны җәй айларында эчәр өчен әзерлиләр икән.

Мәҗлестән соң Кастилия короле җибәргән бүләкләрне күтәргән егетләр бәк каршыннан үттеләр, Бабил солтанының бүләкләре дә шунда иде. Аннары Тимербәккә шул көнне үзенә бүләк ителгән өч йөз баш аргамак өерен күрсәттеләр. Тамаша беткәннән соң, илчеләрне күтәреп алып киттеләр. Аларны кайгыртып, саклап торачак егеткә тапшырдылар. Ул Тимербәкнең баш сакчысы булып чыкты. Бабил солтанын илтеп куйганнан соң, ул илчеләрне бәк сараена якын гына урынга – бакчасы, суы булган бинага илтеп урнаштырды.

Илчеләр киткәннән соң, бәк Кастилия короле җибәргән бүләкләрне китертергә боерган, карап чыгып, бик канәгать калган. Кызыл тукыманы иң өлкән хатыны Биби ханым (ул мәҗлестә утырды) һәм калган хатыннары үзара бүлешкәннәр. Бабил солтанының һәм калган кунакларның бүләген бәк ул көнне карап тормаган. Аның гадәте: бүләкне өч көн үткәч кенә карау икән. Бәк илчеләрне кабул иткән әлеге бакча һәм йорт Дилкош дип атала, анда киез, ефәк тирмәләр бик күп иде. Бәк анда икенче җомгага кадәр яшәде, аннан соң ул бакчалы, бик бай Баги Чинар дип аталган сараена күчеп китте.

15 сентябрьдә, дүшәмбе көнне, Тимербәк, бу сараеннан китеп, шулай ук бакча эчендә утырган искиткеч матур итеп салынган бүтән сараена күченде. Бакчасының мәһабәт капкалары кирпечтән бизәкләп, ялтыравык ташлар белән алтын йөгертелеп эшләнгән. Шул көнне бәк илчеләрне, үзенең туган-тумачаларын, ирле-хатынлы кунаклар чакырып, олы мәҗлес үткәрергә боерган. Очсыз-кырыйсыз бакчада нинди генә җимеш агачлары юк, агач койма белән каймаланган аллеядан, ком сибелгән күләгәле юллардан кешеләр йөреп тора. Һәркайда тирмәләр, чигүле келәмнәрдән, төрле төстәге ефәк тукымадан күтәрмәләр куелган.

Бакча уртасында хачка охшатып эшләнгән бик матур бина балкып тора. Эче искиткеч бай бизәлгән. Керү белән зур залга эләгәсең. Нәкъ ишек турында, түрдә сөрмәле ал-

тын йөгертеп эшләнгән зур өстәл тора, кеше гәүдәсе биеклегендә, иңе өч терсәк булыр. Өстәл алдында келәмнәрдән, ефәк тышлы мендәрләр өелгән урын әзерләнгән. Анда – бәк урыны. Диварлар алсу төстәге ефәк пәрдә белән капланган. Пәрдә идәннән түшәмгә кадәр көмешкә алтын йөгертеп, төрле асылташлар белән зиннәтләнгән, энҗе, зөбәрҗәт кашлар куелган каптырмалар белән бизәлгән.

Бер карыш иңлегендә булыр, чуклы, ефәк тасмалар идәнгә кадәр сузылып төшкән, шулай ук асылташлар белән бизәлгән. Ул тасмаларның җиләс һавадан салмак кына дулкын йөгертеп тирбәлеп торуы искиткеч матур күренеш хасил итә. Залга керү ишеге гөмбәзле итеп эшләнгән. Анда сөңгегә охшаган колгаларга шундый ук асылташлар белән бизәлгән пәрдәләр эленгән; ул пәрдәләрдән ефәктән ишелгән бауга асылган зур-зур чуклар идәнгә кадәр төшеп тора.

Бүтән заллардагы зиннәтләр дә, пәрдәләр дә үзгәрәк, бер-берсен кабатламый. Идәнгә келәмнәр, камыш чипталар җәелгән. Үзәк залда, ишектән кергәч, аяклары һәм өслеге тоташ итеп алтыннан эшләнгән дүрт аяклы ике өстәл тора. Буйга – биш терсәк, иңгә өч терсәк булыр. Өстәл өстенә җиде алтын кувшин куелган. Шуларның икесе зур-зур энҗе, зөбәрҗәт, фирүзә ташлар белән бизәкләнгән. Һәр кувшинның борынына якут таш беркетелгән. Өстәлдә тагын алты касә тора, берсенең эче бик сирәк очрый торган зур түгәрәк энҗе таш белән бизәлгән, уртасында ике бармак калынлыгы якут таш нур чәчеп тора.

Монда үтәчәк мәҗлескә испан илчеләре, тылмач булмау сәбәпле, соңгарып килделәр. Тимербәк инде табыннан торган иде, тылмачны көтеп тормыйча, нәкъ әйтелгән вакытта килергә тиешлекне белдерде. Бу очракта ул илчеләрне гафу итте, чөнки бәйрәм дә бит алар хөрмәтенә, аның сараен тамаша кылып, хушланып йөрсеннәр дип оештырылган иде.

Тимербәк кунакларның вакытында килеп җитүен оештыра алмаган яраннарына бик ачулы иде. Бераздан тылмачны табып китерделәр. Шундый әмер бирделәр: «Синең үз вакытыңда франк илчеләре янында булмавың өчен бәк бик ачулы. Моннан соң үз вазыйфаңны үтәргә һәрвакыт әзер тору өчен сиңа шундый җәза бирелә: борыныңны тишеп, бау кидереп, бөтен урда буйлап тартып йөртү гадел хөкем булачак!» Шушы әмер әйтелүгә, берничә кеше, ташланып, тылмачның борыныннан эләктереп тә алдылар. Шул мәлдә, илчеләрне алып килүгә, җаваплы егет, бәккә ялынып, тылмачны җәзадан коткарып калды.

Соңыннан илчеләр яши торган йортка йомышчы килде, бәйрәм мәҗлесендә катнаша алмавыгыз сәбәпле, бәк сезгә тигән өлешне җибәрә, дип, биш түшкә бәрән ите, ике зур чүлмәк шәраб калдырып китте.

Алдагы дүшәмбедә (22 сентябрь) Тимербәк, әлеге сараеннан китеп, икенчесенә күчте. Бакча эчендәге бу сарай дүртпочмаклы биек дивар белән уратып алынган. Һәр почмагында түгәрәк манара тора. Бакча уртасындагы хач рәвешендә эшләнгән бинаның шәүләсе бассейндагы су өслегендә сурәтләнә. Элек күргәннәргә караганда да мәһабәтрәк, купшылыгы, алтын һәм төрле төсләрдә бизәлеше ягыннан тагын да баерак иде бу зиннәтле сарай.

Тимербәкнең бакчалы сарайлары һәммәсе дә шәһәр читендә урын алган. Ә монысы Баг-и Нау дип атала. Монда да бәк зур бәйрәм оештырган иде; бик күп кеше арасына илчеләр дә чакыртылды. Бу мәҗлестә бәк шәраб эчәргә әмер бирде, үзе дә эчте (шәрабны бәк ихтыярыннан башка, яшерен эчү гадәте юк икән боларда). Шәрабны аш-су килгәнче үк шулкадәр еш чыгарып торалар, күз алдында исерә баралар. Исермәгәч тә, бәйрәм бәйрәм түгел икән алар өчен. Шәраб алып килгән аякчы алдыңа тезләнә дә, бер касәне эчеп бетерүгә, икенчесен тутырып кына тора, әйтерсең лә, аның бүтән

бер мәшәкате дә юк. Бер аякчы арыса, икенчесе аны алыштыра да касәләргә туктаусыз шәраб бүлеп тора башлый. Бер аякчы күп кешегә бүлеп тора дип уйлый күрмәгез тагы бер яисә ике кунакка бер аякчы өзлексез кыстап, мәҗбүри эчертеп тора. Кем дә кем эчүдән баш тарта икән, димәк, бәкне санга сукмый, чөнки бөтен табын аның ихтыяры белән эчәргә тиеш. Зур касәләргә дә мөлдерәмә тутырып салалар, берәү дә төбенәчә эчүдән баш тарта алмый, кем дә булса калдырып эчсә, аның касәсен кире алмыйлар, уртлап-уртлап булса да ул аны барыбер төбенә кадәр эчеп куярга мәҗбүр була. Ә инде бәк исәнлегенә күтәрсәләр, соңгы тамчысына кадәр төпләп куярга тиешсең. Кем бөтенесеннән күбрәк эчә ала, аны баһадир дип атыйлар. Кем дә кем эчүдән баш тарта, аны барыбер мәҗбүр итәләр.

Шул бәйрәмгә килер алдыннан бәкнең яраны илчеләргә бер кувшин шәраб китерде, бәк катына әйбәт кәеф белән килү өчен күпме кирәк, шулай эчегез, диде. Мәҗлескә килгәч, аларны элеккеге тәртиптә утырттылар. Шәрабтан соң ит ризыклары: кыздырылган елкы ите, парда пешкән, кыздырылган бәрән ите, тозлаган, какланган итләр, төрлечә әзерләнгән пылау табынга килә-китә торды. Табын соңында бәкнең бер яраны көмеш савыт күтәреп чыкты, савыт эче көмеш акчалар белән тулы иде, монда аны тәңкә дип атыйлар икән. Менә ул савыттагы тәңкәләрне сибә башлады, калганын илчеләрнең итәгенә бушатты. Шуннан соң Тимербәк илчеләргә ефәк халат кидерергә боерды. Илчеләр, алар гадәтенә тугры калып, хаким каршында өч тапкыр тезләнеп баш иделәр. Тимербәк, иртәгесе көнгә төшке ашка чакырып, илчеләр белән хушлашты.

Икенче көнне, 23 сентябрьдә, монысына якын гына булган икенче сарайга (Дилкош дип атала) күчеп, бәк янә мәҗлес үткәрде. Монда ерактан хәрби түрәләр дә чакырылган иде. Биредәге бакча да, сарай да искиткеч матур иде. Мәҗлестә бәк бик кәефле утырды, үзе дә шәраб эчте, башкаларны да эчәргә кыстады. Гадәт буенча табыннан бәрән, ат ите өзелмәде. Аштан соң бәк илчеләргә ефәк халат бүләк итәргә кушты, аннан соң илчеләр хаким сараеннан ерак түгел генә үз торакларына кайттылар.

Мондый бәйрәм көннәрендә мәйданга шулкадәр күп халык җыела ки, әгәр илчеләрне озатып йөрүче сакчылар булмаса, бәкнең сараена үтү мөмкин булмас иде. Мыж итеп торган халыкның өс киемнәре дә, йөзләре дә тузаннан бертөсле булып беткән. Сарай бакчасы артында елга, сугару арыклары, киң кырлар җәелеп киткән. Шул кырда бәк үзенә, хатыннарына, гаскәриләргә махсус тирмәләр корырга кушкан.

Бәк тирмәсен корганнан соң, югары дәрәҗәледән алып түбәнгә кадәр һәммәсе үз тирмәсен кая куярга икәнен белә, шуңа күрә бу эш тәртип белән, ыгы-зыгысыз гына башкарыла. Өч-дүрт көн үттеме икән, хакимнең үзе, хатыннарының тирмәсе тирәли тагын егерме мең тирмә куелды, монда бөтен тирә-яктан халык агыла иде. Шушы урда белән бергә күчеп йөрүче күпме сугымчы, пешекче, пешкән-кыздырган ит сатучы, җиләк-җимеш, арпа-бодай сатучы, камыр ризыгы пешерү осталары, көмешчеләр, һәртөрле һөнәр ияләре – кем генә юк бу ыстанда, һәрберсенә үз урыны, үз урамы билгеләнгән. Моннан башка тагын гаскәр кая бара, шунда мунчачылар, тиз генә бина корып, тимер мичле, су кайнарлатырга тимер казанлы, парлы мунчаны әзерләп тә өлгертәләр. Шулай итеп, урдага килгән һәр кеше үз урынын белеп эш итә. Бәк исә илчеләрне, урда торган җиргә якын булсыннар дип, үз карамагындагы бакчалы сарайга күчертте.

29 сентябрьдә, дүшәмбе көнне, бәк Сәмәркандка китте. Анда ул кала бусагасында ук урнашкан йортка тукталды. Бу йортны Тимербәк үзенең өлкән хатыны Биби ханымның әнисе хөрмәтенә салдырган. Аның җәсәде дә шушы йорт кырына күмелгән.

Йорт бик затлы, пөхтә җыештырылган иде. Аларда йорт-җир эчен әйбер белән тутыру гадәте юк, әмма монда әйбер-кара шактый күренә, чөнки әлегә төзелеп бетмәгән, осталар көн саен эшлиләр.

Шушы көнне бәк, мәҗлес үткәрергә әмер биреп, илчеләрне дә чакырды. Кытай чигендәге элек үзенә караган җирләрдән килгән илчеләрне кабул итүгә багышланган мәҗлес иде бу. Әлеге илчеләрнең киемнәре мондыйрак иде: кафтанга охшаган бишмәт кигәннәр, мехы таушалган күренә, башларында кечкенә бүрек, ул бүрек шулкадәр сай, бәләкәй ки, менә төшәм, менә төшәм дип тора. Илчеләр барысы да мехлы киемнән, кайсының мехы тышка, кайсыныкы эчкә караган, тышкы рәвешләре белән болар тимерчегә охшаган иде. Бәккә бүләк итеп эшкәртелмәгән сусар тиресе, кеш, ак төлке, лачын тиресе китергәннәр. Алар кытайлар кебек үк нәсарилар иде, Тимербәк йортында яшәүче, элеккеге Тартария хакиме Туктамышның оныгын үзләренә хаким итеп җибәрүен үтенеп сорарга килгәннәр.

Тимербәк ул көнне сәедләр белән озаклап шахмат уйнады. Сәед дип алар Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) нәселеннән чыккан затларны атыйлар. Бәк әлеге илчеләрнең бүләкләрен ул көнне карарга теләмәде, ләкин аларны барыбер күрсәтергә дип алып килделәр.

2 октябрьдә, атнакич, илчеләргә бәкнең баш вәзире килде, франкларның һәр көнне шәраб эчү гадәтен беләм, әмма хәзер минем каршымда күпме кыстап та теләгәнчә эчмиләр, дип, бәк кучтәнәч итеп ун бәрән, бер елкы түшкәсе, туйганчы эчәрлек шәраб җибәргән. Ашап-эчкәннән соң, илчеләргә күлмәк, бүрек, ефәк җилән кигезделәр, тоякларын биетеп торган айгырлар бүләк иттеләр.

6 октябрь, дүшәмбе көнне, бәк үзенең урдасы (үзләре ыстан диләр) торган кырда зур бәйрәм үткәрергә ниятләде. Хатыннары белән бөтен ир туганнарына, хатыннары белән улларына, оныкларына һәм яраннарына шул кырга җыелырга күрсәтмә бирде. Урдага илчеләрне дә чакыртып алдылар. Анда рәт-рәт тезелгән матур тирмәләр бигрәк тә елга буйларында бик күп иде. Илчеләрне тирмәләр арасындагы урамнардан үткәрделәр. Анда яу сәфәренә кузгаласы гаскәриләргә кирәк-яраклар сатыла иде. Бәк үзе урнашкан тирмәгә җитәрәк, илчеләрне күтәрмә астына кертеп утырттылар. Күтәрмә озынча, төрле төстәге ефәк кисәкләре белән бизәлгән җитен тукымадан; аны ике колгага күтәртеп, як-якларыннан бау белән тарттырып куйганнар. Тирә якта мондый күтәрмәләр шактый күренә, кояш нурыннан саклану, җиләс булсын өчен, аларны шулай озын, биек итеп ясыйлар.

Якындарак зур, биек павильон күзгә чалынды, ул тирмә кебек эшләнгән, әмма дүртпочмаклы, биеклеге дә өч сөңге шәйле булыр, аннан да биегрәк булмаса әле; як-яклары җиргә сөңге озынлыгында тимичә кала, киңлеге исә йөз адымнар булыр.

Дүртпочмаклы павильонның түбәсе түм-түгәрәк гөмбәз белән тәмамлана. Гөмбәз киң күкрәкле адәм калынлыгындагы унике баганага таяна. Алтынлап, төрле төсләрдә бизәкләп эшләнгән. Эчтән бер почмактан икенче почмакка бер-берсенә кыршау белән тоташтырылган өчәр бүрәнә-бәпкә түбәне күтәреп тора. Өстән баганалар буйлап сузылып төшкән ефәк тасмалары, бәйләнеп, арка хасил итә.

Павильонның тышында баскыч ясалган, дүртпочмаклы баганада утыра. Бу корылма җәмгысы утыз алты баганага таяна. Ул ефәк аркан белән биш йөз ноктадан тарттырылган. Уртада алтын җеп кушып тукылган, бизәкле кызыл келәм җәелгән. Гөмбәз уртасында гаҗәеп бай итеп эшләнгән сурәт – канатларын җыйган дүрт бөркет. Павильон ак, кара, сары бизәкле ефәк тукыма белән тышланган. Һәр почмагында күккә ашкан багана, очында алма сыман җиз шар, шар өстендә урак ай. Шул баганаларга тарттырылып, ефәктән берничә ярусла манара эшләнгән, керепчыгып йөрергә ишеге дә бар. Җил искән чакта кешеләр анда күтәреләләр, күктә очкан шикелле истирахәт чигәләр. Бу павильон шулкадәр зурлыгы, мәһабәтлеге белән замокны хәтерләтә. Аның озынлыгы, биеклеге шаккаткыч, андагы матурлык-

ны тасвирларга сүз җитмәс иде. Павильон эчендә келәмнәр җәелгән, мендәрләр куелган калку урын – бәкнеке, сулдарак тагын шундый ук, әмма тәбәнәгрәк итеп ясалган, аның янәшәсендә тагын да тәбәнәгрәге бар.

Павильонны замокныкы сыман өсте уемлап эшләнгән парчалы дивар каймалап алган. Дивар тыштан да, эчтән дә баулар белән тарттырылып, ефәктән корылган. Эчке якта баганалар да күренә. Атлы җайдак биеклегендәге дивар өч йөз адымнар әйләнәле түгәрәк мәйданны хасил итә.

Мондый диварларны алар сарыпәрдә дип атыйлар. Шул сарыпәрдә эчендә әллә ничә тирмә, чатыр, күтәрмәләр куелган. […] Тирмәләр берсеннән-берсе матур, берсеннән-берсе биек итеп йә ефәктән, йә кызыл келәмнән тышланган. Тәрәзәләренә ефәктән үрелгән рәшәткәләр куелган. Тирмәләрнең берсеннән икенчесенә гөмбәзле ябык аралыклардан күчеп йөрергә мөмкин. Уртада көмеш аеллар белән бизәлгән кызыл төстәге гаҗәеп биек тирмә тора, гөмбәзенең иң очында көмешкә алтын йөгертеп ясалган зур бөркет утыра, ул канатларын җыйган; ә түбәндәрәк, тирмә ишегеннән сажин ярым арырак, шулай ук көмешкә алтын йөгертеп ясалган өч лачын як-якка куелган. Лачыннар, канатларын җәеп, бөркеттән куркып очып китәргә җыенган кебек. Ә бөркетнең карашы шундый: кайсыдыр лачынга ташланырга җыенган шикелле. Бөркет тә, лачыннар да шулкадәр оста эшләнеп мәгънәле куелганнар ки, илаһи камиллек үрнәге шушыдыр диярсең.

Тирмә ишеге төбенә парчалы ефәктән кояш нурлары төшмәскә күтәрмә тарттырылган. Көн дәвамында кояшның торышына карап күтәрмә дә күчереп куела.

Эчендә хисапсыз тирмәләр, чатырлар корылган беренче сарыпәрдә бәкнең өлкән хатыны – Биби ханымныкы иде. Икенче сарыпәрдә икенче хатынына – Кече ханымга карый. Зур мәйданны биләп, бизәлеше белән бер-берсеннән аерылып торган мондый сарыпәрдәләр рәте унбер иде. Болар – Тимербәкнең хатыннары, оныклары җәен дә, кышын да яши торган тирмәләр шәһәрчеге.

Төш турында Тимербәк әлеге сарыпәрдәләрнең берсеннән чыкты, зур павильонга килеп, илчеләрне дә шунда алдырып, мәҗлес уздырды.

Икенче сишәмбедә, 7 ноябрь көнне, урдада Тимербәк тагын зур бәйрәм үткәрде. Мул табыннан соң, ил-йортның югары даирәсеннән – Шаһ Мәлик морза һәм Нуреддин морза Тимербәккә бүләк бирделәр. Бүләк – эченә шикәр, йөзем, миндаль, пестә (фисташка) чикләвеге салынган биек аяклы көмеш касәләр иде. Һәр савытка кызыл тукыма кисәге куелган. Җәмгысы тугыз данә, Тимербәккә шулай тугыз санлы әйбер бүләк итү гадәткә кергән икән. Тимербәк бу затлы бүләкне яраннарына бүлеп бирде, ике савытны, ефәк тукыма белән төрелгәнен, испан илчеләренә тәкъдим итте.

Торып китәргә дип кузгала башлагач, кунаклар өстенә көмеш тәңкәләр сиптеләр, бик нечкәләп эшләнгән, уртасына фирүзә каш куелган көмеш аеллар бирделәр. […]

Пәнҗешәмбе көнне, 9 октябрьдә, Тимербәкнең улы Гыйммраншаһ морзаның хатыны Ханзадә, илчеләрне дә чакыртып, зур бәйрәм үткәрде. Аның гаҗәеп матур бизәкләнгән тирмәләре каршына шәраблы чүлмәкләр куелган иде. Илчеләрне сарыпәрдә эченә алып керделәр. Ханзадә үзе аксөяк хатын-кызлар даирәсе белән күтәрмә астында, келәм, мендәрләр арасында утыра иде. Ул көнне Ханзадә бер туганының туен үткәргән икән. Төскә-биткә ул кырык яшьләр чамасында, ак чырайлы, шактый калын гәүдәле. Каршында шәраблы, ширбәтле кувшиннар тора. Бия сөтенә шикәр кушып эшләнгән эчемлекне алар бик яраталар. Андый эчемлек буза дип атала. Ханзадә янәшәсендә Тимербәкнең ир туганнары да, төрле уен кораллларында уйнап торган музыкантлар да күп иде. ■

Безнең мирас №3 март 2021

КЫПЧАКЛАР НИЧЕК СУГЫШКАН?

Кыпчакларның сугыш тактикасы ничек булган? Алар ничек җиңүгә ирешкән?

Кыпчак кызы яуда.
М.В.Горелик реконструкциясе

Төркиләрнең хәрби сәнгате турында А.Кушкумбаев, Ю.Худяков, Я.Пилипчук кебек галимнәр бары тик яхшы яктан гына саллы хезмәт-ләр язган.

Кыпчак җайдаклары, дошман сафына җитәрәк, түгәрәк буенча хәрәкәт итә. Алар, аны камап-урап ала башлап, өсләренә җәядән ук яудырганнар, дошман белән якынайганнан соң, сөңге, кылыч сугышына күчкәннәр. Аннары, хәйләләп, кире чигенгәннәр, әмма бу сугыш кырыннан качу булмаган.

Кыпчаклар арттан куып баручы дошманны поскынга (засадага) алып кергәннәр һәм, көтмәгәндә һөҗүмгә күчеп, аны төрле яктан камап, чолганышта калдырганнар.

Кыпчаклар психологик моменттан – дошман гаскәрендә барлыкка килгән паникадан бик оста файдаланганнар: артык кан коймый гына, әсирләрне һәм малны кулга төшергәннәр.

Кыпчакларда халык – гаскәр принцибы яшәгән. Ягъни һәр ир – гаскәри, ә аның хатыны, карт ата-анасы, балалары тылы булган. Хәвеф-хәтәр, көтелмәгән һөҗүмнәр була

калса, алар да атка атланып, дошманга ташланырга, кылыч-сөңге сугышына әзер торган. Бу дәүләттәге һәр гаиләгә дә кагылган. Шунлыктан, кыпчак гаскәриләренең саны дошманныкын узып китеп, өч, хәтта биш мәртәбәгә арткан.

Гадәттә, кыпчаклар, көчләр чагыштырмасы үзләре файдасына булмаган очракта, хәлиткеч бәрелешләрдән киң далага җитез генә таралып качканнар. Дошман бер төркемне куып җитеп эзәрлекли алса да, икенчесен, өченчесен киң сахрадан эзләп таба алмаган. Шулай итеп, кыпчаклар мәгънәсез кан түгүдән сакланган.

Кыпчаклар дошман белән сугыш вакытында елганы кичмәскә тырышкан. Алар елга буйларын стратегик сугыш мәйданы итеп сайламаганнар. Елганы кичкән очракта ун ат тиресеннән яссы капчык ясап, аны салам һәм камышлар белән тутырып, бер тамчы да су үтмәслек итеп теккәннәр. Мәгълүм ки, бу эш шактый вакыт таләп иткән.

Яугир суда йөзгән вакытта үзенең барлык әйберләрен дә тиредән ясалган капчык өстенә урнаштырган, аннары үзе утырган. Ә аты, аргы якка йөзгәндә, капчыкны тартып барган.

Кырыс дала шартларында ат өстендә даими күченеп йөрү, әтисе яки бабасы белән ауда, сугышларда катнашу яшь кыпчакны чыныктырган, аннан чын ир-ат ясаган.

Үз кабиләсендәге кызның гаиләсенә калым түләмәс һәм туган-тумача белән кан кушылдырудан саклану өчен, кыпчак, күрше кабиләгә һөҗүм итеп, андагы хатын-кызны әсир итеп алган.

Кыпчак сугышчысы.
М.В.Горелик реконструкциясе

Кыпчакларда кыз урлау йоласының иң борынгы, хәтәр һәм кәттә тактикасы булган. Гадәттә, кыз ягы аны куа килгән. Һөҗүмгә каршы торыр өчен кыпчак егетенең җитез, оста сугышчы булуы соралган. Югыйсә ул кызга лаек саналмаган!

Кыпчакларның таулы урыннарда сугышу, камалышта калдыру осталыклары булмаган. Шунлыктан алар мондый сугышларда утрак тормышлы халыкларның гаскәрләре белән берлектә генә катнашкан.

Текстны журналга
Ленар Гобәйдуллин *әзерләде.* ■

Безнең мирас №3 март 2021

Кемнәр алар типтәрләр?

Айрат Чанышев

Типтәр авылы

Татарларның типтәр исемле зур гына бер төркеме бар. Типтәрләр патша Россиясендә, башкортлар кебек үк, аерым бер сословие тәшкил иткәннәр, тик, башкортлардан аермалы буларак, аларның салымнары күбрәк булган. Типтәр сословиесендә марилар да, чуашлар да бар. Хәзерге вакытта Уфа галимнәре типтәрләрне Идел-Урал татарларына бернинди дә катнашы булмаган, башкортларга якын торган аерым бер төрки этник төркем итеп күрсәтергә тырышалар (мәсәлән, Б.Г.Әхмәтшин). Әмма типтәрләр – саф татарлар, Казан ханлыгы татарлары, аларның башкортларга һ.б. халыкларга бернинди катнашы да юк.

Иң башта шунысын әйтеп китәргә кирәк: хәзерге Башкортстанның көнбатышы – Уралга кадәрге өлеше Казан ханлыгы составында булган. Ул Казан ханлыгының Агыйдел олысы (Беловолжский улус) дип йөртелгән, ә Урал һәм Урал арты – Нугай Урдасы карамагында, өлешчә Себер ханлыгында. Казан яулап алынгач, Мәскәү хакимияте Чулманга кадәрге җирләрдә үз хакимлеген урнаштыра. Ханлыкның Чулманнан көнчыгыштагы җирләре исә Нугай Урдасында кала. Басып алынган биләмәләрдә Мәскәү хакимияте җирле халыкны изү, көчләп чукындыру сәясәте алып бара. Шуның нәтиҗәсендә, әлеге җирләрдән татарлар күпләп көнчыгышка күченә башлый. Алар көчләп чукындыруга каршы чыгып, Агыйдел олысы җирләрендә нигез кора һәм үзләрен типтәрләр дип йөртә. Бу мәкаләдә типтәрләрнең ни өчен үзләрен алай дип атауларын аңлатырбыз.

«Дәфтәр ясагы»н түләдеңме?

«Типтәр» сүзенең килеп чыгуын Гайнетдин Әхмәров, П.И.Рычков һәм В.Н.Витебскийларның хезмәтләреннән файдаланып, фарсы телендәге дәфтәр, исем-

лек, реестр мәгънәсендә йөргән «дәфтәр» сүзеннән барлыкка килгән дип аңлата. Тик монда бераз төгәллек кертергә кирәк. Иң беренче «дәфтәр» сүзенең таралыш алуына тукталып китик. Кемдер, нишләптер, аны фарсы сүзе дип игълан иткән дә, фарсылардан бу сүз башка телләргә (нигездә, төрки телләргә) таралган икән, имеш. Ә ни өчен киресенчә түгел? «Дәфтәр» сүзе төрки телләрдә генә түгел, ә алтай халыкларының барлык телләрендә дә диярлек бик борынгыдан ук бар. Сүз ахырындагы «әр» сүзьясагыч кушымчасы да төрки телләр өчен хас күренеш. «Дәфтәр» сүзе Йосыф Баласагуниның 1170 елда төрки телдә язылган атаклы «Котадгу белег» хезмәтендә дә очрый. Танылган галим В.В.Бартольдның әйтүенчә, төрки-татар һәм монголларда бу сүз «исемлек, канун, кагыйдә» мәгънәләрендә булган. Р.Әхмәтҗанов фикеренчә, уйгырларда «дәбтәр» сүзе салым түләүчеләрнең исемлеген, хөкем карарларын яза торган дәфтәрне белдергән. Чыңгыз хан турында монгол телендәге иң борынгы чыганак «Алтан дептер» дип атала. Аны бернинди фарсы кешесе дә язмаган, текст татарчага тәрҗемә итүне дә таләп итми. Димәк, бердәнбер һәм дөрес аңлатма: XIII гасырда ук Чыңгыз хан империясендә «дәфтәр» салым түләүчеләрнең исемлеген, түләү тәртибен исәпкә алып бара торган кенәгә булган. Алтын Урда татарлары да үзләренең салым кенәгәләрен «дәфтәр» дип атап йөрткән.

Петр Iгә кадәрге Мәскәүдә барлык дәүләт институтлары да: салым (ясак, тамга җыены – таможня һ.б.); финанс (тәңкә – деньги һ.б.); ил белән идарә итү (рус патшасының чиксез хакимлеге – Алтын Урда ханының чиксез вәкаләте, даруга – губерна, вулыс – волость, Диван – Боярлар Думасы, корылтай – собор һ.б.); хакимлек регалийлары (Кремль, ике башлы каракош – Алтын Урда ханнары тамгасы, буздыхан-скипетр, хакимлек билгесе сагайдак – сайдак, саадак, сагайдак, Үзбәк хан бүләк итеп биргән Мономах бүреге һ.б); гаскәр төзелеше һәм башкалар – болар барысы да татарлардан, Алтын Урдадан. Алтын Урда дәүләт системасын дәвам итүче, аның затлы мирасына дәгъва кылучы Мәскәүдә дә салымнарны «дәфтәр»ләргә теркәп барганнар. Бу рус теленә аерым бер сүз – «девтер», «дефтер» булып кереп калган. М.Фасмерның этимологик сүзлегендә «дефтер», «девтер» – «салым грамотасы, салым хисабы кенәгәсе» дип аңлатылган. В.И.Дальның аңлатмалы сүзлегендә дә «дефтер», «девтер» шундый ук мәгънәдәге татар сүзе дип күрсәтелгән. Шулай итеп, рус дәүләтендә барлык салым кенәгәләре дә «дәфтәр» дип аталган. Типтәрләргә аерым бер салым кенәгәсе ачкан очракта да, аннан типтәр сүзе килеп чыккан дип раслау бернигә дә нигезләнмәгән.

Казан ханлыгының Агыйдел олысы һәм Нугай Урдасы җирләренә күчеп килүчеләрнең саны арткач, патша хөкүмәте аларны санарга һәм салым салырга ниятли. Моның өчен Сенат 1734 елда махсус карар кабул итә. Шул күрсәтмәне үтәп, типтәрләрне, ялгызакларны (бобыльләрне) ачыклап, аерым кенәгәләргә терки башлыйлар. Димәк, рәсми рәвештә типтәр һәм ялгызакларның салым кенәгәсе бары тик 1734 елда гына гамәлгә керә. Әмма типтәр атамасы аңа кадәр, XVI гасырның икенче яртысыннан ук билгеле. (Миллер К.В. «Описание всех в Российском государстве обитающих народов..» Ч.1. О народах финского племени. – С-П, 1776.)

XVI гасыр документларында очраган «дәфтәр ясагы» сүзен типтәрләр ясагы булган дип раслау да дөреслеккә туры килми. «Дәфтәр ясагы түләде» гыйбарәсе, «салым кенәгәсенә теркәлгән, ясакны түләде» дигәнне аңлаткан. Чөнки ул вакытларда салым кенәгәләре «дәфтәр» дип аталганлыктан, барысы да «дәфтәр ясагы» түләгәннәр. Мәсәлән, Якшиван авылы «башкорт»ы үтенечендә: «Мин Уфада елына бер сусардан торган дәфтәр ясагы түләдем», – дип язган (БДҮДА, 1173 ф.,

1 тасв., 1198 сакл. бер., 3 б.). Димәк, бу вакытта Якшиван авылы «башкорт»ының ниндидер аерым бер типтәр салымы түләве турында сүз бармый, ә бары тик салым кенәгәсендә (дәфтәрдә) күрсәтелгән салымны түләве хакында гына әйтелә. Шуңа күрә дә типтәр атамасының «дәфтәр» сүзеннән барлыкка килүе турындагы раслаулар бернинди тәнкыйтьне дә күтәрә алмый.

Типтәр тибелгәнме?

Хәзерге көнчыгыш Татарстан һәм көнбатыш Башкортстанда яшәгән типтәрләрнең тарихи үзаңы җуелган, алар үзләрен гомуми татарлардан аермыйлар һәм типтәр сүзенең каян килеп чыгуын хәтерләмиләр.

Урал һәм Урал арты башкортлары, «көнбатыш башкортлары»ннан аермалы буларак, үзләрен «чын башкортлар» («ысын башкорттар») дип исәплиләр. Менә шул «чын башкортлар» арасында яшәгән типтәрләрнең тарихи үзаңнары көчлерәк. Ул якларда борын-борыннан типтәр белән «башкорт» арасында үзара кытыршылыклар, кырын караулар булган. Бу каршылыклар, нигездә, җир биләү мәсьәләсен хәл иткән вакытта килеп чыккан. Башкортларның җирләре күп булган, аны эшкәртмәгәннәр, күчмә һәм ярымкүчмә тормыш алып барганнар. Бик җиңел һәм юк кына хакка күп җирләрне сатып та бетергәннәр. Типтәрләр һәм татарларның исә җирләре аз булган, алар игенчелек, һөнәрчелек, сәүдә белән шөгыльләнгәннәр, башкортлар белән чагыштырганда, шактый кысанрак шартларда тормыш алып барсалар да, алардан күпкә яхшырак һәм иркенрәк яшәгәннәр, мәчетләр, мәдрәсәләр тотканнар, башкортлар арасында аң-белем, мәдәният таратканнар. Башкортларның типтәрләр һәм татарлар белән судлашып, дәгъвалашып йөргән очраклары күп санда теркәлгән. Хәер, мондый каршылыклар республиканың көнбатышында да булган. Кайвакыт бер үк татар авылының ике очы ике төрле аталып йөртелгән: «Татар (типтәр) очы» һәм «Башкорт очы». Әлбәттә, бу вакытта ул башкорт милләтен түгел, ә бары тик аларның башкорт сословиесендә булуын, күбрәк җирләргә, болынлыкларга, печәнлекләргә, көтүлекләргә ия булуларын, салым ташламаларыннан файдалануларын гына аңлаткан. Башкорт сословиесенең өстенлекле шартлары аркасында бер үк авылның «Башкорт очы» һәм «Татар очы» үзара дошманлашып, судлашып, дәгъвалашып яшәргә мәҗбүр булган. Дәүләкән, Аскын, Ярмәкәй, Бәләбәй кебек «көнбатыш башкортлары»на «чын башкортлар» өстән аска караган кебек карыйлар, аларны «чын башкорт»ларга санамыйлар, ә «кәгазь башкортлар» дип исәплиләр.

Типтәрләрне «чын башкортлар», тибелгән, тибәрелгән, илләреннән куылган, җирсез-йортсыз, сукбай мәгънә төсмере биреп, «типук» диләр. Ә типтәр сүзен шулай ук туган якларыннан тибелгәннәр, тибәрелгәннәр сүзеннән барлыкка килгән дип күрсәтергә тырышалар. Типтәрләрне шулай түбәнсетергә-кимсетергә омтылу татар авылларының яртысын диярлек башкорт итеп язган Ә.З.Әсфәндияров һәм башка Уфа галимнәре хезмәтләренә дә килеп кергән. Ә.З.Әсфәндияров, үзенең «История сел и деревень Башкортостана», «Аулы мензелинских башкир» хезмәтләрендә, мәсәлән, Уфада саклanучы V ревизия материалларына гына таянып, ул вакытта башкорт сословиесендә торган бар татарларны да этник башкортлар итеп күрсәтә. Моның тулы сафсата булуын раслау өчен, шундый бер-ике фактны күрсәтеп китү дә җитә: Россия ревизияләрендә халыкның этник составын ачыклау максат итеп куелмаган. Аларда исәпкә алынучылар үзләренең нинди салым түләве буенча гына теркәлгәннәр. Исәпкә алынучы кеше йомышлы, ясаклы татар салымнары түлиме, әллә инде типтәр салымымы, бобыль салымымы, ташламалы башкорт салымы-

Типтәр балыкчысы

мы? Ә башкорт салымының җиңел булуы аркасында бик күп татарлар башкорт сословиесенә язылганнар һәм бер татарлар гына да түгел, күп кенә мари, чуаш, удмуртлар да. Алдагы ревизияләрдә башкорт сословиесендәгеләрнең саны күпкә аз, мәсәлән, Әсфәндияров яртысыннан артыгы башкортлар итеп күрсәтүче Минзәлә өязендә XVIII гасыр башында бер генә башкорт та теркәлмәгән диярлек. Өязнең «башкортлыгы» турында бары тик 1795 елда үткәрелгән V ревизиядән соң гына сөйли башларга була. Ул ревизия вакытында өяз халкы башкортларының саны 19,2 процентка җиткән (Рим Янгуҗин «Башкорт ырыузары», 14 бит). Минзәлә өязенең III ревизия вакытындагы саф татар авыллары V ревизиядә инде, ниндидер бер могҗиза белән, «башкорт авыллары» булып киткән. Уфа галимнәре саф башкорт авылы итеп күрсәткән Актаныш авылы, мәсәлән, III ревизия буенча (IV ревизия материаллары сакланмаган, бәлки, ул үткәрелмәгәндер, җирле халык әлеге ревизияләргә каты каршылык күрсәткән) – татар авылы, ә 1795 елгы V ревизия вакытында шул ук фамилияле кешеләр, бер үк ата-бабаларның балалары булсалар да, «башкортлар» булып яшиләр икән!

«Чын башкортлар» каршында типтәрләр дә җавапсыз калмый. Алар, үз чиратында, «чын башкортлар»га: «Сез – Мәскәү ялчылары, Мәскәүгә сатылгансыз да, шуңа да сезгә күп җирләр биргәннәр, салымнардан азат иткәннәр, сез казакъларга, Урта Азия төркиләренә Мәскәү белән бергә яу чапкансыз, аларны кыргансыз, талагансыз, кол иткәнсез, татар восстаниеләрен канга батырып бастыргансыз, Оренбург каратель отрядлары составында, патша гаскәрләре ярдәмендә нугай татарларын үз илләреннән куып җибәргәнсез дә аларның җирләрен тартып алгансыз, ә аннан соң бушка килгән бар татар җирләрен дә сатып-эчеп бетергәнсез», – дип җавап бирәләр. Чынлап та, Урал арты халкы башкорт сословиесенә күчкәч, алар патша Россиясенә тугры хезмәт иткән. Ул вакытларда алар әлегә Россиягә кушылмаган кыргыз-кайсакларны (казахларны) туктаусыз һөҗүмнәре белән гел борчып торганнар, Урта Азия ханлык һәм әмирлекләрен яулап алган вакытта да зур гына көч булганнар. Ул гына да түгел, башкорт сословиесендәгеләр татар восстаниеләрен

бастыруда да актив катнашкан, яуда батырлыклар күрсәткән. Шул хезмәтләре өчен аларны «тугры башкортлар» дип атап йөрткәннәр.

«Тугры башкортлар»ның татар восстаниеләрен бастыруда катнашуын күрсәтү өчен, мисал итеп, 1734 елны оештырылган Оренбург экспедициясе (комиссиясе) һәм 1735 елны оештырылган Башкорт эшләре комиссиясе хезмәтен китерергә була. Башкорт эшләре комиссиясе башланып киткән восстаниеләрне бастыру өчен махсус төзелә. Ә Оренбург комиссиясе кыргыз-кайсак далаларын өйрәнү, анда сәүдә һәм башка төрле эшләр оештыру, кирмәннәр төзү өчен булдырыла. Тик бу комиссиягә дә, үз эшен башкарасы урынга, шул вакыттагы татар восстаниеләрен бастыру белән шөгыльләнергә туры килә. Җәза гаскәрләренең составы еш кына яртылаш диярлек «тугры башкортлар»дан торган. Мәсәлән, «Татар Уян» сайтында китерелгән мәгълүмат буенча, Башкорт эшләре комиссиясе җәза отрядларының составында регуляр гаскәрләр – 4467 кеше, «тугры башкортлар» – 4455 кеше, казаклар, крестьяннар ополчениесе һ.б. – 2315 кеше, барлыгы 11 237 кеше тәшкил иткән.

Яртылаш диярлек «тугры башкортлар»дан торган җәза отрядларының аяусызлыгы күпләргә мәгълүм. Уфа губернасының Балыкчы волостендагы Сөянтуз исемле татар авылы фаҗигасе үзе генә дә ни тора! Җәза отрядлары бу татар авылы халкын тулысынча кырып бетергән. Әлеге явызлык турында П.И.Рычков менә ниләр язып калдырган: «Близ тысячи человек с женами и с детьми их во оной деревне перестреляно, и от драгун штыками, а от верных башкирцев и мещеряков копьями переколото. Сверх того, сто пять человек забраны были в один амбар и тут огнем сожжены. ...И таким образом, вся деревни Сеянтус жители с их женами и с детьми от мала до велика чрез одну ночь огнем и оружием погублены, а жилища их в пепел обращено». Кызганыч, хәзерге көндә Уфаның милли активистлары, ул авыл халкының бер өлеше башкорт сословиесенә язылган булу аркасында, яртылаш диярлек «тугры башкортлар»дан торган җәза отрядларының татар авылын юкка чыгаруын патша хөкүмәтенең «башкортларны кыруы», «башкорт геноциды» итеп күрсәтеп, «фәнни хезмәтләр» язып, ялган кинофильмнар төшереп яталар.

Типтәрләр: «Без тәрегә типкәннәр!»

Нәкъ менә шул «чын башкортлар» арасында яшәгән типтәрләрдә «типтәр» сүзенең килеп чыгышы сакланып калган. Урал арты типтәрләре, үзләрен исә, башкортлардан аермалы буларак, сатылмаган, чын, асыл татарлар дип исәпли. Урал артындагы теләсә кайсы типтәр авылының теләсә кайсы типтәреннән, һәрхәлдә, аларның урта буын вәкилләреннән һәм өлкәннәреннән: «Типтәр сүзе каян килеп чыккан?» – дип сорасаң, ул: «Тип тәресен миссионерның!» сүзеннән килеп чыккан атама ул», – дип аңлатачак. «Без динебезне сатмадык, без – безне чукындырырга килгән миссионерларның тәресенә типкән чын татарлар!» – дип тә өстәп әйтәчәк әле алар.

Чынлап та, Мәскәү кулы астында калган җирләрдә, аеруча XVIII гасыр башыннан башлап массакүләм көчләп чукындыру сәясәте башланып китә, чукынмаганнарга күпләп салымнар салалар. Мәсәлән, чукынган татарлар салымнан азат ителеп, аларның салымнары чукынмаган татарларга өстәлә. Чукынмаган татарлар үзләре өчен дә, татарлар өчен дә салым түләргә мәҗбүр була. Аларны төрле җәзаларга тарталар, чукынмаган татар морзаларының мал-мөлкәтләрен тартып алалар һ.б. Нәкъ менә шул кысулардан, эзәрлекләүләрдән, көчләп чукындырулардан татарлар, үзләре әйткәнчә, «мисссионерларның тәресенә тибеп», Алтын Урдадан мирас булып калган Нугай Урдасы җирләренә күченгән.

Татар Башкортстанда килмешәк түгел

Типтәрләр бернинди дә башка халыкларның ил-җирләренә күченмәгән. Алар бу җирләрдә, Идел-Урал төбәгендә бик борынгыдан, Кимәк каһанлыгы заманнарыннан ук, VII гасырдан яшәгән. Ерак бабалары аннан да алдарак, һун чорында ук җир-су биләгән, мал-мөлкәткә хуҗа булган. Чөнки Идел-Уралга болгарлар килгәнче үк, анда төрки-татарлар яшәгәнлеге билгеле. Төрле сәбәп белән Нугай Урдасы җирләренә күченгәннәре дә шул ук Алтын Урда кыпчак-татарлары җирләренә килеп төпләнгәннәр. Татар халкының килеп чыгышында бер болгар компоненты гына түгел, хәзәр-мишәр-мещера, төрки, кимәк каһанлыгы татарлары һәм, аеруча, саллы гына кыпчак компоненты (бигрәк тә Нугай Урдасы татарлары) да бар. Бәлки, кыпчак компоненты барысыннан күбрәктәдер әле.

Ә менә башкорт тарих концепциясенең атасы Р.Кузеевның версиясе буенча, башкортларның иң беренче 3 кабиләсе Идел-Уралга нибары IX гасыр ахырында гына күчеп килгән, элегрәк Урта Азиядә, Арал һәм Сыр-Дәрья буендагы далаларда, бәҗәнәкләр арасында яшәгән. Әйтергә кирәк, алар үзләренең башкорт икәннәрен дә белмәгән, һәр ыру-кабилә үз исеме белән йөртелгән. Кузеев аларны протобашкирлар дип атый. Аннан соң Алтын Урда чорында шул өч «иң беренче», «иң чын» «башкорт ырулары»на дистәләп кыпчак-нугай, татар-монгол һәм болгар ырулары килеп кушылган. Ул гына да түгел, берничә фин-угыр кабиләсе дә башкорт булып киткән икән. Кузеев кулланган «болгар башкортлары ырулары» хәзерге Башкортстанның Уралга кадәрге халкының күп өлешен тәшкил итәләр. Дөресен генә әйткәндә, алар шул ук Казан ханлыгы, аның Агыйдел олысының (Беловолжский улус) җирле татарлары. Кузеев язган «башкорт ырулары» бернинди чыганакларда да искә алынмый. Алар барысы да Уфа губернасында һәм аңа күрше кайбер башка губерналарда патша Россиясе заманында булган административ-территориаль бүленешләрдәге волость атамалары гына, шундагы тау, калкулык исемнәре. «Башкорт ырулары» дип күрсәтелүче ырулар арасында чынлап та тарихта булганнары бар, тик алар, нигездә, Көньяк Уралда һәм Урал артында яшиләр. Күп очракта болар табын, барын, катай, кувакан дип аталган борынгы татар-монгол ырулары.

Кузеевның бу версиясе буенча, башкортлар (Урта Азиядән килгән «чын башкортлар») бер стакан судагы тамчы кебек кенә булып кала. Калганнары исә Идел буе Болгар дәүләте болгарлары – Казан ханлыгы татарлары, кыпчак-нугайлар – Алтын Урда татарлары, монгол-татарлар йә «башкортлашкан» (чынлыкта татарлашкан) фин-угырлар – истәкләр.

Ә Урал арты халкының (алар, нигездә, инде алда әйтеп кителгәнчә, табын, барын, катай, кувакан кебек монгол-татар ырулары) бу җирләрдә утрак тормыш белән төпләнүе XVIII гасырда гына булган. Алар элек Урал арты, Көнбатыш Себер, Көнбатыш Казакъстан далалары буенча күчеп йөргәннәр, Оренбург төзелеп, Урал арты җирләре Россиягә кушылгач кына үзләрен конкрет бер урын белән бәйли башлаганнар. Ә бу вакыйгалар типтәрләрнең бабалары Идел-Уралда яши башлавыннан соң меңъ ел үткәч кенә булган.

***

Шулай итеп, типтәрләр бернинди дә дәфтәрләр дә, тибелгән-тибәрелгәннәр дә түгел, ә чын татарлар, асыл татарлар, баш имәгән, баш бирмәгән татарлар! Алар үзләрен типтәрләр – «Без тәрегә типкәннәр!» дип атаганнар. Татар халкының ата-бабалары Идел-Урал төбәгендә «чын башкортлар»дан бик күпкә элегрәк яши башлаган. ■

Башкорт-мещеряк гаскәрендә татарлар

Рөстәм Әминев

Уңда – 3 нче мещеряк кантоны татары. 1845 ел

XVII гасырда мишәр татарларының Урал буена күченү ташкыны көчәя. Хөкүмәтнең йомышлы татар һәм мещерякларга карата сәясәте шактый каршылыклы була. Аерым алганда, мещерякларны салым түләүчеләр сословиесенә күчерү процессы башлана. Чукынырга теләмәү һәм салымнар арту сәбәпле, алар XVII-XVIII гасырлар дәвамында яңа җирләргә күчеп китәргә мәҗбүр ителә. Бу чорда хәзерге Башкортстан территориясе иркен, анда шактый гына буш җирләр була. Күчеп йөрергә сәләтле һәм дәүләт чиген саклау хезмәтендә тәҗрибәсе булган мишәрләр яңа җирдә уңышлы гына төпләнеп яши башлый. Күп очракта мишәр татарлары мещеряк катлавына кергән, шул ук вакытта аларның бер өлеше башкорт сословиесенә дә язылган.

Татарлар – дәүләт чиге сагында

1742 елда Оренбург комиссиясе начальнигы И.И.Неплюев мещерякларны башкортлар белән бергә чик буенда хезмәт итәргә билгели. Мещерякларның (әлбәттә, аларның күбесе мишәр татарлары), шулай ук Оренбург, Урал казакълары һәм башкортларының (алар арасында татарлар да күп) хезмәтен сөргенгә җибәрелүчеләрне озатканда, төбәктәге тәртипне саклаганда файдаланганнар.

1748 елдан башлап, Оренбург губернаторы Неплюев билгеләгән штат буенча, чик буен саклау хезмәтендәге регуляр булмаган гаскәр (казакъ, башкорт, мещеряк һәм калмыклар) 10 800 кеше тәшкил иткән. Шуларның 5700е (48 процент) башкорт һәм мещеряк сословиесеннән. Ә 1786 елда 11 523 кешедән 7447е, ягъни 64,7 проценты башкорт-мещеряк булган.

Социаль-хокукый яктан башкорт һәм мещерякларның охшашлыклары шактый. Мәсәлән, үз хезмәтләре өчен алар ай саен 1 сум акчалата хезмәт хакы алган. Әмма бер шарт үтәлергә тиеш: аларның авылы белән хезмәт итү урыны арасындагы ераклык 100 чакрымнан артык булсын. Мещерякларны дәүләт чиге иминлеген саклауда файдалану ил өчен шактый отышлы проект була, чөнки матди чыгымнарның барысы да диярлек халыкның үз өстенә салынган.

Урал буе төбәге, күрше Идел буе районыннан аермалы буларак, куркынычсызлык мәсьәләсендә шактый тотрыксыз вазгыяте белән аерылып торган. Чөнки бу тирәдәге авыллар еш кына кыргыз-кайсаклар тарафынннан зыян күргән: алар җирле халыкның терлекләрен урлаган, кешеләрне әсирлеккә алган.

Мещеряк-мишәр кантоннары

1798 елда төбәктә кантон идарә системасы кертелә. Нәтиҗәдә, 11 башкорт, 5 мещеряк, 2 урал казаклары, 5 Оренбург солдаты кантоннары оештырыла. Моннан тыш, Ставрополь калмык гаскәре аерым бер кантонга туплана. Бу чор өчен кантон системасы яңалык түгел. Ул хәрби-феодаль режим хөкем сөргән күп кенә дәүләтләрдә, мәсәлән, Австро-Венгрия һәм Пруссиядә гамәлгә кертелә.

Восстаниеләрне кисәтү, чик буе биләмәләрендәге вазгыятьнең тотрыклылыгын тәэмин итү, Урта Азияне яулап алу өчен терәк-җирлек булдыру да әлеге реформаның төп максатларыннан булган. Кантон системасының тагын бер уңай ягы – анда яшәүчеләр өчен дәүләт йөкләмәләрен үтәүнең катгый регламенты һәм админстратив контроль кертү.

Мишәр татарлары территориаль принцип буенча бүленгән биш мещеряк кантонына урнаша. Аерым алганда, 1 нче мещеряк кантоны Троицк һәм Чиләбе өязләре авылларын үз эченә алган. 2 нче кантонга – Бөре һәм Минзәлә өязләрендәге торак пунктлар, 3 нче кантонга – Стәрлетамак өязе, 4 нче кантонга – Уфа өязе, 5 нче кантонга Бөгелмә өязе мещеряклары кергән.

Мишәр татарлары башкорт кантоннарындагы өязләрдә дә яшәгән. Башкорт кантоннарында башка мөселманнар да – татар, нугай, кыргыз-кайсак һәм башкортлар бергә тупланган. Һәр кантонның җитәкчесе булган. Мәсәлән, 1 нче мещеряк кантонында бу вазыйфага – юрт старшинасы Мәхмүтов, аның ярдәмчесе итеп юрт старшинасы Бектимеров билгеләнгән; 2 нче кантон белән юрт старшинасы Мәкъсүтов, аның ярдәмчесе старшина Мендиев; 3 нче кантон белән юрт старшинасы подпоручик Солтанморатов, ярдәмчесе поход старшинасы Габдессәләмов; 4 нче кантон белән юрт старшинасы Мәүлетов, аның ярдәмчесе Тимербаев идарә иткән.

2 нче һәм 4 нче кантонның мещеряклары, башка кантоннарның мещерякларыннан аермалы буларак, Себер чик буе хезмәтенә кирәк булган. Аларның хезмәте ике чорга – җәйге (16 майдан 16 ноябрьгә кадәр) һәм кышкы айларга (ноябрь уртасыннан майга кадәр) бүленгән. Җәйге чор белән чагыштырганда, кышын хезмәткә чакырылучы кешеләрнең саны икеләтә кимрәк икәнлеген күрербез. Уртача һәр форпостка 2-3 казак, 10-12 башкорт һәм мещеряк билгеләнгән. Хезмәткә килүче үзе белән кылыч, сөңге, чәнечкеле лат алырга, социаль хәленнән чыгып, утлы корал, төгәлрәге, ике пистолет һәм мылтык белән коралланырга тиеш була.

«Яуның тышында булма, эчендә бул»

XIX гасыр башында Россия империясе дөньяның төрле державалары белән күпсанлы сугышлар алып бара. Аеруча 1812 елгы Ватан сугышын һәм 1813-1815 нче еллардагы чик буе походларын онытырга ярамый. Билгеле булганча, бу сугышларда катнашу өчен мещеряклардан ике полк формалаша. Мәсәлән, 1 нче мещеряк полкы Мәскәүгә җибәрелгән һәм анда 1812 елның ноябреннән 1814 елга кадәр гарнизон хезмәтен башкарган. Мещеряклардан төзелгән икенче полк Польша армиясе составында хезмәт иткән. Аның төп бурычы армияне батырларча саклау һәм төнге каравылда тору була.

Моннан тыш, мещеряклар 1828-1829 нчы елларда – Рус-төрек сугышында, 1839-1840 нчы еллардагы Һива походында, 1852-1853 нче еллардагы Коканд походларында, 1853-1856 нчы еллардагы Кырым сугышларында катнашкан. Алда искә алынган хәрби кампанияләрдә мещеряклар үзләренең дин кардәшләре булган мөселманнарга каршы кылычка-кылыч сугышырга мәҗбүр була.

Кантоннардагы үзгәрешләр

1819 елда биш мещеряк кантонында 29 279 ир-ат яшәгән. Кеше саны буенча иң зурысы 3 нче кантон булган. Ул Оренбург губернасындагы Уфа, Пермь губернасындагы Пермь, Красноуфим өязләрен үз эченә алган. Аннан кала, 5 нче кантон – Бәләбәй өязе, 4 нче кантон – Бөре өязе, 2 нче кантон Стәрлетамак өязе булган. Иң кечкенәсе – 1 нче кантон. Аның составына Оренбург губернасының Чиләбе, Троицк һәм Верхнеуральск өязе мещеряклары кергән. 1847 елда, кечкенә булу сәбәпле, 1 нче кантон бетерелә. 1859 елгы халык санын алу материалларын карасак, калган дүрт мещеряк кантонында барлыгы 86 мең ир-ат һәм хатын-кыз яши.

Бер мещеряк полкы штатына, биш йөз кешелек хәрби мещеряктан тыш, полк командиры, старшина, есаул (5 кеше), йөзбашы, полк квартирмейстеры (6 кеше), хорунжий, полк адъютанты (6 кеше), өлкән урядник (5 кеше), кече урядник (15 кеше), полк мулласы (1 кеше), өлкән писарь (1 кеше), кече писарь (2 кеше), полк коновалы – ветеринар (1 кеше), фурлейт (11 кеше) кергән. Гомумән алганда, бер штаттагы барлык хәрбиләр саны 555 кеше тәшкил иткән.

Мишәр татарлары бер-берсеннән үзләренең социаль-хокукый хәлләре белән дә аерылган. Хәрби казанышлар һәм озак еллар хезмәт иткән өчен, аларга офицер чины бирелгән. Зауряд-офицер исемен йөртү шактый мактаулы булган. Алар җәмгыятьнең югары катлавын тәшкил иткән, салымнардан, тән җәзаларыннан азат ителгән. Оренбургның Неплюев кадет корпусында белем алган хәрбиләр дә дәрәҗәлеләрдән саналган. Бу уку йорты башкорт-мещеряк гаскәрен югары хәрби әзерлекле кадрлар белән тулысынча диярлек тәэмин итеп торган. Биредә татар теле һәм әдәбиятының да фән буларак укытылуы билгеле. Бу булачак хәрбиләргә җирле халыкның телен һәм гореф-гадәтләрен тирәнрәк белү өчен кирәк булган.

Терлекчелек белән шөгыльләнгән һәм хәрби хезмәт башкарган һәр ир-ат мещерякка 1832 елга кадәр 30 дисәтинә җир бирелгән. Бу төбәкнең башка социаль төркемнәре белән чагыштырганда шактый зур милек. Әмма хәрби хезмәт сословиесендә булу аларның иреген чикләгән: старшинадан рөхсәт алмыйча авылдан чыгу катгый тыелган, ә губерна территориясенә чыгу кантон начальнигы рөхсәте белән генә яраган. Мишәр иренең шактый гомере туганнар, бала-чага һәм якыннардан еракта, чик буенда узган. Шунысы кы-

Башкортстанның Благовар районындагы Өйдрәкбаш авылы. Бу авыл да кайчандыр мещеряк кантонына караган. Анда патша армиясенең генерал-лейтенанты Хаҗиәхмәт Ишбулатов (1851-1921) һәм әдәбият галиме, язучы Галимҗан Нигъмәти (1892-1937) туган.

зык: мещеряклар, кагыйдә буларак, кәләшне үз тирәлегеннән алган. Хакимият аларның башкорт белән никахларын хупламаган, чөнки бу җир милеген мирас итеп калдырганда һәм бүлгәндә проблема тудырган.

Кантон системасының бетерелүе

Россия дәүләте елдан-ел киңәйгән, чик буендагы позицияләрен ныгыткан. Шулай итеп, XIX гасырның 40 нчы еллар азагында элекке чик буе хезмәтенә нибары 14 процент башкорт һәм мещеряк кирәк булган. Шул сәбәпле алар башка эшләргә җәлеп ителгән. Мещерякларга төзелеш ташы вату, урман кисү, почта һәм сәүдә трактларын салу эшләре, төрмәләрне төзекләндерү, почта хезмәтләрен, земство полициясен тәэмин итү кебек хезмәтләр йөкләнә.

Соңрак, 1855 елның 31 октябрендә башкорт-мещеряк гаскәре үзенең исемен үзгәртә һәм «башкорт гаскәре» дип атала башлый. Гаскәрнең халкын мещеряк, типтәр һәм ялгызаклардан (бобыль) торган башкортлар тәшкил итә.

1860 нчы еллар башында кантон системасы бетерелә. 1863 елның 14 маендагы «Башкортлар турында положение» буенча мещеряк, типтәр һәм башкортларга ирекле яшәргә, күчеп йөрергә рөхсәт ителә, хәрби режим йомшый. 1865 елның 2 июлендә башкорт гаскәре һәм хәрби-административ система да бетерелә. Халык белән идарә итү функцияләре өяз органнарына бүлеп бирелә. Кантон системасы юкка чыкканнан соң да мещеряклар үзләренең 30 дисәтинә җирләрен саклап калалар. Алда әйткәнебезчә, бу сан төбәктәге башка сословие төркемнәре биләгән җирдән ике мәртәбә күбрәк. Шулай итеп, аларга игенчелек белән уңышлы гына шөгыльләнергә мөмкинлек туа. Күбесе туган авылларына, гаиләләре янына кайта, сәүдә белән шөгыльләнә башлый. ■

Безнең мирас №3 март 2021

Кама аръягы төбәге татарлары тарихыннан

Нәкыйп Гафиятов

Хәрби ныгытма

Кама аръягы төбәге тарихи үзенчәлекләре буенча икегә аерыла:
1) ***Көнбатыш ягы*** *– Казан губернасына караган Чистай һәм Спас өязләре;*
2) ***Көнчыгыш ягы*** *– Оренбург губернасы төзелгәч, аңа кергән Минзәлә, Бөгелмә, Бөре, Уфа һәм Стәрлетамак өязләре.*

КӨНБАТЫШ ЯГЫ

Идел һәм Кама елгаларының сул ягында колонизация XVII гасыр уртасында башлана. Шулай итеп, Кама аръягы төбәге этник яктан зур үзгәрешләр кичерә. «Список населенных мест Казанской губернии 1866 г.» исемле китапта: *«Руслар, бу якларга басып алучылар булып килгәнгә, иң яхшы, уңайлы һәм файдалы җирләрне*

үзләренә алырга тиеш. Казанны алганнан соң, татарларны көнчыгышка кысырыкларга кирәк иде. Татарлар үзләре дә көнчыгышка, үзләренең туганнары янына күченү файдалырак икәнен аңлады. Татарлар калдырып киткән җирләргә руслар килеп урнашты. Кама аръягында рус элементы тиз артты. Шул сәбәпле, русларның бу җирләрне колонизацияләве көчәйгәннән-көчәя бара», – диелгән. Нугай Урдасы татарлары русларның бу җирләрне үзләштерүенә каршы тора алмый.

Кама аръягының төп халкы – татарлар. Бу – элекке Нугай Урдасы татарларының нәсел биләмәләре. Җирнең төп хуҗалары – мангыт нәселләреннән булган ыруглар. Казан яулап алынганнан соң, ханлык тарафыннан күченеп килгән татарлар белән Нугай Урдасы татарлары бербөтен татар халкына әверелә башлый.

1651 елдан, Алексей Михайлович указы белән, Нугай Урдасы татарларының борынгы җирләрендә Минзәлә-Иске Чишмә-Чирмешән-Ак Яр хәрби ныгытмасы – «Засечная Закамская линия» төзелә. Иделнең уң ягындагы Олы Урда халкын – Мещера, Кадом һәм Темников җирләрендә яшәгән татарларны, нигездә, мишәрләрне Кама аръягына күчерү процессы башлана. Аларга берләшкән исем – мещеряк татарлары сословиесе дигән атама бирелә һәм әлеге татарлар Иделнең сул ягыннан алып Агыйдел бассейны буйларына, Урал тауларына кадәрге җирләрдә яши башлый. Хәрби ныгытмаларны төзергә Сура елгасы буенда яшәүче йомышлы мордва һәм чуашлар да күчерелә. Әлбәттә, аларның күпләре төпләнеп кала һәм хәзерге көндә дә бу җирләрдә нәселләре яши.

Гомумиләштереп әйткәндә, төзелгән кирмәннәрне, чик буен, күчеп килгән рус халкын һәм чиркәү җирләрен саклау өчен мондый гаскәри төркемнәр күчерелә. Алар: 1) коралланган казакълар; 2) Актачин шәһәре укчылары; 3) кызыл байраклы смоленск шляхтичлары; 4) Петр I чорында Россия дәүләтенең эчке өлкәләреннән руслар; 5) Петр I указы белән өстәмә гаскәриләр – 10 драгун полкы; 6) гвардеецлар һәм ландмилиция. Әлеге хәрби төркемнәрне берләштереп белопахотный солдатлар сословиесе төзелә. Алар рекруттан азат ителә, әмма һәрвакыт хәрби хезмәткә һәм дәүләт иминлеген сакларга әзер торырга тиеш булалар.

Шулай итеп, XVIII гасыр урталарына Нугай Урдасы татарлары биләгән мәйданның төньяк-көнбатыш ягы тартып алына һәм тулысы белән үзләштерелә.

КӨНЧЫГЫШ ЯГЫ

Иван IV, Казан ханлыгын яулап алганнан соң, Ык бассейныннан алып Агыйдел елгасы үзәнлегенә кадәрге җирләрне – Нугай Урдасы татарлары биләмәләрен тартып алып, үз теләкләре белән рус дәүләтенә буйсынган табигый башкорт халкына бүләк итә.

XVII-XVIII гасырларда Кама аръягының көнчыгышына – Минзәлә, Ык һәм Агыйдел елгалары буена рус, поляк, мордва, чуаш, чирмеш һәм башка халыклар күчерелә. XIX гасыр урталарына мещеряк, типтәр сословиесе кешеләренең күбесе башкорт сословиесенә кертелә.

Шул чорда яшәгән рус дәүләтенең билгеле тарихчылары язып калдырган китапларга анализ ясасак, хәзерге чор өчен бик катлаулы булган сорауларга анык җавап алыныр.

«Памятная книжка Уфимской губернии. Часть 1, 1873 г.» китабында: «башкорт» сүзе ике төрле мәгънәдә кулланыла:

1. Административ сословие буларак, башкортлар дип башкорт нәселләренә

генә түгел, ә шулай ук чирмеш, вотяк халкына һәм типтәр, мещеряк сословиеләренә дә әйтелә. Вотяк һәм соңгы ике сословие, берләштерелеп, яңа башкортлар дип атала башлый.

2. Этнографик милләт.

Шунда ук: *«Мещеряклар тарихи һәм генетик яктан башка булсалар да, икътисади һәм көнкүреш ягыннан алар охшаш. Мещеряклар да башкортлар арасында вотчинникларга әверелеп, этнографик яктан тулысы белән охшаш тормышта яши башладылар. Аларны аеруның кирәге юк. Әгәр раса һәм кан принцибы буенча аерсак, башкортлар үзләре генетик яктан әһәмиятләрен югалтырлар, үзләре генә тарихи-аерым элемент булудан туктарлар иде. Типтәрләргә килгәндә, 1865 нче елга алар юридик яктан аерым сословие булудан туктаганнар инде. Алар да башкорт сословиесенә кертелде. Башка бу мәсьәләне кире кузгатуның кирәге юк»,* – дип язылган.

«

Башкорт авылларында көнкүреш мәсьәләләрен хәл итү, вак җинаятьчеләргә хөкем карарын чыгару башкорт казыйларына йөкләнә. Нәтиҗәдә, авыл тормышындагы проблемаларны хәл итү шактый җиңеләя. Әлеге уңай якны да истә тотып, күп авыллар үзләрен башкорт сословиесенә яздырта башлый.

Кама аръягының көнчыгыш өлешендәге Нугай Урдасы биләмәләрен тартып алып, гаять аз санлы башкорт халкының бу җирләрнең яңа хуҗалары – вотчинник итеп билгеләнүе күп тарихи чыганакларда күрсәтелә. Ә әлеге җирләрнең элекке хуҗалары булган татарлар оброк түләп яшәүче припущенник итеп калдырыла.

Шулай да татар халкының бер өлеше төрле юллар белән башкорт сословиесенә язылырга мәҗбүр була. Башкорт булып язылгач, аларның тарихи үзаңнары үзгәрә, югалткан җирләргә дәгъвасы бетә, үзләрен шәхси милек кенә кызыксындыра башлый.

1871 елда басылып чыккан статистика китапларында 617 600 кеше башкорт дип язылса да, аларның 329 800е мещеряк һәм типтәрләрдән булганлыгы күрсәтелә. Калган 287 800 кеше дә табигый башкортларның санын күрсәтми.

1735 елда, Сенатның обер-секретаре Кириллов законы нигезендә, башкорт авылларында көнкүреш мәсьәләләрен хәл итү, вак җинаятьчеләргә хөкем карарын чыгару башкорт казыйларына йөкләнә. Нәтиҗәдә, авыл тормышындагы проблемаларны хәл итү шактый җиңеләя. Әлеге уңай якны да истә тотып, күп авыллар үзләрен башкорт сословиесенә яздырта башлый. Хәтта христиан булган халыклар да авыллары белән башкорт булып теркәлә. Соңрак башкорт булып язылган руслар зур авырлык белән генә үз милләтенә кире кайталар. Тарихчы Татищев: *«Кириллов чыгарган бу законнан соң, чын башкортларның санын якынча да белү мөмкин түгел»,* – дип язып калдырган.

Башкорт сословиесенә язылган халыклар турында тагын бер тарихи китап бар. Ул «Историческая записка о местности прежней Уфимской провинции, где был центр древней Башкирии. 1867 г.» дип атала. Бу китапта кемнәрнең башкорт булып язылганлыгы җентекләп аңлатыла. Анда: *«1557 елда Иван IV Урал төбәгенең Оса дару-*

гасындагы Гайнә волосте башкортлары нәселләренә «вотчинник» хокукларын бирә һәм үзенең грамотасы белән беркетә», – дип язылган. Бу җирләрнең элекке хуҗалары – Нугай Урдасы татарлары. Ләкин алар бервакытта да җирләрне, шулай ук рус җирләрен дә хосусыйлаштырмаганнар. «Җир – Аллаһныкы!» – дип санап, үзләренә аерып алмаганнар.

«Бу җирләрнең элекке хуҗаларыннан булган күп татарлар, Сенаттан раслатмыйча гына, Алтын Урда һәм Нугай Урдасы чорларыннан калган «борынгы исемлекләр»ен урындагы чиновникларга күрсәтеп, башкортларга бирелгән җирләрне «урлап», үзләрен башкорт итеп яздыртып, «вотчинник-башкорт» булып китәләр».

Рус тарихчылары үзләре дә мондый сорау бирәләр: «Ни өчен башкортлар бүләк ителгән җирләрне тулысы белән үз милке итеп кабул итә, фанатизм дәрәҗәсенә җитеп, шул җирләрен сакларга тырыша?» Бирелгән җирләрнең зурлыгы башка сыймаслык. Аз санлы башкорт вотчиннигына үз җирен карап, саклап тору мөмкин булмый. Урал төбәге җирләренең бик зур булуы нәтиҗәсендә, табигый башкортлар бирелгән җирләрне колачлый алмаган. Бу җирләргә «патша законнарын үтәмәүче» төрле халыклар «качып» килгән. Кайчак аларның авыллары күп еллар үткәч кенә ачыкланган.

Шул ук китапта: *«Бу җирләрнең элекке хуҗаларыннан булган күп татарлар, Сенаттан раслатмыйча гына, Алтын Урда һәм Нугай Урдасы чорларыннан калган «борынгы исемлекләр»ен урындагы чиновникларга күрсәтеп, башкортларга бирелгән җирләрне «урлап», үзләрен башкорт итеп яздыртып, «вотчинник-башкорт» булып китәләр. Урал төбәгенә башкорт вотчинниклары рөхсәте белән дә, рөхсәтсез дә бик күп халыклар күченеп утыра. Бик күп фин-угыр кабиләләре – чирмеш һәм вотяклар, мордвалар; типтәр һәм мещеряк сословиесе кешеләре; качып килгән рус халкы да килеп төпләнә. Шактый күп сандагы руслар һәм башка христиан халыклары да, ислам динен кабул итеп, «башкорт исеменә керәләр» (башкорт булып язылалар).*

Урындагы җирлек җитәкчеләре исәпкә алулар үткәрмәгән. Бу хәлләр турында ул чорда югары җитәкчеләргә билгеле дә булмаган. Пугачев восстаниесен бастырганнан соң, 1775 елга Россиядә борынгы табигый башкорт кабиләсеннән булган чын җир хуҗалары калмады.

1801 елда 100 мең атлы азиатларның, төрле күченүчеләрнең күбесе хөкүмәткә билгеле түгел. Алар, үзләрен борынгы башкорт нәселләре итеп күрсәтеп, җир талап итеп алганнар. Монда шулай ук татарлар, Алтын Урданың борынгы ханнары исемнәре бирелгән авыллар төзеп, күченеп утырдылар», – дип язылган.

Рус тарихчылары, элек яшәгән табигый башкортлар турында бик аңлатып, аларның кайда һәм ничек яшәгәнлекләрен, халкының санын күрсәтеп язып калдырганнар.

«Список населенных мест Российской империи. Уфимская губерния. 1887 г.» исемле китапта башкортларның Көньяк Урал буенда яшәүләре әйтелә. Анда: *«Башкортлар бервакытта да бәйсез булмаганнар, монгол (мәңге) ханнары һәм кенәзләре хакимлегендә яшәгәннәр. Ул*

монголларның берләштерелгән исеме нугайлар дип атала», – дип язылган.

1740 елда рус кенәзе Михаил Урусовның табигый башкорт старшиналарын җыеп сөйләгән сүзләре тарихта калган: *«Сезгә, табигый башкортларга, барлык диярлек нугай халкының җирләре бирелде. Күпләрегез тарханлык ярлыклары алды...»*

«Уфа губернасы төзелүгә (1865 елга), башкорт сословиесенә ясалма рәвештә күп санлы мещеряк һәм типтәр сословиеләре, Казан, Себер, Нугай Урдасы татарлары, чирмешләр, вотяклар, табигый башкортлар һәм башка халыклар берләштерелеп языла.

Шунда ук кызыклы факт ачыла: *«Барлык башкорт халкының саны гаять аз булуы, нибары берничә мең гаиләдән генә торганлыгы, шулай ук ярлы булулары һәм белемнәре булмау сәбәпле, алар тиз арада бер җирдә дә каршы торырдай көндәшләре булмаган татарларның тыңлаучан коралына әверелделәр, мөселман диненә кереп, Рус дәүләтенә каршы да көрәшә башладылар...»*

«Памятная книжка Уфимской губернии. Часть 2, 1873 г.» исемле китапта 1739 елда һәр даруга һәм андагы волостьларда яшәгән табигый башкорт халкының гаиләләр саны – 7129, җан саны 19 266 кеше булганлыгы күрсәтелгән. Берничә елдан соң гаиләләр саны 14 092гә җиткән. Ир-ат һәм хатын-кызлар, балалары белән бергә, 40 мең башкорт халкы исәпләнгән.

Шулай итеп, Рус дәүләте идеологларына башкорт халкы санын арттыру бик зарур булганлыгы аңлашыла. Гомуми саны 30-40 мең булган табигый башкортлар, тиз арада, миллионнар белән саналган татар халкына «кушылып», юкка чыгар иде. Шуның белән рус патшалары уйлап чыгарган «башкорт дигән тарихи аерым элемент» төзү тормышка ашмыйча, «татар» термины сакланып калыр иде. Нугай Урдасы татарларының җирләрен бирү, барлык табигый башкортлардан тарханнар ясау, салымнардан азат итү башкорт сословиесенең күпләп артуына китерә. Идел-Урал җирләренә юридик яктан хуҗа булу өчен, татар халкын ваклап, төрле милләттән булган төркемнәргә кушу идеологик яктан караганда иң дөрес һәм уйланылган алым була. Уфа губернасы төзелүгә (1865 елга), башкорт сословиесенә ясалма рәвештә күп санлы мещеряк һәм типтәр сословиеләре, Казан, Себер, Нугай Урдасы татарлары, чирмешләр, вотяклар, табигый башкортлар һәм башка халыклар берләштерелеп языла.

5 нче (1795 елгы) ревизия сказкаларына «мещеряк» һәм «типтәр» сословиеләре үз исемнәрендәге сословиеләр булып теркәлә.

8 нче (1834 елгы) ревизия сказкаларында «башкирцы из мещеряков» һәм «башкирцы из тептярей» дип языла.

10 нчы (1859 елгы) ревизия сказкаларында барысы да «башкорт» сословиесенә берләштерелә.

1871 елда башкортларның саны 617 мең дип күрсәтелә. Анда алда әйтелгән барлык милләт һәм сословие кешеләре дә кушып язылганлыгы аңлашыла.

Шул ук китапта: *«Табигый башкортларга типтәр һәм мещеряк сословиеләре кушылмаган булса, башкортларның тарихи әһәмияте бе-*

теп, алар тарихи аерым элемент булудан туктап, үзләре татарлар арасында ассимиляцияләнеп бетәрләр иде», – диелгән.

***

19 нчы йөз уртасы-XX гасыр башында Россия империясендә феодализмнан капитализмга күчү процессы башлана. Чагыштырмача демократик үзгәрешләр халык тормышына зур йогынты ясый. Милли үзаң формалаша, «крепостное право» бетә, завод-фабрикалар күпләп төзелеп, эшче сыйныфы барлыкка килә, яңа мөнәсәбәтләр урнаша. Бу үзгәрешләр нәтиҗәсендә, вотчинник сословиесе үзе биләгән җирләрне саклап кала алмый, аларның әһәмияте бетә. Вотчинник булудан туктаган һәм башкорт сословиесенә кергән татар, чирмеш (мари), вотяк (удмурт), мордва һәм башка халыклар үз милләтләренә кайтуны кулайрак күрә башлый. Башкорт сословиесенең саны кими һәм аның урынына башкорт милләте сүзе кулланылышка керә.

Хәзерге чорда башкорт милләтенең санын күп итеп күрсәтү йөзеннән, «яңа идеологлар» башкорт сословиесенең санын башлангыч итеп алалар. Алар аеруча Көнчыгыш Кама аръягындагы элек башкорт сословиесенә кергән барлык татарларны башкорт милләте итеп күрсәтергә омтылалар.

Тарихи дөреслеккә туры килмәгән уйдырмалар башка милләтләрнең дә милли үзаңын кимсетә. Кыргыз-казакъ халкының башкорт сословиесенә язылганнарын башкортларның кыргыз ыруы дип, төп атаманы кече өлеш белән алыштыру бара. XVII гасырда миллионлап халкы булган, өч зур урдадан торган кыргыз дәүләтләре башкортларның кыргыз ыругы гына булган, имеш.

Башкортларның бервакытта да үз дәүләтләре булмаганлыгы билгеле. Кызганыч, хәзерге көндә Башкортстан тарихчылары кайчандыр үзләрен буйсындырып яшәткән Нугай Урдасы татарларының нәселләрен һәм тарихын «урлап», аны үзләштерү белән шөгыльләнә. Анда яшәгән татарларны төрле ыругларга (мангыт, байлар, бүләр, сарайлы, гәрәй һәм башкаларга) һәм тагын да ваграк өлешләргә бүлгәләп, аларны башкорт милләте эчендә калдыру йөзеннән, мәгълүм тарихи фактларны үзгәртәләр. Аларның бу уйдырма фикерләрен тарихи документлар һәм шәҗәрәләр буенча җиңел фаш итеп була.

Шулай итеп, Россия империясенең, ясалма рәвештә бер халык исеме белән сословие төзеп һәм шуның эченә башкаларны язарга мәҗбүр итеп, киләчәк өчен катлаулы милләтара проблема ясаганлыгын күрәбез. Аны хәзерге көндә дөрес итеп чишү зарур.

Россия һәм башка дәүләтләрнең архивларында, тарихи китапларда татар һәм башкорт халкы турында гаять күп мәгълүмат табарга мөмкин. Һәр ачыш ут күрше булган бу ике милләтнең шанлы тарихына гадел бәя бирергә, чын дөреслекне ачарга ярдәм итә.

Файдаланылган чыганаклар:

1. Историческая записка о местности прежней Уфимской провинции, где был центр древней Башкирии. 1867 г.
2. Список населенных мест Казанской Губернии 1866 г.
3. Памятная книжка Уфимской губернии. Часть 1, 1873 г.
4. Памятная книжка Уфимской губернии. Часть 2, 1873 г.
5. Список населенных мест Российской империи. Уфимская губерния. 1877 г. ■

Актанышта Беренче бөтендөнья сугышы сәхифәләре

Лилия Габдрафикова

Актаныш районы җирләре 1917 елга кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязенә кергән. 1897 елгы мәгълүмат буенча, өяздә 379 981 кеше яшәгән, шуларның 7552се – Минзәлә шәһәрендә. Өяздә хәзерге Актаныш, Минзәлә, Зәй, Түбән Кама, Мөслим, Тукай һәм Сарман районнары, Әлмәт, Азнакай һәм Чирмешән районнарының бер өлеше урнашкан була. Актаныш районы җирлегенә Минзәлә өязенең Актаныш, Байсар, Пучы, Семиостров һәм Такталачык волостьлары кергән.

Минзәлә өязендә мобилизация

Гади халык өчен Беренче бөтендөнья сугышы хәрби мобилизациядән башлана. Татар халык иҗатында крестьяннарның басу эшләрен ташлап сугышка киткәннәрен бәян иткән бәетләр шактый. Әмма Минзәлә өязенә 1914 елның июль мобилизациясе кагылмаган. Биредә төп чакырылыш икенче хәрби мобилизация вакытында – шул ук елның сентябрь аенда башлана. Мәсәлән, 21 сентябрьдә генә Минзәлә өязеннән 1900 егет Казанга китә. Кайбер йорттан фронтка берничә ир-ат җибәрелә. Тарихчы Владимир Ермаков фикеренчә, бу чорда Минзәлә өязеннән фронтка озатылган солдатлар саны 10-11 меңгә җиткән.

Актаныш районы тарихына бәйле хезмәтләргә күз салсак, аларда кайбер авыллар буенча күпме солдатның фронтка җибәрелгәнлеге турында әйтелә, исемнәре дә телгә алына. Бурсык авылы тарихын барлаучылар, 50 якташыбыз фронтта һәлак булды, дип язалар. Чуракайдан – 87 кеше, Суыксу авылыннан 33 солдат фронтка китә. Чалманарат авылы тарихын өйрәнүчеләр сугышта катнашучылар исемлеген дә төзегән: Бакиров Шәйхелмәрдән, Госманов Харис, Латыйпов Васыйк, Латыйпов Мөхәммәдҗан, Фәтхетдинов Латыйп, Хәмзин Локман, Ханнанов Сәлмән, Шәрәфетдинов Хужабаһаветдин. Соңгы икесе фронтта һәлак булган.

Русия хәрби-тарихи архив материаллары нигезендә төзелгән «Памяти героев Великой войны. 1914-1918» (*https://gwar.mil.ru*) дигән мәгълүмат базасын карасак, анда күп кенә солдат исемнәре, бигрәк тә татарныкы бозып язылган. Бу писарьларның татар телен аңламаулары һәм хаталы язулары белән аңлатыла*. Солдатларның туган җирләре архив материалларының барысында да төгәл күрсәтелмәгән, кайбер очракларда өяз белән генә чикләнгәннәр.

Мәсәлән, Чалманарат авылыннан әлеге базада нибары 4 солдат исеме генә ачыкланды: Гаптулхананов Симнархарси, Хуснутдинов Мадригин, Милашенов Даулет-Гирей, Ямалтдинов Вазетдин. Төбәкне өйрәнүчеләр мәгълүматы буенча, сугышта Чалманарат авылыннан сигез кеше катнашкан. Архив материалында Гаптулхананов Симнархарси дип күрсәтелгән кешенең Ханнанов Сәлмән булуы да мөмкин. Ул 199 нчы Кронштад пехота полкында рядовой була. Брусилов прорывында катнаша, 1916 елның 20 августында Хута-Нова дигән поляк авылы янындагы яуда каты яралана һәм хастаханәдә кала. Аның язмышы документлар буенча билгеле түгел. Әмма, авыл тарихын өйрәнүчеләр мәгълүматынча, Сәлмән Ханнанов фронтта һәлак булган.

Чуракай авылыннан Беренче бөтендөнья сугышында катнашкан 8 солдат исемен күрсәтәләр: Гайсин Хираҗетдин, Галиев Әкрам, Гыйззәтуллин Шәрифулла, Насыйров Гафур, Рәхимҗанов Габдулла, Фәрдиев Мирзасалих, Хәйдәров Мостафа, Хафизов Нурлыгаян. Соңгы ике солдат әсирлеккә эләгә. Архив материалларын карасак, Чуракай авылыннан тагын 10 солдатның сугышта катнашканын ачыклыйбыз. Аларның да исемнәре хаталы язылган: Ахметвалиев Мендал, Абдуллин Абдураз Исланович, Акмалетдинов Маулетдин, Галимов Абдул Хакимович, Гизатуллин Юнус, Мухамедьянов Мухамацидек, Кадаргулов Нургалей, Казаргулов Галиян-Махамет, Хусаинов Насаттин, Шагимарданов Анас. Ике чыганактан алынган мәгълүматлар Чуракай авылыннан чыккан 18 солдатның исемен ачыклый, әмма билгесез солдатлар да шактый.

Саннар ни сөйли?

Минзәлә өязенең 5 волостеннан, ягъни хәзерге Актаныш районы җирлегеннән ничә солдат Беренче бөтендөнья сугышына алынган? Һәрбер авыл күпме кеше җибәргән? Кайбер статистик материалларны файдаланып, математик ысулга таянып, якынча саннарны әйтә алабыз.

Тулы булмаган мәгълүматлар буенча, Минзәлә өязеннән 1914-1916 нчы елларда фронтка 54 990 солдат җибәрелгән. Алда күрсәтелгән архив базасында Минзәлә өязеннән 54 092 гаскәринең документы бар. Математик исәп өчен

* Исем-фамилияләрне архив документында язылганча калдырабыз. Кызыксынучылар булса, шул исемне үзгәртми генә *https://gwar.mil.ru* базасына кертеп, документлар белән таныша ала.

Сугыш кырында газ баллоннарын кую

без шул саннарга таяндык. Шәһәрдән киткән солдатларны аерым санасак, һәр авылдан уртача 135 кеше җибәрелүе мөмкин дип фаразлыйбыз. Димәк, Минзәлә өязенең 5 волостеннан, ягъни хәзерге Актаныш районыннан 8141 кеше солдатка алынган. Бу – бик зур сан һәм тылда калган халык өчен авырлыклар тудырган югалту. Күп гаиләләр, крестьян хуҗалыклары ятим кала, аларның матди ягы зәгыйфьләнә. Минзәлә өязе кешеләренең якынча 14,5 проценты Беренче бөтендөнья сугышында катнаша, фронтның төп көче авыл халкы була.

Солдат анкеталарыннан күренгәнчә, Минзәлә өязеннән алынган гаскәриләр төрле полкларда хезмәт иткән. Әлбәттә, алар күбрәк пехотага эләккән. Кайвакыт якташлар бер җирдә хәрби хезмәттә булган. 54 092 гаскәридән 2144 кеше сугышта һәлак була, тагын 135 кеше яра һәм авырулардан бакыйлыкка күчә. 6731 кеше исә хәбәрсез югала. Моннан тыш, 2818 ир-атның язмышы әлегә кадәр ачыкланмаган. Солдат карточкаларында «сугыш кырында калдырылган» кебек билгеләр дә бар. Мондый хәрбиләр 905 кеше исәпләнә. Рәсми документлар буенча, Минзәлә өязеннән чыккан солдатлар арасыннан 87 кеше әсирлеккә эләккән санала. Яраланган, төрле контузия алган ир-егетләрнең саны – 28 285, ягъни Минзәлә өязеннән алынган гаскәриләрнең яртысы. Тагын 12 586 солдат төрле чир-сырхауларга дучар булып, хәрби сафтан чыгарыла.

220 нче Скопинск пехота полкында хезмәт итүчеләрнең язмышы аеруча аяныч тәмамлана. Актаныш якларыннан бу полкта 6 рядовой хезмәт иткән: Тимергалиев Мухаметхалим (Байсар волосте), Хакимуллин Ялчугулла (Байсар волосте), Садретдинов Бадрутдин (Пучы волосте), Ахметжанов Мухаметдин (Пучы волосте), Сибгатуллин Камилир (Пучы волосте), Гизатулин Зинатулла (Түбән Семиостров авылы). Бу солдатлар 1915 елның 24-25 июнендә Доловатка дигән поляк хуторы янында һәлак була. Үлемнәренең сәбәбе – газ белән агулану. Алар Германия армиясенең газ атакасы корбаннары булалар. Гомумән, Беренче бөтендөнья сугышында Минзәлә өязеннән киткән 26 солдат шулай һәлак ителә.

Актаныш батырлары

Минзәлә өязеннән фронтка алынган 210 солдат күрсәткән батырлыклары өчен төрле дәрәҗәдәге Георгий тәреләре һәм Георгий медальләре белән бүләкләнгән. Әлеге дәрәҗәле бүләкләргә Актаныш ягыннан 13 солдат лаек була: Сиразитдинов Гариф (Такталачык волосте), Муллашинеянов Фатхетдин (Такталачык волосте), Авсянетинов Довкатча Минивсиевич (Семиостров авылы), Султанов Шагигардан Мухаметович (Байсар авылы), Джамалтдинов Мигнохази (Байсар волосте), Баймахаметов Харис (Пучы волосте), Валиахметов Шаймухамет Валиахметович (Пучы волосте), Ямалетдинов Батретдин Ямалетдинович (Пучы волосте), Харматуллин Хайрулла (Байсар волосте), Сулбанов Худья Исламович (Әтәс авылы), Галишин Гильмутдин (Түбән Урьяды авылы), Маликов Ханан Хабирович (Суыксу авылы); Хайбатдинов Богаутдин (Семиостров волосте). Әлбәттә, батырлар арасында яу кырларында ятып калганнары да бар. Бу очракта дәүләт бүләкләре солдатның туганнарына тапшырылган.

Солдаткалар һәм яралылар

Сугыш башлангач, Минзәлә өязендә, тылдагы тормышта үзгәрешләр була. Хәрбиләрнең гаиләләре хөкүмәттән бераз матди ярдәм ала, бу акчаларны халыкка муниципаль органнар тарата. Губерна матбугаты хәбәр иткәнчә, Минзәлә земство идарәсе бүлеге сугышка чакырылган гаиләләргә пособиеләр таратуны көне-төне, ялсыз алып барган. Әлеге факт та сугышка алынучыларның саны күп булганлыгын исбатлый.

Сугышның беренче айларыннан ук яраланган солдатлар өязгә кайтарыла. Яңа госпитальләр ачу тизләтелә. Яр Чаллыдагы хастаханә, пристаньга якын булу сәбәпле, яралы һәм авыру солдатларны кабул итүнең төп пункты итеп сайлана. 1914 елның октябрендә беренче яраланган гаскәриләр кайта. Минзәлә өязенең калган хастаханәләренә савыгып килгән хәрбиләрне урнаштыралар. Мәсәлән, 1915 елның гыйнварында Чаллы лазаретыннан бер төркем солдатны Минзәлә шәһәре хастаханәсенә җибәрәләр.

Качаклар һәм әсирләр

Сугыш башлану белән, өязгә качаклар, интернированныйлар, ягъни Русиядә яшәгән, әмма дошман илләренең гражданнары булган гади кешеләр һәм хәрби әсирләр җибәрелә. 1915 ел ахырында Минзәлә өязендә 5123 качак теркәлгән, алар илнең Көнбатыш губерналарыннан, сугыш барган яклардан килгәннәр. Такталачык волосте авылларында, 1915 ел мәгълүматлары буенча, 750 качак яшәгән. Алар 1920 нче еллар башында гына туган якларына кайткан. 1915 елның сентябрендә Минзәлә өязендә чыгышлары белән Германия һәм Австро-Венгриядән булган 2760 кеше (интернированный) теркәлгән була. Хәрби әсирләрне башта җирле халык бик кызыксынып күзәткән. Мәсәлән, 1915 елның 29 мартында Чаллыдан Минзәләгә 1100 әсирне (Австро-Венгрия солдатларын) конвой белән күчерәләр. Шул күренешне карарга якын-тирәдән шактый кеше җыела. Соңрак, әлбәттә, өяздәге әсирләр гадәти күренешкә әйләнә, чөнки сугыш озакка сузыла. Аларны күбрәк авыл хуҗалыгы эшләрендә файдаланганнар. Шулай ук бер өлеше – 200гә якын кеше – Чаллы элеваторы


Московскій Городской Ходынскій Заразный Госпиталь
ист. бол. 2098
спр. пунктъ
Форма Кр. Кр. и В. В. 27 (VIII)
Московское Городское Общественное Управленіе.
ОТЧЕТНО-ОСВѢДОМИТЕЛЬНАЯ КАРТОЧКА.
(часть войска, лечебн. завед., учрежд.)
На убитаго, пропавшаго безъ вѣсти, поступившаго въ леч. завед. (непосредственно изъ ... и по переводу изъ лечебн. завед.), выздоровѣвшаго, умершаго, уволеннаго въ несно... ... эвакуированнаго, оставшагося въ строю ранѣнаго.
Фамилія Зайтбай
Имя и отчество Гантула
Мѣсто рожденія (губ., уѣздъ, селеніе) кр. Уфимской г. Мензелинск. у. Тахталачукск. вол.
званіе р. сд.
Часть войска 165 Луцкій п.
(время и мѣсто боя)
безъ вѣсти (тоже)
ранѣнъ (время и мѣсто боя) числа мѣс.
ненie, контузія; тяжелое, легкое; огнестрѣльн. (руж. пулей, шрапн., осколк. снаряда) холодн. оруж. (штыкъ, шашка, проч.); проникающее (черепъ, грудь, животъ, суставъ); съ поврежд. костей, безъ поврежд. костей; черепа, лица, шеи, груди, живота, спины, конечн.: верхней, нижней.


Форма Б.
Всероссійскій Земскій Союзъ помощи больнымъ и раненымъ воинамъ.
УВѢДОМЛЕНІЕ о ПРІЕМѢ
раненаго или больного, поступившаго съ театра военныхъ дѣйствій.
Губернія Оренбургская
Уѣздъ Челябинскій
Лѣчебница Лаз № 56 З. С. при Чел. Р. Ч.
Спец. госпиталь (патронажъ)
№ 2166.
1. Фамилія Галяметдиновъ
Имя Гималутдин отчество
2. Хол., женат., вдовъ
3. Негрям., грамотн., образован. 4. Возрастъ 21.
5. Народность татар.
6. Вѣроисповѣданіе магомет.
7. Войсков. часть, должность (занятіе) р. 99 Ивангор. резерв. пол.
8. Мѣсто родины: губ. Уфимская, Мензелинский уѣздъ (городъ) Байсаровской, д. Шабызбаш.
9. Мѣстожительство (передъ войной); губ. там же
уѣздъ (городъ)
10. Занятіе (передъ войной) хлеб.
11. Болѣзнь или поврежденіе (какое, когда и гдѣ получено)
12. Принятъ мѣс. марта числа 20 1916 г.


(Синія для нижн. чиновъ).
На прибывшихъ.
Фамилія Камадфутдиновъ
Имя Абдулгалимъ
Отчество
Воинское званіе и часть р. 330 Златоустов. п.
Губернія Уфимская
Уѣздъ Мензелинскаго
Волость Тахталачукской
Селеніе (деревня, станица) и деревни
~~Боленъ~~
Раненъ Р.
Время и мѣсто сраженія 19/VIII 15 бугъ
Названіе и подробный адресъ лазарета, сообщающаго свѣдѣнія (штемпель) Уфимская Команда


Списокъ № 15439

Фамилія.	Шайгатдинов
Имя и отчество.	Шаймардан
Часть войск и званіе.	2-й гр. РОСТОВСК. п. ряд.
Національность.	
Вероисповеданіе.	Маг.
Холост или женат.	ж.
Возраст.	
Грамотность.	
Род занятій (или профессія).	
Происхожденіе. Губернія.	Уфимск.
Уезд.	Мензелин.
Волость.	Тахтамчунск
Село, деревня или станица.	
Причина выбытія из части.	УБИТЪ
Время сраженія.	18 ИЮЛЯ -915 г

Минзәлә өязеннән киткән ир-атларның https://gwar.mil.ru сайтына кертелгән документлары

төзелешендә катнаша. Бу предприятие 1917 елның 4 сентябрендә эшли башлый, ул Русиядәге иң эре элеваторларның берсе санала.

Тылдагы тормыш

Әсирләр кебек эшче куллар булса да, Минзәлә өязендәге авыл халкы сугыш елларында зур кыенлыклар кичерә. Вак хуҗалыклар хәрби әсирләрнең хезмәтен файдаланырга ашыкмый. Атсызларның саны арта, кайберләрнең чәчүгә чыгарга да хәленнән килми. Крестьян гаиләләренең 1/3 өлеше ир-атсыз кала. Шулай ук 1915 елны иген уңмый. Түләнелгән пособиеләрнең ярдәме бик аз тия, чөнки көндәлек товарларга дефицит бәяләрнең кискен артуына сәбәпче була.

1917 елның февраль вакыйгалары, сугыш һәм түнтәрелеш кыенлыклары, бәяләрнең күтәрелүе, көндәлек товар һәм азык-төлек кытлыгы, әлбәттә, Минзәлә өязенә дә кагылган. Крестьяннарның инкыйлаб турындагы яңалыкларны дөрес аңлап җиткермәү очраклары да булган. Мәсәлән, Чалманарат авылында патша төшерелүе турындагы хәбәрне сугыштан кайткан солдат Мөхәммәтҗан Латыйпов тараткан. Халык бу яңалыкларны төрлечә кабул иткән. 1917 елның март аеннан Минзәлә өязендә шактый гына тәртипсезлекләр башлана. Пучы авылында бер төркем кешеләр урындагы табибны һәм укытучыны куа, хастаханәне яба. Күтәрелгән халыкның максаты волость идарәсендә һәм хастаханәдә эленеп торган патша портретларын алып ташлау була. Актанышта халык лавканы вата. Мондый хәлләр хәзерге Минзәлә районындагы Матвеевка һәм Новое Мазино авылларында да күзәтелә. Гулькино авылында (хәзерге Зәй районына карый) крестьяннар урман каравылчысын куарга маташалар. Җәен һәм шул ук елның көзендә хәлләр бик киеренке була.

Икенче яктан, Минзәлә өязендә ирек һәм тигез хокуклылык идеяләренә нигезләнгән, күп мәсьәләләрне тыныч юл белән хәл итүгә юнәлтелгән иҗтимагый чаралар да оештырыла. 1917 елның 15-16 апрелендә Теләнче Тамак авылында (хәзерге Тукай районы) Минзәлә өязе мөселманнары съезды уза. Анда 2500 делегат (әлбәттә, хәзерге Актаныш районыннан да) катнаша. Биредә Бөтенроссия мөселман съездына делегатлар сайлана.

***

Гомумән, инкыйлаб һәм аннан соң башланган Гражданнар сугышы давыллары Беренче бөтендөнья сугышы сәхифәләрен онытырга мәҗбүр иткән, дисәк, ялгыш булмас. Совет чорында бу тарихи вакыйгалар бик өйрәнелмәгән. Онытылган сугыш турындагы истәлекләр соңгы елларда гына яңадан торгызыла башлады.

Бүген Беренче бөтендөнья сугышы геройларының исемнәрен мәңгеләштерү мөһим. Татарстанның кайбер торак пунктларында андый мисаллар бар. Мәсәлән, Менделеевск районындагы кечкенә генә Мари Текәше авылында соңгы елларда бер һәйкәл ачылды. Анда, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның исемнәре белән беррәттән, Беренче бөтендөнья сугышына киткән ир-атларның да исемнәре бар. Әлбәттә, мондый изге эш – якташларның истәлеген мәңгеләштерү – һәр авылда һәм шәһәрдә башкарылсын иде. ■

Безнең мирас №3 март 2021

«Җырлаулары белән сихерләндем»

Мирхәйдәр Фәйзи

Балтач районының Шода авылында Сәедгәрәй имам булган мәчет

ШОДА АВЫЛЫ, 1923 ЕЛ, МАЙ-ИЮНЬ

22се урам халкының су сибешеп, куышып йөрүләрен карап тордым. Миңа да сибәргә кыҗрап куалар да, тартыналар. Анысы яхшы булды әле. Хатыннар, тәрәзәдәге кызлар, кунакка да сибегез, дип котыртып торалар. Бер кыз әйтә: «Мин булсам барыр да сибәр идем», – ди. «Син әле дә бар бит, әле дә кил дә сип», – дидем.

Өйгә кайтканымда чардактан ике кыз карап торадыр иде. Мәхмүрә, Ламига туташлар икәнен белеп, яннарына барып күрештем. Бик кыю азапланалар. Озак шаярып сөйләшеп утырдык. Китә башлаганнарында, чиләк белән су алып, артларыннан йөгереп чыктым. Берсе чүмеч белән, берсе чиләк белән су алып өлгереп, каршы торып каушаттылар. Әллә ни гомер куышып, уйнап йөрдек. Ламигасын

Көндәлекләрдән кыскартып бирелә. – ***Ред.***

«тәти абый» дигән матур сүзе хакына азат итеп, Мәхмүрә белән «сәүдәбез» озакка тартылды. Ахырында солых өчен кул бирешеп, чиләкләребезнең суын бергә түктек. Үзләрен арт капкага кадәр озатып калдым. Күңелемне ямьләп киттеләр, зимагур кызлар.

23е. Сәгыйть хезмәт урыны – Сәрдеккә кире китте. Салих белән үлән өстендә сөйләшеп утырдык. Аннан ул минем бүлмәмә кереп утырды. Аннан мин аның столовоена кердем. Тәмле ботка ашадык. Ул скрипка уйнады. Матур, авылча итеп уйный икән. Ике кыз килеп керде. Аларны җырларга көчләп, җырлата алмый интектек. Ахыры Салих, үзе генә теге бүлмәгә чыгып, миннән качырып җырлатмакчы булды. Мин, ул чыгу белән, урта ишекне бу яктан бикләдем дә, тышкы ишектән барып кереп, анысын эчтән бикләп алдым. Һаман шаяралар, кыланалар, назланалар. Тагы бер матур кыз килеп керде. Ахырында кушлап торып җырлый башладылар: скрипка да аларның тавышы, аларның тавышы да скрипка. Сандугач баласы, дип, җырлаулары белән сихерләндем. Бик күңелле булып, күңелләр ямьләнеп калды. Бу тартыш вакытында авыл кызларының байтак кына табигый кыланышлары, сүзләре, рәвешләре белән таныштым.

Кичке чәйдән соң урамга чыгып, Урбар урамына таба киттем. Кешеләр, яшь егетләр өелеп торган җиргә туктап сөйләшеп, танышып тордым. Егетләр җыелып китте. Бераз торгач, арадан бер яшь егетне ияртеп, урамнардан әйләнеп килик, дип, китә башлаган идем, каршыбызга Ламига туташ килеп чыкты. Үзләренә чәйгә керергә чакырды. Иярткән егетем аның энесе икән. Бу тәти кызның теләген иртәгәгә кичектереп, алга киттек. Тагы бер төркем егетләргә очрап, иптәшем (Ламиганың энесе Закир) аннан бер егетне эләктереп алып китте. Ул гармунчы икән. Гармунын алып чыгарттык. Су буена төшеп бүрәнәләр өстенә утырдык. Гармун гәйләп китте, бер егет бик әче әйттерергә тотынды. Тирәдән егетләр җыелды. Шулай иттереп күңелем теләге гамәлгә куелды. Күңелемнең үз дуслары булган авыл балалары арасында бәхетле булдым.

Урам буйлап, Закир белән бер малай бик матур авыл көенә җырлап, уйнап киттек. Тагы бер җиргә (канау тирәсенә) кунаклап, егетләрнең уйнавы, бию, шаярып сөйләшүләре дәвам итте. Тагы йөрдек, тагы утырдык. Гармунчыларга, җырчыларга, күңелем иркәләгән башка егетләргә дә папирослар бирдем. Дусландым. Закир белән бергәрәк йөрдем. Кызык һәммәсе дә. Чабатадан диярлек, кайсысы пима кигән. Арада бер генә итеклесе бар. Кадимгечә, япь-яшь, мапматур егетләр чабата киеп йөриләр шул. Шулай да ямьләрен бик өзми тагы. Башларындагы читсез бүрекләре яшьләргә бер дә килешми инде. Нигә яшьлекнең ямен шундый ямьсез киемнәр белән бозарга!..

Шода яшьләре революция тудырган мәдәни эшләрдән бик саф күренәләр әле. Аларда оешма да юк, клуб та юк, спектакль дә юк, аны уйлаган кеше дә юк. Бу тирәдәге авыллар, гомумән, шулай диләр. Кызганыч хәл!

Таңга якын гына кайтып, өйгә керәсем килми тышта утырдым. Рәхәтләнеп, җиңеләеп киттем дә, шул хәлне үземдә күбрәк тотар өчен, тагы утырырга тырыштым. Йокы рәхәт булды.

25е. Их, авылда рәхәт соң! Тирә ямь-яшел. Агачлар күп. Яшел үләннәргә басып сөенеп, ямьләрдән сөелеп, рәхәтләнеп йөрим. Кичкә таба Мәгъмүрә туташ килде, минем бүлмәдә икәү озак утырдык. Шаярып беттек. Кунакка чакырды, акыллым, барырмын, дидем. Күңелле булды.

Кичке чәйдән соң капка төбенә чыккан идем, яныма ике егет килде. Берсе – Нургалинең энесе Габдулла, икенчесе Идрис дигән егетләр икән. Габдулласы бик матур, җагымлы егет. Килеп күреште, сорашты, матур сүзләр әйтә белде. Тиз дусландык. Бергә йөреп килергә предлагать иткәч, ияреп киттем. Закирларга бардык. Аларның бакчасында Ламига да бергә булган хәлдә бераз утырдык. Аннан урамда йөрергә киттек. Беркөн «бердәнбер итекле егет» дип язганым Нуриәхмәтнең энесе Хаҗиәхмәт икән. Аның белән сөйләшеп уздым. Өре очына чыгып, байтак җирләрне әйләнеп кайтып килгәндә, гармунлы төркемгә очрадык. Берәү матур итеп уйный, әче иттереп җырлыйлар. Күңелле булды. Аннан Габдулла, Закирлар белән кайттым. Бу ике бер-берсенә дус малайларда үзем ярата торган хосусиятләр таптым, яраттым.

26сы. Бүген төшемдә Казандагы яшь язучылардан Толымбайскийның өй түбәсеннән җыгылып төшеп тә, җен дә булмаганын күрдем.

Ламига туташ, Кәримә ханымнар килде. Бергәләп бераз көн үткәрдек. Кәримә ханымга күлмәк чигәргә биреп җибәрдем.

Сәетгәрәй абзый белән Малмыж ягына сәяхәткә чыктык. Элек Түнтәргә таба киттек. Юлда коданың (Ишми ишанның) атылуы хакында сорашып бардым. Түнтәргә җитеп, кодагыйларга төштек. Нәкыйб каршы алды. Үткән килгәндә Ишми ишан янына кереп, аякларны издереп чыккан бүлмәбездә хәзер үз иркебезчә кунак булабыз инде. Кодагый да бу юлы һич качмыйча күренде. Бик матур, сөйкемле карчык икән. Бөтенләй әнигә охшаган кебек күренде.

Мирхәйдәр Фәйзинең абыйсы Сәедгәрәй хатыны Фатыйма белән

Гаян да өйдә. Ул хәзер коммунист. Озын, таза бер егет булган. Нәкыйб башка чыгып, Габделхәй, Нурисламнар үлгәнгә, ул өй хуҗасы хәзер. Бу йортта элек килгәнемдә Ишми ишан хаким мотлак иде, хәзер коммунист Гаян хаким инде. Габделхәй мескеннең хатыны Мәдинә ханым, угылы Үзбәкләрне күрдем. Мәдинә ханым – укыган, ямьле Казан кызы. Габделхәй тик иптәш табып, тормышын матурлаганда гына әрәм булды.

Чәй эчтек, аш ашадык. Аннан Гаян белән сөйләшеп утырдык. Ул хәзер биш волостьның райком РКП мәсьүл *(җаваплы)* секретаре икән.

27се. Сәгыйть тә килде. Ул, мин, Гаян Үзбәк бакчаларына бардык. Матур, күңелле. Агачлар арасында, үләннәр өстендә аунап яттык. Нәкыйб чакырды. Чәй эчтек, аш ашадык.

Түнтәрдә җыен атнасы. Урамнар чуп-чуар киенгән хатын-кыз белән тулган. Яшьләр уенын күрә алмадым. Барыйк дип тә әйтергә лөзүм күрмәдем. Мулла белән чыгылган бу сәфәрдә күңелем теләкләренә якынлый алмавымны алдан белеп чыктым инде мин.

Түнтәрдә шәп сыйланып, Малмыжга киттек. Юлда Исмәил, Ор, Шеншегәр дигән өч зур, матур татар авылларын үттек. Боларда тормыш күңелледер төсле тоелды.

Малмыжга җитәрәк бик уңайсызланып бардым. Җизнинең тормышы бик борчыр төсле тоелды. Малмыжга җиткәч, Хәким абзыйга ат куйдык та, җизнигә бардым. Элек килгәннәрдә абыстай тарафыннан каршыланган йортка боегып кына барып кердек, ләкин җизни бүлмәсе бикле. Чыгып киттек, тагы бардык, тапмадык. Шулай итеп бу йортның бусагасыннан сөртелеп йөрдек. Ахыр Шәфигулла Хәмидуллинга барып чәй эчтек. Җизни белән дә шунда күрештек. Йорты кулыннан тәмам ычкынып, борчылып йөргән чагы икән. Картайган, хатыны белән ташлашкан, баласы, туганнары юк, акчасы, нәрсәләре күп. Ни өчен ул йорт өчен аһ ора, аңа йорт нигә кирәк, белмим. Бар байлыгы белән полный рәхәтләнеп торыр җирдә, һаман капиталга ялчылык итә. «Сажинь бай хәерчедән дә ярлы», – дигән сүз шул инде.

Шәфигулладан чыгып, җизнигә кердек. Һавасы начар, тәртипсез бер бүлмә. Бер сәгать утыру да газап. Менә шулкадәр байлык белән шулай яшәп маташкан кешеләрнең малын совет тартып алса, аннан да изге нинди эш булсын. Аптырагач, бер йомыш табып чыгып китеп, Шушма буйларында йөреп кердем.

Бер кеше чәйгә чакырган икән, шунда киттек. Җизни зарларын сөйләп барды. Кызганыч та, ләкин... әллә ничек инде.

Мин Хәкимнәргә кайтып кундым.

28е. Иртә чәйне җизнигә барып эчтек. Җизнинең үзе куйган самавыр белән чәй эчү миңа бик ашсыз булды, уңайсыз булды.

Чәйдән соң зыяратка бардык. Чардуган ясатмаган, таш утыртмаган. Кичәдән бирле тартылмаган тел тегермәненең нәтиҗәсен шушында күрдем. Үзе дин белән, Алла белән башы әйләнеп беткән кеше, ә үзе дөнья йорты өчен чабып, ахирәтен оныта. Абыстайга булган мәхәббәтенә бер билге дә утыртырга өлгермәгән әле ул.

Малмыж кечкенә, әмма матур шәһәр. Бөтенләй бакча эчендә утыра. Өзлексез хуш ис аңкып тора. Нимес әсир докторлары аны Кавказ белән тиңләгәннәр.

Җизни миңа: «Шөкер, бозылмагансың икән әле, коммунист булып бетте микән дип курыккан идем», – диде. Үзе чын мәгънәсе белән контр икән. Гел дин белән чуалып, япь-яшь балаларның зиһенен чуалтканын, йомышка килгән балалардан «тәүхид кәлимә»ләре тыңлатып, һәлакәткә өстерәгәнен үз күзем белән күрдем. Үземнең чын йөземне ачып бәхәсләшәсем килмәде. Шулай да күңел бик тарланды. «Элекке иманнар җимерелде, революция вакытында төрле якка сугылып йөрелсә дә, хәзер чын һәм нык эзгә төшелде», – дип аңа әйтеп торасы итмәдем. Картны борчымадым.

Их, Малмыждан авылга килгән юлның матурлыгы! Йөреккә килеп, Нурвисал апайларга төштек. Аларның элекке йортлары янган инде. Өйдә Гафиулла абзый гына. Минем бәхетсезлеккә каршы, монда да яшьләр юк. Уллары Габдулла да, Нәҗип тә өйдә туры килмәде.

Гөлҗәүһәр туган белән дә, Нурвисал апай белән дә күрешеп, сөйләшеп утырдык. Нурвисал апай беркадәр зарларын да сөйләп алды.

Гафиулланың Нәкыйб дигән 14 яшьлек тагы бер улы бар икән. Бик сөйкемле малай. Күкәй җыеп сәүдәгәрлеккә хәзерләнеп ята. Тәмәке алырга килгән авыл егетләре белән каты мөгамәлә итеп, аларны да, мине дә аптыратты. Бик йомшак урында ятып йокладым.

29ы. Кич капка төбендә торганда Габдулла килде. Бергә су буена төштек. Бик матур күренешле су буеның бер матур җиренә утырып папирос тарттык. Яныбызга күрше Гыйльметдин малае килде. Шәрәфетдин атлы икән, гармунчы икән. 18 яшьлек кенә егет икән. Шундук гармунын алдырды. Гармун да килде, җырчы Идрис тә килеп җитте. Дөнья төгәлләнде. Уен-җыр китте. Озак утырып кайттым.

31е. Табигать матур, тирә ямьле. Җәй рәхәтләре белән иркәләнеп яшим. Тирәмдәге ямьләргә мәфтүн булып *(сокланып)*, мөрәҗәгать итәр нәрсәм булмаса да, саулыклар теләргә тотынам. Табигый ямьләр арасында гел-гел яшисем килә. «Сау булыйм!» – дим.

Көннең байтак өлешен үрдә, чардакның балконында үткәрдем. Бик матур, кечкенә генә, буяулы бүлмәнең чуар рәшәткәле балконында хозурланып утырдым.

2сендә. Шода белән Кунәр арасындагы күпер яны ике авылның егетләре, кызлары белән тулган. Болын чуп-чуарланып, аллы-гөлле чәчәкләр белән бизәлгән кебек булган. Яшьлек, шатлык, матурлык белән аңкый. Салихлар читтәрәк утырып уйнамакчы, анда бармыйча, читтән генә карамакчы булалар. Мин ул рамка эченә генә сыя алмадым, аз гына скрипканы тыңладым да анда, алар янына чаптым, Иделгә кереп актым. Яшьлек дулкыннары арасында рәхәтләнеп йөрдем.

Ап-ак оеклар, яңа чабаталар, итекләр, ак алъяпкычлар, чиккән күлмәкләр, бүрек, кәләпүш, эшләпәләр белән егетләр. Оек-чабата, ботинка, чуар күлмәкләр, чуар алъяпкычлар, яулыклар белән кызлар – күзләр белән иркәләнеп, күңелемдә тирбәтеләләр. Кызларның уеннары, егетләрнең биюләре, бергә биюләр, бергә уйнаулар, тагы язып бетерү, аңлату мөмкин булмаган әллә нәрсәләр хөкем сөрә.

> **«Кайсыбер кызлар оялып, тартылыбрак тора, егете аны сөйрәбрәк йөртә. Кызның йөзенә чыккан кызыллык. Егетнең аны кысып тотып үз янына сыендыруы картинага аерым бер ямь бирә.**

Егетләр кызлар төркеме эченнән берәр кызны әләктереп җитәкләп китәләр, бергә сөйләшеп йөриләр. Гаеп тә түгел, көлмиләр дә, үртәмиләр дә – кук дип тә кычкырмыйлар. Бик күңелле.

Шундый бернәрсә дә булып алды: Кунәр кызлары матур түгел дә, Шода кызлары матуррак, матурлыкка баерак, имеш. Кунәр егетләре Шоданың матур кызларын берәм-берәм җитәкләп алып китә башлагач, Шода егетләре җәберсенделәр. Уенга да җүнәтеп катышмый, җыенны рухландырырга хезмәт итми, протест сымак бернәрсә ясадылар. Шулай итеп, уенның иртә таралуына сәбәп булдылар.

Күңелемә иң охшаган картина шушы булды: бер егет белән бер кыз, җитәкләшеп, зур бер круг ясап әйләнеп йөриләр. Бу йөреш вакытында гармунчының ике ягында ике егет җырлаган хәлдә кочакланышып, әчке яктан агымга каршы әйләнәләр. Көчле җыр, музыка астында егет-кызларның җитәкләшеп, матур гына итеп сөйләшеп йөрүләре җанымны дәүләтләргә чумдырды. Карап туя алмадым. Болар театр фойеларында түгәрәкләнеп йөрүнең гайнән *(ничек бар, шулай, аутентик)* ясыйлар диярлек. Тик култыклашу урынына – боларда җитәкләшү. Кайсыбер кызлар оялып, тартылыбрак тора, егете аны сөйрәбрәк йөртә. Кызның йөзенә чыккан кызыллык. Егетнең аны кысып тотып үз янына сыендыруы картинага аерым бер ямь бирә. Сөйләшүләр шәһәрдәге кебек өзлексез түгел, озын сүзләр сөйләшеп бармыйлар. Җылмаешып, бер-ике сүз генә әйткәләп, җиңел генә шаярып йөриләр. Бу йөреш озак кына дәвам итте.

Бөтен халык таралып бетми кайтмадым. Нургалины да кайтармадым. Кәримә, Ламигалар белән дүртәү бергә, якын юлларны җыраклап, әллә кайлардан урап кайттык. Утырып-утырып хәл җыйгаладык. Нургали һаман элекке Нургали икән әле. Шаяра, көлдерә, ни тапмаса таба, аптыратып бетерә, оялтып бетерә. Кызларны кинаялеге бик юка өртелгән сүзләр белән коендыра, талый, кычкырта, куа. Өйләнү белән басылмаган, һаман яшьни. Ул хатын-кызга шундый бер тәклиф *(боеру)* тә ясаган: «Миннән качып йөрегез, югыйсә миңа үпкәләмәгез. Берәр хәл булса, мин отвечать итмәм», – дигән. Менә шул Нургали бергә булган өчен, кайтышлый да сиксән сигез төрле кызыклы хатирәләр калды. Дуслыкны ныгыттык, миңа күп җиңеллекләр ясады. Менә шулай үтте Шода белән Кунәр арасында элек-электән җола булып килгән еллык «Шода каршына» дигән уеннары.

«

Монда инде коры ятып йоклау белән канәгатьләнәләр. Зыянлы эш юк. Гадәт шулай. Шулай булмаса ярамый да. Үзләрен саклый алмаган егет-кызларга авылның хөкеме бик каты. Аларны тәмам мәсхәрә итәләр.

Кичке чәйне эчкәч, урамга чыктым. Ниндидер кызлар: «Мирхәйдәр абый, абыйлар су буенда», – дип кычкырдылар. Габдулла, Һашимлар белән шунда бардык. Егетләр дә, кызлар да бар – бәйрәм. Кантур очына чыктык. Яр башыннан су буен тамаша итеп папирос тарттык. Өре очыннан әйләнеп, үзебезнең урамга кайттык. Егетләр төркеме янына киттек. Бүген егетләр бар да киенгән, бар да урамга чыккан. Араларында озак йөреп кайттым. Хәлил үзләрендәге кунак кызлары белән йокларга чакырды. Мин бармадым. Егетләр: «Берсе янына мине сал», – дип җайланалар. Ә егет кызлар санынча гына егетләр алып китте. Монда инде коры ятып йоклау белән канәгатьләнәләр. Зыянлы эш юк. Гадәт шулай. Шулай булмаса ярамый да. Үзләрен саклый алмаган егет-кызларга авылның хөкеме бик каты. Аларны тәмам мәсхәрә итәләр.

Габдулла, Закир белән кайттым. Закир киткәч, Габдулла серле сүзләр сөйләде. Зимагур малай, минем исемемнән бер кызга сүз салып, җаучылыклар эшләп йөри. ■

Безнең мирас №3 март 2021

Коточкыч ачлык

Ачлык якларда

Татарстанда гыйнвар аенда 8 мең 485 кеше – ачлыктан, 1 мең 475 кеше тифтан үлгәннәр. Беренче февральдә җирле һәм чит ярдәмнәрдән 5 миллион 913 мең 355 зур кеше, 454 мең 524 бала файдалана, җөмһүрият эчендә 2 миллион 125 мең 591 зур кеше һәм 472 мең 982 бала ачыга.

Башкортстанда ачлык хәдтән ашкан. Авыллар бөтене белән кырылалар. Кеше ашау җыш очрый башлады. Декабрьдә барысы 660 мең ач иде, хәзер ачлыктан үлгән – 25 мең, авырган – 42 мең. Декабрь башына чаклы бер кадак та ярдәм килмәгән. Декабрь һәм гыйнвар айларында Башкортстанның 90 процент халкы ач хисапланалар. Ачлыктан үлү хисап ителә алмаслык дәрәҗәдә күп.

Саратов вилаятендә 600 мең кеше ачыга. Германиянең «Фринагау» обществосы Волга буендагы 50 мең дисәтинә җирне электрик белән эшләргә алмакчы булып, бу хакта Шуралар җөмһүриятенә *(СССР)* тәкъдим ясаган. Җир эшләре комиссариаты бу тәкъдимне карап, тикшереп, киләсе җәйдә иген эшләр өчен Волга буеннан 50 мең дисәтинә җирне немесләргә бирергә карар кылган. Җир белән файдаланган өчен немесләр беренче елны барлык игеннең 25 процентын, икенче елны 40 процентын Шуралар җөмһүриятенә биреп, калганын үзләренә алачаклар.

Азат Себер. – 1922. – 21 февраль.

Мәет ташучы үзе дә салкыннан катып үлгән...

Бөгелмә кантонында кара юллар

Сембер байларыннан Виноградов, яхуд *(яки)* «Дәдәй Костя» дип йөртелә торган анархист Бөгелмәдә (ул Бөгелмәдә хезмәт итә) бер ач татар хатынының 3 яшьлек баласын, тәрбиягә алам, дигән булып, чукындырды. Бу эш тиешле урын-

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2021) санында.

нарга белдерелсә дә, артык дикъкать ителмәде. Баланы җәберләү һәм шушындый авыр көннәрдә Шуралар җөмһүрияте *(СССР)* эчендә яшәп тә, татар халкының шул урыслаштыру сәясәтеннән котыла алмавы, бигрәк тә шушы соңгы факт гакылны гаҗәпкә калдырды. Моны да контрреволюция, әллә бер ялгышлык диергәме? Юк инде, ялгышлык дип булмый, бу ачык сурәттә татар пролетариатыннан көлү һәм, ачлыктан файдаланып, шул Ильминский компаниясенең кылган эшләренең дәвамы дип карарга туры килә. Әгәр дә ул баланың хәятен *(гомерен)* саклап калырга тырышып, эшне инсаният ноктаи назарыннан карап эшләсә, баланы чукындырмас иде.

Закир Исхаков.
Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 12 март.

Ана ач балалары белән. Аларның берсе үлем исереклегендә...

Тәтеш кантонында

Кантонда ачларга ярдәм комиссиясенең ашханәләрендә – 32 563 кеше, «АРА» ашханәләрендә 28 828 кеше туйдырыла. Тагын калган ачларның саны 100 меңнән дә ким түгел.

Хәзерге көндә азык китерелми тору сәбәпле, ашханәләрдә икмәк бирелми вә шул сәбәптән ачларның хәле һаман начарлана бара. Кантон халкының күбесе җәгълый азыклар ашап тора. 30-40 процент халыкның андый азыклары да юк инде. Андый кешеләр мәче, эт, үләксә һәм ат тизәкләре ашыйлар. Мәет ашаучылар да очраштыргалый. Ата-аналардан 3 кешенең балаларын иткә суеп ашаганлыклары беленде. Авыру һәм үлүләр һәркөн арта бара. 1921 елда кантонда ачлыктан һәм йогышлы авырулардан 1452 кеше үлде. Авылларда күп вакытта унар мәет

җыела вә аларны соңыннан бер кабергә күмәләр.

Һәммә авылда кадакланган йортлар очрый. Аларның хуҗалары җә үлеп беткәннәр, җә күчеп киткәннәр. Ачларның качулары узган август аенда башланды һәм октябрь аенда гына 39 513 кеше качты. Аларның бер өлеше кире кайтты инде.

Азык булмау сәбәпле, крестьяннарның үзара ярдәмләшү комитетлары начар эшлиләр. Күп ярдәм алына башлаганчы халык бик тизлек белән кимиячәк.

Шулай ук терлек-туарлар да бик тиз бетә. 1921 елда кантонда 21 мең сыер булган вә хәзердә 4700 баш калган. 18 мең баш атның фәкать 5096сы гына калган. 86 мең вак хайваннарның 6 меңе генә бар. Терлекләрне түбәләрдәге иске салам белән ашаталар.

Иген эшләгәндә һәр ат башына 30-40 дисәтинә туры килә. Шуңар күрә иген эшләре берничә атнага барачак. Ләкин бер ай эчендә генә бөтен сабан җирләрен сукалап бетерергә мөмкин булмаячак.

Фәкать җирләрнең көздән сукаланып калуы гына бераз ярдәм итәчәк. Чөнки андый җирләргә тырмалап кына чәчәргә дә мөмкин. Шәһәрдәге мөәссәсәләрнең *(оешмаларның)* атларыннан да файдаланырга туры киләчәк.

Кантонга наряд буенча 268 000 пот чәчүлек билгеләнде. Чәчүлек һәм атлар җитмәү сәбәпле, 40 процент җирләрнең чәчелми калуы көтелә.

Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 15 март.

Ачлык белән көрәш

Мәскәүдә Идел буе ачлары файдасына ясалган лотереядан 9 миллиард сумлап акча җыелган.

Смоленски вилаятенә *(өлкәсенә)* Идел буеннан килгән 1800дән артык ач бала урнаштырылды. Аларның күбесе «Фронтта ачларга ярдәм» комиссиясе тарафыннан җыелган иганәләр белән тәрбия ителә.

Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 5 март.

***

Гомәр Бәшировның «Көзге ачы җилләрдә» *исемле повесть-истәлегендә Арча ягындагы, аерым алганда туган авылы Яңасаладагы ачлык вакыйгасы бәян ителгән. Әлеге әсәрдән бер өзекне сезнең игътибарга да тәкъдим итәбез:*

«Комиссия торганда колагым ишетмәүне яшереп калдым, юкса мине чыгармаган булырлар иде. Өч айга өйгә җибәрделәр. Юлга биргән бер бөтен икмәкне солдат капчыгына салып, Казан вокзалына юнәлдем.

Барып төшсәм, хәйран калдым. Вокзал мәйданын ачлыктан качып килүчеләр баскан. Трамвайлар, автомобильләр күзгә чалынмый диярлек. Вокзал мәйданы бер кырыеннан икенче кырыена кадәр поезд көтүче авыл кешеләре белән тулган. Бар җирдә төтен. Әллә кырык-илле, әллә аннан да күбрәк урынга учак якканнар да солдат котелокларында чәй кайнаталар, барлы-юклы ризыкларыннан нидер пешереп яткан булалар. Мәйданның чуерташы өстенә бишмәтен йә чикмәнен җәеп, аның өстенә мендәрен, ястыгын салган да карт-карчыклар бөрешеп ята, кечкенә балалар да шунда ук, учак тирәсендә утыра. Йорттан алып чыккан кечкенә сандыклар, капчыкка тутырылган төрле кием-салым, йорт кирәк-ярагы да шунда өелгән.

Арлы-бирле сугылып эзләнә торгач, якташларыма барып юлыктым. Арада Тәмте, Саба, Арча яклары да бар иде. Бала-чагалары белән һәркайсы үз учагы тирәсенә җыелган да, башларын иеп, уйга калып утыралар.

– Икмәкле якка китәргә дә исәп, поезд юк. Менә дүрт тәүлек инде, – диде бер олы кеше. Мин шунда гына искәрдем: карасана! Поездлар гөрелдәве, паровоз гудоклары әллә нидә бер генә ишетелә икән бит! Мәскәү кадәр Мәскәүдә, шундый зур станциядә мондый тынлык бик авыр тәэсир итә иде.

Әлеге агай миңа карап алды да:

– Ә син кая таба юл тотмакчы? – дип сорады.

– Мин өйгә кайтам, Арча ягына! – дидем.

Бик гаҗәпләнеп күтәрелеп карадылар. Әлеге олы кеше, минем сүзне ошатмыйча, башын чайкады.

– Әйтеп торам бит, ачлык анда, дип, ачлык! Былтыр бер бөртек икмәк алмадык – янды, көйде. Мал-туарны көз көне үк суеп ашадык. Бер кабым ризык заты калмады. Нәрсәгә дип кайтасың, үләргә дипме?

Бу абзый минем зиһенемне чуалтып җибәрде. Ни хәл инде бу?! Нинди канлы сугышлардан исән-аман чыктым, тиф сырхавын җиңдем. Инде туган ягымның ындыр артына кайтып җиткәч, кире борылып китимме? Бу минем башыма сыймый иде.

– Алты-җиде айдан бирле әнидән хат юк. Туганнарым хакында бернәрсә белмим. Бик кайтасым килә шул, – дидем.

Теге абзыйга тагын бер кеше кушылды.

– Анда буласы булгандыр инде, энекәш. Син кайтып кына берсен дә төзәтә алмыйсың. Күпкә түзгәнне азга калгач кына түз! Кайтма ул якларга! Яңа икмәк өлгергәнче кайда булса да ялланып эшләп тор!

Нишләргә инде соң миңа? Бу абзыйлар акыллы киңәш бирәләр, аларга ышанмыйча мөмкин түгел. Ләкин ялланып мин нишли алам? Аягыма да чак кына басып торам лабаса! Аннары, нишләтим үземне? Кайтырга дигән ниятемне һич башымнан чыгарып ташлый алмыйм бит! Бу агайларның чын күңелдән бирелгән яхшы киңәшләренә колак салмау да яхшы түгел иде.

– Кайтмыйча булдыра алмыйм шул, абзыйлар, – дидем мин аларга. – Халык ни күрсә, миңа да шул... Хәзер май башы. Озакламый кукы, кузгалак, балтырган өлгерә. Кычыткан, алабута ашы белән булса да туенып торырмын...

Тагын бераздан Казанга поезд китәргә тиеш иде.

Ачлыктан йөзләре күм-күк булган, иреннәре зәңгәрләнгән якташларым минем киреләгемә сәерсенеп калдылар. Әлеге өлкән яшьтәге агай, сулагай кулын селтәп, миңа аркасы белән борылды. Мин, бу олы кеше алдында нindидер ярамастай эш кылган гөнаһлы бәндә кебек кыенсынып, атлар-атламас, тезелеп торган кызыл вагоннарга таба юнәлдем.

Кайтып төшсәм, йортта безнең гаиләдән беркем дә калмаган. Абыйлар әнине алып Себер ягына киткәннәр. Бөтен хуҗалык тузган, мал-туар юк. Икмәк юк, керосин юк, хәтта тоз да табып булмый. Авыл агайлары әйтмешли, «ат юк, арба юк, аннан бүтән бар да юк». Авыл кешесенең сабын белән ситсы күрмәгәннәренә биш былтыр. Яңа күлмәк кигән хатын-кызга шаккатып артыннан баралар иде: каян алган, ничек тапкан, ничек акча җиткергән? Паровозларга утын ягылган чак. Казаннан Арчага бик «фарт» килү сәбәпле генә бер көндә кайтып җитә алдым.

Юлда үзем юк-бар белән туенып уздырсам да, күңелем сизде, госпитальдә биргән арыш икмәген өйгә кадәр саклап алып кайттым. Шушы гади генә арыш икмәге дөньяда иң кадерле, иң тансык күчтәнәч булып чыкты...

Безнең йортта торып калган туганыбыз Зифа тәтәй икмәкне, юка телемнәргә кисеп, башта миңа, иренә, балаларына өләште. Хәтта минем белән күрешергә

кергән туган-тумачага, күршеләргә дә авыз иттерде. Кергән беренә прәннек тикле генә икмәк кисәге суза да, күзләрен челт-челт йомгалап:

– Бисмиллаһи, менә авыз итегез, Гумәр, рәхмәт төшкере, Мәскәүдән чын ипи алып кайткан, арыш ипие, – дип кабатлый иде.

Авылдашларымның ипи кисәге күргә күзләре елтырый, авыз сулары килүгә түзә алмыйча, төкерекләрен йоталар, ләкин ипине капмыйлар, рәхмәт әйтә-әйтә, балаларына алып чыгалар иде. Күрше килене Фагыйләнең, икмәк сузгач, зәңгәрсу иреннәре дерелдәп куйды. Ул, икмәк кисәген күкрәгенә кысып, шатлыгыннан сөйләнә-сөйләнә, ишек төбендә таптанырга тотынды.

– Ай, рәхмәтләр генә яусын! Менә бит, кибегеп беттем, күкрәгемдә бер тамчы сөтем юк, баламны туйдыра алмый интегәм. Нәниемә имезлек салам мин моннан, боерган булса, бер юньле ризык капсын, Алла теләсә...

Зифа тәтәй кечкенә яктан зур-зур табаклар белән яшел төстәге кайнар сыекча ташый башлады. Бу бик гаҗәп тоелды. Менә бу кечкенә малайларга нигә ашны шулкадәр зур табак белән бирә икән?

– Гаеп итмәссең инде, кычыткан шулпасыннан бүтән бер ризыгыбыз да юк, – диде Зифа тәтәй.

Барабандай зур корсаклы малайлар яшел шулпага комсызланып ташландылар. Ул сыекчаның тозы да, мае да, бүтән берние дә юк, аннан яшел үлән тәме генә килә иде. Ул арада малайлар табакларындагы яшел шулпаны чөмереп бетерделәр дә, тагын нидер көтеп, ач күзләре белән әниләренә текәлделәр. Зифа тәтәй, гаепле кеше сыман башын иеп, кечкенә якка кереп китте.

Мин тетрәнеп киттем. Шул көннән башлап ачлыкның бөтен рәхимсезлеген, дәһшәтен үз җилкәмдә күтәрә башладым. Зираттагы яңа каберләр янына көн саен яңадан кабер казырга туры килә иде. Урамда бер генә бала да юк, чөнки олысы-кечесе, ашыйсы килгәнне сизмәс өчен, көне-төне йоклап шешенеп бетәләр. Тора-бара авылда кабер казырга барырлык берничә кеше генә калды.

Мин алып кайткан икмәкне «авыз итүдән» соң яңа өлгергәнче, авызларга бер генә валчык та «чын ипи» кермәде. Алабута икмәге дә, кычыткан шулпасы да калмады, халык төрле какылар, балтырганнар, юачалар, үлән тамырлары белән дә тукланды, кишер чәе дә эчте. Тик яңа арыш орлыклана башлагач кына, хәлләр бераз җиңеләя төште.

Менә шундый шартларда бер кат өс-баш белән шәп-шәрә йортка кайтып төшүче авыру сугышчыга нишләргә, кая барырга? Ничек көн итәргә? Тормыш дигән бу аяусыз нәрсәне кайсы башыннан тотынып, ничек башлап җибәрергә? Бу сорауларга дөрес җавап табу, шул буталчык яшәеш ыгы-зыгысында үзеңә бердәнбер дөрес, бердәнбер туры юлны сайлап алу һич тә җиңел эш түгел иде.

Дөрес, революциягә кадәр, ягъни яшүсмер чагында, бөтен хуҗалык минем өскә калганнан соң, җир сөреп, печән чабып, иген эшләре белән мәш килеп йөргәндә, заманасына күрә минем хыялым юк түгел иде: яхшы ат, шәп дирбия, чибәр өс-баш, ак мунча... Аннары инде шушылар һәммәсе дә көйләнеп, үз урынына килеп утыргач, әнигә акыллы гына, чибәр генә бер килен...

Әмма революциядән соң, бигрәк тә гражданнар сугышында йөреп, ярты дөньяны дигәндәй айкап кайтканнан соң, яшүсмер чактагы ул хыял бик кечкенә булып калды. Революция яшьлек дәртенә канат үстерде. Авыл яшьләренең күбесе, бигрәк тә аз-маз укыганы, ул вакыттагы крестьян тормышының тар буразнасына гына сыя алмый башлады».

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** һәм **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Ибраһим Хәлфиннең Казан тарихына багышланган хезмәте

Раиф Мәрданов

Сүзебез Ибраһим Хәлфиннең Казан дәүләт университеты фәнни китапханәсендә саклана торган бер тарихи хезмәтенә (төгәлрәге, Казан тарихына багышланган әсәренең кереш өлешенә) бәйле кәгазьләр турында.

Альберт Фәтхи: «Бу әсәр үзе сакланмаган»

Фән әһелләренең игътибарыннан читтә калып килгән әлеге кульязманы татар тарихы фәне өчен бик мөһим дип саныйбыз. Аның турында галим Альберт Фәтхинең хезмәтендә мондый мәгълүмат бирелгән: *«216 т (э.№2667). Төхфәт-эл-җәдидә фи тәварихы кадими Казан. – Казан, 1827. Автограф. Нәсех. 2 кәгазь, 17х22. Өч битле (1б–2б кәгазь) бу кульязма И.Хәлфиннең Казан тарихына багышланган «Төхфәт-эл-җәдидә фи тәварихы кадими Казан» (татарча әйткәндә «Борынгы Казан тарихыннан яңа истәлек») исемле әсәренең кереш сүзеннән гыйбарәт. Ул әсәр үзе сакланмаган, гыйльми әдәбиятта да аның турында мәгълүмат юк. Әсәргә кереш сүзләрнең, гадәттә, әсәр эшләнеп беткәч, җәмәгатьчелеккә, басмага тәкъдим итәлер алдыннан язылуын исәпкә алганда, бу әсәр тәмамланган булган дип уйларга кирәк. Кереш сүзнең каралама түгел, ә акка күчерелгән нөсхә булуы да шуны ук күрсәтеп тора. Анда И.Хәлфин әсәрне язуның сәбәпләре, эчтәлеге, Казан тарихы буенча чыганаклар хакында фикер йөртә. Әсәрне язуының сәбәпләрен әйтә. И.Хәлфиннең бу китабының үз дәверендә басылмавы һәм фәндә билгесез калуы цензура белән бәйле булырга тиеш, чөнки нәкъ менә шул дәвердә цензура җирле тарихка карата каты тыйгын сала. И.Хәлфиннең монда тасвирланган кульязмалары 1920 нче елларның азагында Татар китап палатасы тарафыннан сатып алынган»*[1].

***

«Төхфәтел-җәдидә...» хезмәтенең авторы Ибраһим Хәлфин керешен «бисмиллаһ...» белән башлап, Аллаһы Тәгаләгә һәм рәсүленә мактаулардан соң болай язган: *«...Сәбәбе тәэлиф бу габде би-бизагать Ибраһим бине Исхак Хәлфийүн мәмләкәтемезә хезмәт вә мөэмин карендәшләредән хәер-фатиха илә йад улынмакымы таләб вә җәлеб идүб, Казан шәһәренең кадими бөнйады илә әхваль вә хәвадисәтләрене, вә ханларыны, вә анларның солтанәтләрене, вә рус хәлайыкы илә ничәмә кәррә газа вә хәребләрене, вә соңрада хикмәте Йәздани вә газабе Илаһи илә «төэтиәл-мөлкә мән тәшаэү» айәте шәриф фәхвасенчә, дийаре Казанга рус хәлайыкының зафәрләре, нитәк хәраб вә бәгъдә нитәк забыт әйләмәкләрене һәрчәнд бәгъзесе бу замана дик бәйнән-нас сәмәган зикер улынуб калынурса да, ләкин безем ул заманлардагы мөселман җәмәгатьләре әүвәлән – әмир Тимүрнең*

[1] Кульязмалар тасвирламасы. XII чыгарылыш: Татар әдипләре һәм галимнәренең кульязмалары. Өченче бүлек / төз. А.Фәтхи. – Казан: Ун-т нәшр., 1968. – Б. 29.

дийаре Болгар вә әтрафларыны вәйран кыйлмакы, икенче – Дәште Кыбчак вә Урду ханлары бер-бере ара җәң идешүләре, өченче – соңрада рус хәлайыкы куәтләнүб, анлар илә чук җәң вә җидаль, вә әтрафе Казан, вә гайре мәкяннәрдә дәхи чук-чук мөһликәтлекләр сәбәбле, тәварихлар китабәт итмәйә имкян улынмадыкданмы йәки китабәт кыйлмыш исәләр дә, ул замандагы дошман хәлайыклары әлләренә дөшүб, тәләф улынмакларынданмы – бонлар хосусларында безләрә һәрничүк бер тәварих вә төхфә йазуб калдурдуклары бу анә дик һичкайда вә һичбер йирдә мәсмуг вә мөшаһәдә улынмадукларындан отру, бәгъзе әһле ислам тәварихы гөзидәләрендән әхәз вә иҗмалән бәдд идүб вә ахырында ки шәһри Казан хосусында игътибарлу рус тәварихларына зарури мөраҗәгать вә анлардан имкянем кадәр тәрҗемә вә бонда тәртибләренчә бәрабәр җәмегъ әйләмәкемлә, бу китабы «Төхфәтел-җәдид фи тәварихы кадими Казан» дәйү тәсмийә әйләмешем. Илтимас идәрем ки, тапуларыңызда бу кечекчә хезмәтем хөсне зан иделүб, сәһүләре гафу улына ирде.

Фи сәнәи һиҗри 1243 вә фи сәнәи милад 1827 бу китаба шөруг улынды вә билләһи тәүфыйк».

Текстның хәзерге телгә күчермәсе

«Бу фәкыйрь кол Ибраһим Исхак улы Хәлфин язуымның сәбәбе – мәмләкәтебезгә хезмәт һәм мөэмин карендәшләрдән хәер-фатиха белән искә алынуымны таләп вә җәлеп итеп, Казан шәһәренең борынгыда нигезләнгәннән соңгы хәлләрен һәм вакыйгаларын, ханнарын һәм аларның хакимлекләрен, рус халкы



Ибраһим Хәлфин кульязмасы

белән ничә мәртәбә изге сугыш вә орышларын, һәм соңыннан Тәңре хикмәте һәм Аллаһ газабы белән «төэтиәл-мөлкә мән тәшаэү»[2] («патшалыкны кемгә теләсәң, шуңа бирәсең») мәгънәсенчә, Казан вилаятен рус халкының җиңүе, ничек харап итеп һәм ничек басып алуларын – бу заманга кадәр халык арасында нихәтле ишетелеп сөйләнеп калса да, ләкин безнең ул заманнардагы мөселман җәмәгатьләре әүвәл – әмир Тимернең Болгар йортын һәм тирә-ягын вәйран кылуы, икенче – Дәште Кыпчак вә Урда ханнары бер-берсе белән сугышулары, өченче – соңында рус халкы куәтләнеп, алар илә күп сугыш вә җәнҗал Казан ягында да, башка урыннарда да тагын күп-күп һәлакәтләр сәбәпле, тарихлар язарга мөмкинлек булмауданмы яки язсалар да, ул замандагы дошман халыклары кулларына төшеп, юкка чыгуларыннанмы – болар турында безгә һәрничек бер тарих вә әсәр язып калдырганлыклары бу вакытка хәтле һичкайда һәм һичбер җирдә ишетелмәүгә вә күрелмәүгә күрә, кайбер мөселман сайланма тарихларыннан алып һәм кыскача аерып, ахырында Казан шәһәре турында җитди рус тарихларына зарури мөрәҗәгать итеп һәм алардан мөмкин кадәр тәрҗемә итеп һәм монда тәртибе белән туплавыма күрә, бу китапны «Төхфәтел-җәдид фи тәварихы кадими Казан» дип исемләдем. Үтенәм ки, сезгә хезмәт итүдә бу кечкенә хезмәтемә яхшы уйда булып, хаталары гафу ителсә иде.

Һиҗри 1243 һәм милади 1827 елда бу китап башланды, Аллаһы ярдәм итсә иде».

Китап ни өчен басылмаган?

Хәлфиннең бу хезмәте басылмыйча калуның сәбәбе, А.Фәтхи фикеренчә, цензура тыюдан булуы чынбарлыкка никадәр туры килгәндер – әйтүе читен. Һәрхәлдә, университет каршында 1812 елда оештырылган цензура комитеты 1827 елда ябылган һәм көнчыгыш телләрендә чыгачак китапларга аерым цензор итеп профессор А.Казимбәк билгеләнгән. Галим Әбрар Кәримуллинның язуынча, 1829 елдан соң университет үзе чыгарган китаплар бернинди цензурасыз басылган[3].

Хәлфин китабы басылмау аның 1829 елның гыйнварында вафат булуы белән бәйледер. Чөнки, «үзе юкның сүзе юк» дигән кебек, вафатыннан соң кайгыртып йөреп, бастырып чыгару хәстәрен күрерлек мөмкинлек булмаган. И.Хәлфин үлгәннән соң аның улы Шаһиәхмәтне университет типографиясенә хәреф җыючы итеп тә алмаганнар. Гәрчә ул гимназиядә укыганда ук әтисенә типография басмалары корректураларын укыганда булышып, тәҗрибә туплаган. Аны эшкә алмыйча, хәрби хезмәткә керергә тәкъдим иткәннәр[4].

Ибраһим Хәлфиннең «Төхфәтел-җәдидә...» китабы басылып чыкмаган һәм кульязмасы тулаем сакланмаган булуга карамастан, аның датасы күрсәтелгән үз мәгълүматына нигезләнеп, факт буларак тәкъдир ителергә тиеш иде. Һәрхәлдә, ул – татар халкының тарихын фәнни нигездә өйрәнүгә гыйльми оешмада хезмәт иткән татар галимнәреннән Ибраһим Хәлфин XIX гасыр башында керешкән дигән нәтиҗә ясарга ышанычлы дәлил. ■

---

[2] Коръәннең «Әлү Гыймран» сүрәсендәге 26 аятьтән.

[3] Кәримуллин Ә. Китап дөньясына сәяхәт: татар басма сүзенең сәхифәләреннән. – Казан: Татар. китап нәшр., 1979. – Б. 44.

[4] Каримуллин А. У истоков татарской книги. Изд-е 2-е, испр. и пер. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1992. – С. 128.

Метрика язмаларында Актаныш төбәге

Эльмира Сәлахова

Яңа Байсар авылындагы йорт. XX гасыр уртасы

1829 елдан башлап алып барылган метрика язмалары – имамнарының үз мәхәлләсендәге кешеләрнең гражданлык хәлен теркәгән әлеге документлар татар халкы тормышының билгеле бер тарихи этаптагы хәләтен, үзгәрешен, үсешен өйрәнергә зур мөмкинлек бирә. Бу мәкаләне элеккеге Байсар һәм Шәрип волостьларына караган Байсар, Мәчти, Актанышбаш, Иске Кормаш, Иске Гәрәй һәм Такталачык авылларының 1870-1880 нче еллардагы метрика кенәгәләре нигезендә яздык.

Байлар иле – Байсар

Байсар волостена XIX гасыр ахырында 26 татар авылы кергән. Аларның күбесе берничә мәчетле зур авыллар. 19 нчы йөз ахырында волость үзәге Байсар авылында 298 йортта 1817 кеше гомер кичергән, 2 мәчет-мәдрәсә булган. Авылда почта станциясе, шимбә көннәрдә базар эшләгән. Анда сәүдәгәрләр 13 лавка тоткан. XIX гасырның 80 нче елларында Байсардагы ике мәхәлләдә туучылар саны 90-130 кеше була. Вафат булучылар саны туучылар белән чагыштырганда азга гына калыша. Авылның зурлыгын билгели торган тагын бер факт – никахлар саны. Байсарда елына 30-35 никах укылган. Авыл зур булгач, талак саны да күп. Бер елда ул җидегә җиткән. Никах вакытында бирелә торган мәһәр күләме дә байсарлыларның башкалар белән чагыштырганда хәллерәк яшәгәнлегенә ишарәли. Әлбәттә, мәһәр күләме төрле факторларга бәйле, ул бары тик гаиләнең матди байлыгыннан гына тормый. Олырак кешеләр, икенче йә өченче никахка керүчеләр өчен мәһәр күләме яшь кыз-

га бирелә торганнан күпкә кимрәк булган. Байсар авылында 19 нчы йөзнең 80 нче елларында күп очракта никахка 500-600 сумлык мәһәр бирелгән. Бу заманы өчен кечкенә сумма түгел.

Башкортка күчүчеләр

1730 елда Казан губернаторы А.П.Волынский «Россия империясендә башкорт мәсьәләсенең торышы һәм аны чишү юлындагы алымнар» дигән язмасында «башкорт»лар яшәгән җирләрдә халык санының тиз темплар белән үсүен, аларның бу төбәккә җир салымының югарылыгыннан, төрле изүләрдән качып килүен әйтә. Ул: *«Моннан 20 ел элек кенә 35-40 меңнән артмаган башкорт саны бертуктаусыз үзгәрә тора һәм хәзер качкыннар хисабына 100 меңнән артып китте. Казан, Сембер, Темников һәм башка өязләрдә яшәүче ясаклы татарларның яртысыннан артыгы башкортка күчте, башка христиан булмаган халыклар да, мордва, чуаш, вотяклар, бөтен авыллары белән, ясактан качып, шунда ук күчтеләр»*, – дип яза. Оренбург губернаторы И.И.Неплюев та 18 нче йөздә үк башкортлар составы рус булмаган халыклар белән тулылануын язып тора. «Башкорт» атамасының социаль катлам булуы хакында хәзерге заман тарихчыларының да хезмәтләре бар. Аңлашыла ки, XVIII-XIX гасыр документларында кулланылган «башкорт» атамасы этноним мәгънәсен аңлатмый. Гадәттә, ревизия документлары, метрика язмаларында халыкның милләте түгел, ә социаль катламы күрсәтелгән. Мондый төр документларның төп максаты – кешеләрнең нинди милләттән булуын ачыклау түгел, ә салым түләү, армиягә алу өчен төгәл санын һәм яшен белү. Диния нәзарәтенең кагыйдәсе буенча, метрикага сословиене язу таләп ителми, әмма атасы мещан, дворян яисә мактаулы граждан булган очракта, аларны күрсәтү кирәк, диелә. Шулай да муллалар үз теләкләре белән авылның барлык башка катламнарын да теркәп куйганнар. Мисал өчен, метрикаларда крестьян, зирагатьче (ягъни игенче), мулла, имам, мөәзин, типтәр, башкорт, хәтта падишаһ коллары (безнең фикеребезчә, дәүләт крестьяны) дигән катлам да күрсәтелә. Авылда берничә төрле катлам кешеләре яшәгән вакытта, бер үк мәхәллә халкын ике исемлеккә язу очраклары да бар. Мисал өчен, шул ук Минзәлә өязенә кергән Рангазар авылында (хәзерге Сарман районы) «башкорт» һәм «типтәр» сословиеләрендә булганнар бер үк кенәгәдә ике аерым исемлеккә язылган.

Байсарның беренче мәхәлләсендә социаль катлам күрсәтелми – «башкорт» сүзе юк. Ә икенче мәчеткә караган мәхәлләдә яшәүчеләрнең барысы да «башкорт» дип теркәлгән. Иске Кормаш авылы метрика язмаларында да сословие бөтенләй күрсәтелми, Актанышбаш авылында яшәүчеләрнең дә зур күпчелеге «башкорт» сословиесе дип язылган, әмма тулысы белән түгел. Ә менә Иске Гәрәй авылы кешеләре тулысы белән «башкорт» сословиесендә күрсәтелә. Такталачык авылында да «башкорт»лар яшәгән. Бу авыллар тарихына күз салсак, аларга XVII-XIX гасырларда нигез салынган. Такталачык һәм Гәрәй авылларының тарихы XVII гасырдан башланса, Байсар һәм Иске Кормаш 18 нче йөздә нигезләнә, Актанышбаш XIX гасырда барлыкка килә. Әлеге авыллар тарихының чагыштырмача яңа булуы аларның хәзерге Актаныш районы территориясендә җир кишәрлекләре алып, башкорт сословиесенә керүләрен күрсәтә.

Мәчти – затлы кешеләр авылы

Мәчти үзенчәлекле авыл. Кызганыч, ул хәзер Татарстан картасында юк, 1970 нче елларда юкка чыккан. Кайбер чыганакларда Наратлы исеме белән дә йөртелгән. Бу авыл хакында билгесез авторның кулъязма этнографик очеркы бар,

аның төп нөсхәсе Казан университеты китапханәсенең кульъязмалар бүлегендә саклана. Китап 2017 елда тарихчы Х.З.Баһаветдинова тарафыннан өйрәнелде һәм фәнни әйләнешкә кертелде.

Билгесез автор язуынча, авылның нигезләнүе турында берничә фикер бар. Мөфти Мөхәммәдъяр Солтановның ерак бабасы, җир сатып алып, шунда үз утарын булдыра, соңрак авыл зурая. Икенче караш буенча, аның бабасы, тугрылыклы хезмәте өчен, Екатерина II тарафыннан җир белән бүләкләнә. 1816 елгы ревизия вакытында бу авылда Солтановлар нәселеннән 26 ир-ат, 1834 елда – 43, 1850 елда – 37, 1859 елда 39 кеше исәпләнә. Авылда «башкорт» сословиесендәге дворяннар һәм дворян булмаганнар да яшәгән, җирсез, ялланып эшләүче крестьяннар да көн күргән. Бу авылның 1870-1890 нчы еллардагы метрикаларына обер-офицер чины, дворянин, сотник, ясаул, поручик, урядник, башкорт дигән катламнар да язылган. Аларның барысы да диярлек Солтанов фамилиясендә. Метрика язмаларында тагын бер үзенчәлек – хәрби чинны яисә дворянлыкны урысчалатып «из дворян» дип язу. Шул чорда авылда яшәгән дворян титуллы башка кешеләрне дә искә алыйк: Шаһсолтан Шаһхәйдәр улы Солтанов, Шаһмөхәммәд Солтанов, Әхмәдшаһ Солтанов, отставкадагы ясаул Шаһиморад Солтанов, Шаһимәрдан Дәүләтшаһ улы Солтанов, Шәехрамазан Солтанов һәм башкалар. Шул ук Солтанов нәселеннән булган Мөхәммәдгали Габделгалләм улы Солтанов, Хөснетдин Габделмәннан улы Солтанов, Солтангәрәй Габдерәкыйб улы Солтанов һ.б. бары тик «башкорт» сословиесендә генә күрсәтелә. Кайбер Солтановларның дворян титулында булып, икенчеләренең исә дворян титулын йөртмәүләренең сәбәбе хакында алда әйтелгән билгесез авторның кульъязма хезмәтендә җавап бар. Ул бу хакта ике төрле караш булуын күрсәтә. Солтановның полковник чинын алганчыга кадәр туган балалары, онык-оныкчыклары дворян титулын йөртмәгән, ә чинны алганнан соң туган балаларның нәсел дәвамчылары «потомственный дворянин» дип язылган. Әмма автор, бу версия белән ризалашмыйча, үз фикерен болай аңлата: Солтанов поручик чинында булган, ул нәселдән килә торган дворянлык чинына ия булмаган, шул сәбәпле, балаларына бу титулны тапшыра алмаган. Балалары исә моңа фәкать үз хезмәтләре белән ирешкән, кайсыдыр дворян булып киткән, кайберләре бу дәрәҗәгә күтәрелә алмаган.



Мәчти һәм Байсар авыллары метрикаларыннан фрагментлар

Мәчти авылының тормышына бәйле саннар метрика язмаларында да чагыла. XIX гасырның 90 нчы елларында 46 хуҗалыкта 280 кеше гомер иткән, аларның мәчете һәм 2 мәктәбе булган. Метрика язмаларыннан күренгәнчә, мәхәллә әллә ни зур

булмаган. 1870-1890 нчы еллар аралыгында туучылар саны елына – якынча 9-25 кеше. Башка авыллардагы кебек, вафат булучылар саны югары. Мисал өчен, 1892 елда вафат булучылар саны туучылардан 13 кешегә артык. Авыл халкы санының артуы түгел, ә кимүе хакында сүз алып барырга кирәк. Вафат булучыларның зур күпчелеген кече яшьтәге балалар тәшкил иткән. Алар арасында 3 көнлек баладан башлап 12 яшькә кадәргеләре дә бар. Ул елны олылардан бары тик 78 яшьлек кеше генә картаеп вафат булган. Үлүчеләрнең 90 проценттан артыгын яшь балалар тәшкил иткән. Аларның вафат булу сәбәпләре, әлбәттә, шул заманда балалар арасында киң таралган йогышлы чирләр: чәчәк, кызамык, күкрәк зәхмәте, бума, баш, эч авырулары һ.б.

Җир эшкәртү белән көн күргән мәчтилеләрнең матди табышлары әллә ни зур булмый. Бу метриканың никахларны теркәгән сәхифәсендә дә күренә. Никах вакытында бирелә торган мәһәр күләменең суммасы төрле: нигездә, 100-500 сум аралыгында булган, әмма 100 сумнан кимрәк мәһәр бирү очраклары да бар. Бу – шул чор татар авылларындагы уртача мәһәр күләме. Базарлы Байсар авылы әлеге яктан баерак. Анда 600 яисә аннан да артыграк мәһәр бирүчеләр бар.

Шушы елларда Мәчти авылы мәхәлләсенең метрикасын тутырып баручы – указлы имам-хатыйб һәм мөдәррис Мәүләви Җәләлетдин мелла Әхмәдҗан улы Кутлин. Авылда ике уку йорты эшләгән: аның берсе мәчет каршындагы башлангыч мәктәп, икенчесе – мәдрәсә. Соңгысында укучылар инде үзләре мулла булып киткән. Метрикалардан аңлашылганча, авыл укытучысы да – Мөхәммәдзариф Солтанов.

Мәчти авылы Солтановлар фамилиясе белән данлыклы, шуларның бер вәкиле – бишенче мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов (1837-1915). М.Әхмәтҗанов Мөхәммәдьяр Солтановның тулы бер шәҗәрәсен болай күрсәтә: Туксаба – Шаһвәли – Тәвкил – Тәңребирде – Йулбирде – Акйул – Котлыш – Күзәй – Тотар – Чупан – Мәмәт – Солтан – Габделҗәлил – Баязит – Мөхәммәдшәриф – Мөхәммәдьяр.

Никахлар

Актаныш төбәге авылларының аралашу даирәсе, никахлашу географиясе – кызыклы бер тикшерү объекты. Бай катлам, бигрәк тә дворян титулындагылар яисә имамнар, еракка булса да, кызларын үз дәрәҗәсендәге кешеләргә бирергә тырышкан. Мәчти авылында яшәгән дворян Солтановларның да кызлары, кияүгә чыгып, еракка киткән. Мисал өчен, дворян Шәйхелзаман Солтановның кызы Бибирәхимә Бәләбәй өязендәге морзалар Каргалысының (хәзерге Оренбург өлкәсендә) дворян титулындагы Сәлимгәрәй Мөхәммәдгәрәй улы Чанышев белән никахлаша. Бу авыл кешеләре Минзәлә өязендәге башка бик күп авыллардагы егет һәм кызлар белән гаилә корган. Мәсәлән, Чурпакай, Яхшы, Яңа Байсар, Апач, Кармыш, Аккүз, Тактала-чык, Пучы, Шәмәк егетләре Актанышбаш, Иске Гәрәй һәм үз өязендәге башка авыллардан кала, Бөре өязе кызларына да өйләнгән. Метрика язмаларыннан, Байсар авылы зур булганлыктан, бу авыл кешеләренең, үз авылы эчендәге никахлардан тыш, шул ук өяз авыллары, хәтта Казан өязенең Мәңгәр егет-кызлары белән дә гаилә корганын күрәбез.

***

Актаныш төбәгенең метрика язмалары әле яңа гына өйрәнелә башлады. Киләчәктә, комплекслы эзләнүләрдән соң, бу юнәлештә билгеле булмаган яңа фактлар ачылыр һәм кызыклы нәтиҗәләр ясалыр дип уйлыйм. ■

Безнең мирас №3 март 2021

Туган тел – изге тел

Мәҗит Гафури

Бетмәдек без

Бетмәдек без, без тереслдек, инде мәңге бетмәбез,
Инде юл ачтык хакыйкатькә таба, без салдык эз.
Бик матур бер моң белән безгә карап кемдер дәшә:
«Әй татар, яшисең инде, мең яшә, мәңге яшә!..»

Зөлфәт

Туган тел хакында

Тел ачылгач әйтә алсаң: «Әни!» – дип,
Тел ачылгач әйтә алсаң: «Әти!» – дип, –
Күзләреңә яшьләр тыгылмас,
Туган телең әле бу булмас.

Соң минутта әйтә алсаң: «Әни!» – дип,
Соң минутта әйтә алсаң: «Әти!» – дип, –
Күзләреңә яшьләр тыгылыр,
Туган телең әнә шул булыр...

Ләбиб Лерон

Теләк

Бары илем, телем белән
Бәхетле була алам.
Илемнән дә, телемнән дә
Аера күрмә, Аллам!

Наҗар Нәҗми

Татар теле

Туган җирең – Идел буе,
Һәр телнең бар туган иле.
Туган җирең кебек назлы,
Җырдай моңлы татар теле.

Ак алъяпкыч бәйләсәләр,
Өзелеп тора кызлар биле.
Кызлар кебек шат чырайлы,
Ачык йөзле татар теле.

Халкың кебек уңган да син,
Хезмәттә син көне-төне.
Ир-егетләреңдәй дәртле,
Гайрәтле син, татар теле.

Фәннән сине аерса да
Гасырларның афәт җиле,
Аксакалларыңдай олпат,
Акыллы син, татар теле.

Ассалар да, киссәләр дә,
Үлмәдең син, калдың тере.
Чукындырган чагында да
Чукынмадың, татар теле.

Яндың да син, туңдың да син,
Нишләтмәде язмыш сине.
Дөньяда күп нәрсә күрдең,
Әй мөкатдәс Тукай теле.

Төрмәләргә дә яптылар
Җәлил белән бергә сине.
Төрмәләрдә дә килмешәк
Булмадың син, татар теле.

Зинданнарны ярып чыктың,
Ялкынланып чыктың кире.
Хәтта фашист тегермәне
Тарталмады анда сине.

Кабатланмас үткәннәрең –
Гасырларның яман чире.
Кабатлар сине гасырлар,
Татар теле, дуслык теле. ■

Безнең мирас №3 март 2021

Минзәлә сөйләше

Олег Хисамов

Башкортстан Республикасының Туймазы районындагы Түбән Әмәнәк авылы кешеләре

Татар теленең иң зур диалекты булып саналган урта диалект үз эченә зур территориядә, Татарстан һәм Башкортстан Республикаларында һәм аларга якын булган төбәкләрдә – Казан артыннан башлап Чиләбе, Курган һәм Оренбург өлкәләрендә таралган күп санлы сөйләшләрне ала. Урта диалект вәкилләре – Казан татарлары Идел буе болгарларының варислары булып исәпләнә һәм алар үзләренең борынгы бабалары биләмәләрендә яшиләр.

Урта диалект сөйләшләре системасының катлаулы булуы байтак кына тарихи сәбәпләргә бәйле: Идел буе болгарларының җирле кыпчак кабиләләре тарафыннан ассимиляцияләнүе, күрше фин-угыр, төрки, славян халыклары белән үзара тәэсир итешеп яшәүләре, бу халыкларның татарлар тарафыннан өлешчә ассимиляцияләнүе, татар халкының бер өлешенең дини яктан изоляцияләнүе, аерым этник төркемнәрнең төп массадан территориаль ерак торуы, соңгы чорларда мишәр диалекты йогынтысының артуы һ.б.

Диалектларның нигезендә – кыпчак теле

Хәзерге вакытта урта диалект (Казан татарлары) **Казан арты** (Әтнә, Лаеш, Балтач, Мамадыш, Дөбьяз), **Тау ягы** (Кама Тамагы, Яшел Үзән, Тархан – Идел һәм Зөя елгалары арасы), **керәшен татарлары** (Казан арты, Түбән Кама сөйләшләре – Татарстан һәм Башкортстан Республикаларының чиктәш районнары, Чиләбе өлкәсендәге нагайбәк), **Бәрәңге** (Мари-Эль), **Минзәлә** (Татарстанның көнчыгыш, Башкортстанның көнбатыш районнары), **Бөре** (Башкортстанда Агыйделнең урта агымы), **Нократ-кистем** (Киров өлкәсе һәм Удмурт Республикасы), **Касыйм** (Рязань өлкәсе), **Пермь** (Пермь өлкәсе), **Златоуст** һәм **Красноуфим** (Башкортстанның төньяк-көнчыгыш районнары, Свердловск өлкәсе), **Эчкен** (Курган һәм Чиләбе өлкәләре) сөйләшләренә бүленә.

Соңгы еллардагы фәнни тикшеренүләр һәр диалектның татар әдәби теле формалашуындагы ролен төгәлрәк билгеләргә мөмкинлек бирде. Татар диалектологлары барлык татар диалектларының да нигезен борынгы кыпчак теле тәшкил итә дигән нәтиҗәгә килде. Кыпчаклардан тыш, татар халкының аерым этник төркемчәләре формалашуында угыз кабиләләре дә әһәмиятле роль уйный. Билгеле булганча, Идел һәм Җаек буйларына кадәр таралган угыз кабиләләре XI гасыр уртасында кыпчаклар тарафыннан кысрыклап чыгарыла.

> **«Барлык татар диалектларының да нигезен борынгы кыпчак теле тәшкил итә.**

М.И.Әхмәтҗанов «Шәҗәрә материаллары буенча Ык елгасы бассейнында барган этнолингвистик процесслар» дигән мәкаләсендә, монголлар басып алганчы, бу җирләрдә болгарлар һәм угырлар яши, дип яза. Угырларның бер өлеше көньяктан килгән кыпчаклар тәэсирендә төньякка һәм төньяк-көнчыгышка таба кузгала, ә икенче бер өлеше, кыпчак телен кабул итеп, яшәгән урыннарында кала.

1552-1557 нче еллар вакыйгаларыннан соң Казан һәм Казан арты халкының бер өлеше, басып алучыларга буйсынырга теләмичә, Ык елгасы бассейнына күчеп утыра.

1652-1657 нче елларда Кама аръягы ныгытмаларын төзү башлана. Әлеге эштә катнашу өчен Казан яныннан һәм көнбатыш өлкәләрдән татарлар күчерелә. Шул рәвешле, XVII гасырда бу җирләрдә кыпчак-нугай чыгышлы татарлар күпчелеккә әйләнә.

Җир биләмәләренә мөнәсәбәтле рәвештә, әлеге территориянең (хәзерге Башкортстан Республикасының көнбатыш, Татарстан Республикасының көнчыгыш районнары) халкы 3 социаль катламга бүленә: типтәр, Казан кешеләре һәм башкортлар. Әлеге катламнар арасында башкорт катламы иң югары дәрәҗәдә була. Казан кешеләре һәм типтәрләр дәүләткә генә түгел, җир биләүче башкортларга да бәйле булалар. Җирләре булмаган типтәрләр һәм Казан кешеләре төрле юллар белән өстенлекле башкорт катламына керергә омтылганнар. Ә иң күп санлы катламны типтәрләр тәшкил иткән.

XVIII-XIX гасырларда фәнни әдәбиятта типтәр-бобыль катламында кайсы этник төркемнең өстенлек итүе хакындагы бәхәсләр күтәрелеп тора. Игътибар итегез: бу факт типтәрләрнең (шулай ук башкортларның да) аерым бер милләт түгел, ә бәлки, социаль төркем генә булганлыкларын күрсәтүче дәлил. П.Рычков, П.Небольсин һәм П.Кеппен хезмәтләрендә типтәрләр арасында татарларның күплеге ассызыклана. Шуңа да карамастан, бары тик XX гасыр башында гына татар теле белгече, этнограф Гайнетдин Әхмәрев типтәрләрнең күбесе татарлардан дигән нәтиҗәгә килә.

«Төньяк-көнбатыш диалект» юк! Ул – татар теле!

Соңгы елларда Уфа галимнәре башкорт теленең «төньяк-көнбатыш диалект»ын аерып чыгарып, татарлар тупланып яши торган төбәкне «башкортлаштырырга» омтылалар. Бу төбәктәге татарларның тел үзенчәлекләрен беренче булып фәнни яктан рус галиме А.Г.Бессонов өйрәнә. 1881 елда аның «О говорах Казанского татарского наречия и об отношении его к ближайшим к нему наречиям и языкам» исемле хезмәте басылып чыга. Анда галим татар сөйләшләрен Казан татарлары сөйләше белән чагыштыра һәм алар берберсеннән аерылмыйлар дигән нәтиҗәгә килә. Төбәктәге татар сөйләшләренең күпмедер дәрәҗәдә генә башкорт теленең һәм мишәр сөйләшенең тәэсирен кичергәнлекләрен ассызыклый. А.Г.Бессоновның әлеге фикере дөреслеген территориядәге сөйләшләрне махсус өйрәнгән галим Д.Б.Рамазанова материаллары да раслый. Галимә Башкортстанның көнбатышында таралган сөйләшләр, күпмедер дәрәҗәдә, мишәр диалекты тәэсирендә формалашкан дигән нәтиҗәгә килә.

Шушы төбәктә киң таралыш алган, Минзәлә сөйләшенең фонетик үзенчәлеге саналган «d» тартыгын А.Г.Бессонов татар әдәби телендә кулланылышта булган «д» тартыгы белән тәңгәлләштерә. Сүз уңаеннан шунысын да әйтеп китәргә кирәк: әлеге авазны без үткән гасырның 50 нче елларында Казан артыннан һәм Тау ягы районнарыннан язып алынган диалектологик текстларда да очратабыз. Ягъни бу аваз Минзәлә сөйләшендә генә түгел, урта диалектның башка сөйләшләрендә дә булган икән.

1898 елда тюрколог Н.Ф.Катанов 3 ай дәвамында Бәләбәй өязендәге сөйләшләрне тикшерә. Ул мондагы халыкның сөйләше икегә аерыла: өязнең көнчыгышында – башкорт сөйләшләре, көнбатышында татар сөйләше таралган дигән нәтиҗәгә килә.

Бу мәсьәләдә совет тюркологы, башкорт теле һәм диалектологы А.А.Юлдашевның да фикерләре кызыклы. Бөтен гомерен шушы эшкә багышлаган галим «төньяк-көнбатыш диалект»ны башкорт теленә кертеп карауны дөрес түгел дип саный. Галим әлеге сөйләшнең һәрвакыт татар теленең урта диалектына кергәнлеген ассызыклый һәм аның татар әдәби теленә якын икәнен искәртә, ул берничек тә башкорт теле системасына керә алмый дигән фикер үткәрә.

Лингвист-тюрколог Җ.Г.Киекбаев, үзенең тикшеренүләренә таянып, хәзерге башкорт әдәби теленең нигезендә ике – көнчыгыш һәм көньяк диалектлар ята дигән нәтиҗәгә килә. Ул өченче – «төньяк-көнбатыш диалект»ның барлыгын инкяр итә һәм бу җирләрдәге сөйләшләрне татар теленеке дип саный.

Алда искә алып киткән галимнәрдән тыш, Минзәлә сөйләшен өйрәнүгә Җ.Г.Алмаз, А.Ш.Әфләтүнов, Г.Х.Әхәтов, Ф.С.Баязитова, Л.З.Җәләй, Л.Т.Мәхмүтова, И.С.Насыйпов кебек галимнәр дә үз өлешләрен кертәләр. Әлеге галимнәр, бертавыштан, Минзәлә сөйләшенең татар әдәби теленә якынлыгын ассызыклыйлар.

Күрүебезчә, бу мәсьәләдә рус, немец, татар һәм башкорт галимнәре үз сүзләрен әйткән. Аңлашыла ки, «төньяк-көнбатыш диалект» юк! Ул фәкать татар теле, ягъни туган телебезнең Минзәлә сөйләше генә.

«Бу мәсьәләдә рус, немец, татар һәм башкорт галимнәре үз сүзләрен әйткән. Аңлашыла ки, «төньяк-көнбатыш диалект» юк! Ул фәкать татар теле, ягъни туган телебезнең Минзәлә сөйләше генә.

Сөйләшнең үзенчәлекләре

Шактый зур территориягә таралган Минзәлә сөйләше үзенең төп элементлары ягыннан бербөтен. Шул ук вакытта, периферик элементларны, лингвистик һәм экстралингвистик факторларны исәпкә алып, сөйләш **төп – Минзәлә, Әгерҗе, Янаул һәм Бәләбәй** урынчылыкларына бүленә.

Сөйләшнең фонетик үзенчәлекләре итеп, без инде югарыда күрсәтеп үткән интерденталь [d] авазының кулланылуыннан тыш *(Бed, сабан туйы, димәйбed, җийын дибed)*, сүз башында [й] тартыгы урынына [җ] тартыгын куллануны күрсәтәбез. Бу Минзәлә сөйләшенең генә түгел, ә урта диалектның төп үзенчәлеге һәм аның барлык сөйләшләрендә дә очрый. Мәсәлән, *җафрак* – яфрак, *җозак* – йозак, *җон* – йон, *җөрү* – йөрү һ.б.

Тартыклар системасы, гомумән алганда, әдәби телнекеннән аерылмый, татар әдәби теленә һәм татар теленең Казан ханлыгы чорында формалашып беткән Казан арты, Тау ягы сөйләшләренә бик якын тора. Бу аңлашыла да, Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, ханлыкның төп халкы үзләренең ата-бабаларының изге туфрагына килеп егыла. Мәгълүм ки, IX-X гасырлардан башлап Урал итәкләреннән Идел елгасы бассейнына иксез-чиксез кыпчак төркемнәре күченеп киткән була.

Үзенчәлек авазлар тәңгәллегендә генә чагылыш таба. Мәсәлән, кайбер сүзләрдә әдәби телдәге [д] тартыгы урынына яңгырау спирант [з] кулланыла: *бозай* – бодай, *Изел* – Идел, *казак* – кадак һ.б.

Сөйләштә әдәби телдәге *-ый/-ий* дифтонгы урынына *-ай/-әй* дифтонгы кулланыла. Шулай ук бу күренешне дә сөйләш өчен генә уникаль күренеш дип әйтеп булмый. Ул урта диалектның кайбер сөйләшләрендә һәм көнчыгыш диалектларда актив кулланыла. Шулай ук XX гасыр башына кадәр татар әдәби язма сөйләмендә дә була.

Кайбер грамматик үзенчәлекләр: мин, син алмашлыклары юнәлеш килешендә *мийә/сийә, миңә/сиңә* кулланылырга мөмкин. Мәсәлән, *Шул wахытта мийа қыстыбый китерде.*

Сөйләшнең тагын бер үзенчәлеге – анау//анаwу//анаwы//анаwу, монау//монаwу//монаwы//монаw күрсәтү алмашлыкларының кулланылуы. Кайвакыт *монау* алмашлыгына тартым кушымчасы өстәлеп, *монаусы* варианты барлыкка килә. Мәсәлән: *Монаусы матур.*

Минзәлә сөйләшендә үзенчәлекле сорау алмашлыклары да кулланыла: кем, ний, нәрсә//нәрсәкәй//нәстә//нәстәкәй//нийәстә//нийәстәкәй//нәмәрсә// нәмәрсәкәй; ничә, ничек, кайсылай, нихәлле, ник, нигә//нәрсәкәйгә//нәмәрсәгә// нийәстәкәйгә; күпме, қайа, қайан, қайчан//қачан, қайсы, нинди. Мәсәлән: *Нәрсәкәй сөйлиләр, бич йаза барасыз. Нийәстәкәй сора, шуны бирә ул.*

Кайбер торак пунктларда инфинитив *-мак, -ма, -мага* формалары *кирәк* модаль сүзе белән бергә кулланыла: *Төбә ничек буйамақ кирәк, изән буйап күз тондо. Запасқа әпәй алып чықма кирәк.*

***

Татар диалектлары, бер төркем үзенчәлекләре белән бер-берсеннән аерылып торуга карамастан, иң беренче чиратта, уртак билгеләр нигезендә милли телебезнең төп өлешен тәшкил итәләр. Диалект системасындагы үзенчәлекләр милләттәшләребезне бер-берсеннән аермый. Татар халкы, аерым этник һәм тел билгеләрен саклаган хәлдә, бер халык, бер кавем булып яшәвен дәвам итә. Төрле географик киңлекләрдә башка халыклар белән борынгыдан ук аралашып яшәү һәр диалектка, һәр сөйләшкә хас үзенчәлекләр туута сәбәп булган. Әмма әби-бабаларыбыз тел дигән олы мирасны саклап, башкаларның көчле тәэсиренә бирешмичә, безгә, бүгенге көндә яшәүче оныкларына, китереп җиткергән.

Кулланылган әдәбият:

1. Ахметзянов М.И. К этнолингвистическим процессам в бассейне р. Ик по материалам шеджере //Сборник научных статей и очерков. Т.1., ч.1. – Казань: «Ихлас», 2014. – С.170-187.
2. Бессонов А.Г. О говорах Казанского татарского наречия и об отношении его к ближайшим к нему наречиям и языкам // Журнал Министерства народного просвещения, ч. CCXVI. – СПб., 1881.
3. Катанов Н.Ф. Отчет о поездке, совершенной с 20 мая по 20 августа 1898 года в Белебеевский уезд Уфимской губернии // Уч. записки Имп. Казанского университета, год LXVII, кн. 7-8, июль-август. – Казань, 1900.
4. Киекбаев Ж.Г. Башҡорт диалекттары һәм уларҙың тарихына ҡыҫҡаса инеш // Ғилми язмалар. Башҡортостан дәүләт университеты. III сығарылыш. Башҡорт филология серияһы. №2. – Өфө, 1958. – Б. 41-78.
5. Рамазанова Д.Б. Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии / Д.Б.Рамазанова. – 2-е изд. – Казань: ИЯЛИ, 2020. – С. 208.
6. Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. – Казан: Татарстан китап нәшр., 2009. – Б.839.
7. Юлдашев А.А. К изучению говоров башкир Туймазинского района БАССР // БДС. – Уфа, 1959. – С.141.
8. Юлдашев А.А. Язык тептярей: дис. … канд. филол. наук. – М., 1950.
9. Юсупов Ф.Ю. Морфология татарского диалектного языка. Категория глагола. – Казань: «Фән», 2004. ■

Илсур Һадиуллин: «Татар кешесе үзенең кыйбласын сакларга тиеш»

Татар телен саклап калу өчен аны яратырга һәм телгә карата яхшы мөнәсәбәт булдырырга кирәк. Беренчедән, татарча сөйләшүдән куркырга кирәк түгел. Русча ялгыш сөйлибез, кушымчаларны дөрес әйтмибез икән, суффикслар төшеп калалар – моннан куркырга да, оялырга да кирәкми. Татар беркайчан да башка милләт булмый. Үз милләтеңне югалтып, үзеңнең телеңнән бизеп, кемгә дә булса ярарга тырышып, ниндидер калыпка кереп, шул җырны гына җырларга ярамый.

Телне ничек сакларга соң? Беренчедән, гаилә һәм мәктәпкә кенә сылтап калдырмаска кирәк. Шәһәрдә тусалар да, безнең балалар чын татарча сөйләшәләр. Татарча да, русча да, инглизчә дә иркен аралашалар. Гаиләдә татарча сөйләшмәсәләр, соңыннан сөйләшергә оялып йөрсәләр, татарча тапшырулар карамасалар, татарча газета-журнал укымасалар, интернет аша татар массакүләм мәгълүмат чараларын күзәтеп бармасалар, кызыксынмасалар, язучыларыбызны, җырчыларыбызны, рәссамнарыбызны белмәсәләр, кыйблаларын югалтсалар, әлбәттә, ул вакытта телебез дә югала.

Телне югалтмас өчен, һәр татар кешесе үзенең кыйбласын сакларга тиеш. Аның кыйбласы – ана теле белән кергән татар теле. Чувашларга ул – әлбәттә, чуваш теле, мариларга – мари теле, үзбәкләргә – үзбәк теле. Кайбер вакытта шаккатып карап торам: «Татарча укытырга, татарча белергә кирәк», – дип сөйләп йөриләр, ә үзләренең балалары да, оныклары да татарча белми. Аннан соң, акланып: «Балалар бакчасына, мәктәпкә барганда белә иде, шуннан соң онытты», – дип сөйләнәләр. Эшләмәс, телеңне белмәс, үзеңнең ялгышыңны башка берәүгә сылтап калдыру өчен әле ярый балалар бакчасы һәм мәктәп бар. Инде югары уку йортын да тәмамлагач, кемне гаепләргә? Хәер, тормышта да гаепләргә кеше табылып тора: йә хатынын, йә ирен, йә әби-бабайны гаепли башлый. Сөйләшергә урын, вакыт, мохит юк, ди. Авылдагы әби белән бабай безне үстергән инде. Оныкларны үстерү, ашату, карау-тәрбияләү, татарчага өйрәтү аларның миссиясе түгел. Әби белән бабай ярдәм итәргә генә мөмкин. Бездә: «Кем тапкан – шул баксын!» – дип әйтәләр иде. Ходай шулай насыйп итсен. Тапкансың икән, үзең үстер, тәрбиялә, телгә өйрәт, шунда инде беркемне дә гаепли алмыйсың: мәктәпне дә, балалар бакчасын да, әби белән бабайны да…

Рәмис Латыйпов *әңгәмәсеннән* ■

Җәүһәр иясе Җәүһәриягә

(Кыйсса)

Әхтәм Зарипов

Җирле үзидарә рәисен озаткач, үзем яшәячәк бүлмәне бераз үзгәртү турындагы эшләрне күрсәтеп, блокнотыма язып куйдым. Яту, йоклау турында уйга да китермәдем. Очрашу вакытында кемнәр белән ничек сөйләшүемне, кемнәргә ышанырга була, кемнәр ышаныч уятмавын хәтерләргә тырышып утырдым. Нәтиҗә куандырырлык, өметләнерлек иде. Уйлануларым, әлбәттә, өзек-өзек, узган гомерем турындагы хатирәләр белән аралаш булды. Җавапсыз калган сораулар исә киләчәк көннәремә кагылышлы иде. Ә аларны Газизәсез күз алдыма китерергә дә җөрьәт итмәгәнлектән, уйларымнан арынып өчен, шушы язмамны дәвам итмәкче була идем. Тик... Юк, булмый. Язылмый. Күз алдымда торган Газизә барысын да томалый. Аның һәр сүземә реакциясен хәтерләргә тырышам. Аларның һәркайсы ике катлы: тегеләй дә, болай да аңларлык. Үз ягыма борырга тырышам да туктап калам: нинди файда турында сүз алып барырга була?

Файда ни дә, зыян ни? Кемгә файда, кемгә зыян? Ә ул, әнә, йөри. Ни эшләгәнен белеп, миңа ничек тәэсир итүен белеп йөри. Азгын ханымның табигый кыланышымы бу, әллә яңгырга сусаган җирнең корылыктан яргалануы кебек, ялгызлыктан зарыккан яшь тәннең тынычлану өчен үзенә-үзе урын таба алмый хәрәкәтләнүеме? Кешелек дөньясы тәрәккыятькә ирешкән саен, үз табигатенә каршы килү ысулларын арттыра, үстерә барган. Безнең мисалны гына алыйк. Ышанам: безнең икебезгә дә нидер кирәк. Аны ул да, мин дә тоям. Тик кеше табигатендәге әдәп киртәсе: «Тукта, шашма», – ди. Ул яктан хайваннарның рәхәт: кирәк икән, тыелма.

Хыялларымны бүлдереп, капка төбенә Тәлгать машинасы килеп туктады. Рульдә үзе түгел, шоферы иде. Кабинасыннан төшеп, пассажир ишеген ачты да, аннан катыргы тартма алып, эчтә утыручыга: «Килеп җиттек», – диде. Зур юл сумкасын алып машинадан төшкән сакаллы кешене төрек кешеседер дигәнем дөрескә чыкты.

Шофер егет каршы алырга чыккан Газизәгә: «Бу тартмада азык-төлек, ә бу егет Сөләйман атлы төрек булыр. Тәлгать абый, калганын Газдә үзе белеп эшләр, дип әйтте», – диде.

Төрек, тартманы Газизә кулыннан алып, өйгә таба атлады. Ике кулында ике йөк булса да, сынатмады егет. Өйгә керделәр. Ә шофер егет, ачык тәрәзәдән карап торуымны күргәч:

– Тәлгать абый, районга барасы булса, барып кайтыгыз, дип әйтте, – диде.

Мин:

– Башка эшләр чыгарга тора әле монда, рәхмәт, – дидем.

Шофер китте. Без калдык: Газизә, мин һәм сакаллы төрек.

– Татарча беләсеңме, Сөләйман бабай?

– Минем инде монда дүртенче елым. Төрекчәмне онытмасам ярар иде дип куркам.

– Курыккач, онытмассың. Хатларыңны төрекчә язасыңдыр бит?

– Бездә хат язышу юк. Телефон.

– Юынырга дисәң, җылытырга баллонлы газ гына.

– Кирәкми, җылытмагыз. Бүген тәһарәт алганда юынган идем. Икендегә юынырмын. Суык су белән генә.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2021) санында.

– Ашау мәсьәләсе ничек?

– Уразада.

– Ураза ае узды ич.

– Ә мин казага калган көннәр өчен.

Төрекнең бу җавабы Газизәгә бик ошады булса кирәк, ул, Сөләйманга карап елмайды да: «Алла кабул итсен!» – диде.

Үз чиратында, Газизәнең сүзләре төрек күңеленә «бәлзәм» булып ятып, ул, җавапсыз калмас өчен генә: «Амин», – диде.

Сәхнә теле белән әйткәндә, шушы кечкенә эпизод бу ике җанның берберләренә мөнәсәбәтләрен, күңелләре тартылуын да ачык күрсәтте. Ходай, саклаганны саклармын, дигән. Сак булырга кирәклек кенә аз, сакчы булырга кирәк. Янәсе ул уразада икән. Газизәнең дин юлында кәсеп итүен кемнәндер ишеткән дә, әле килеп эш башлаганчы ук ишеткәненнән файда тапмакчы була. Уразаңның ныклыгын... карарбыз, Сөләйман. Имеш, ул хат язмый, телефон аша гына сөйләшә.

– Карале, кем, өйдәш, исемеңне Сөләйман диделәр шикелле, бу йортта ирләрдән син генә түгел, мин дә бар. Танышырга теләгең булса, мен югары.

– Гомергә югарыга менәргә омтылмадым. Танышырга дисәң, үзең төш.

– Ә мин гомер буе югарыга, үргә менәргә омтылдым. Тик әллә ни биеккә күтәрелә алмадым. Ярый, һәркайсыбыз үз биеклегендә очсын. Син прораб булсаң, мин шул төзеләчәк йортның хуҗасы Әдип Гаязович булырмын.

– Бик рәхмәт. Хуҗа булгач, минем таләпләремне тыңла: йорт тиз өлгерсен дисәң, миңа шушы авылдан өч ярдәмче ташчы ир, измә әзерләргә ике хатын-кыз кирәк булыр.

– Кирәк нәрсәләрегезне рәис белән хәл итегез.

– Алайса мин сиңа бүтән мөрәҗәгать итмәячәкменмени?

– Синең мөрәҗәгатең – эшләгән эшең. Һәр салынган кирпеч минем күздән узачак. Уйлап уйна, Сөләйман.

– Уйларга вакыт калса, уйларбыз да, уйнарбыз да, хуҗа әфәндем. Мине өркетүеңә генә өметләнмә. Без инде өркүдән узган.

Вакыт агымы агымсу кебек. Канәгатьлек белән әйткәндә, шушы сөйләшүдән соң Татлысуны тергезү буенча башланган эшләрнең һәркайсында чын эшләрнең гөрләп баруын күрергә була иде. Буа өчен чыгарылган ташларны ике КамАЗ ташый, буа буылып, су күтәрелгәч, мәчет күленә һәм Үлетатлысу күленә керергә тиешле чиста суүткәргеч юан бетон торбалар урыннарына китереп аударылган, канау казырга экскаваторлар килүен генә көтәләр. Ә инде бетон торбаларны урнаштыргач, ягъни күлләр туңгач, аларны ләмнән чистартуга кучәчәкләр. Барысы да акыл белән уйлап хәл ителгән.

Безнең эштә дә үзгәрешләр барлыгы сизелә. Татлысу елгасының суы хәзер күрән төстә түгел, ә саргылт. Министрлар Советының карары үтәлә башлау нәтиҗәсе иде бу. Район үзәгенә анализга пробиркаларны Газизә үз вакытында илтергә өлгереп, һәркөн мактауга лаек була башлады. Шунысы уңай, Газизәнең җиңел машина йөртү таныклыгы бар икән, почта ташучыга ялыныч юклык эшне бермә-бер җиңеләйтте. Йөрәк эшләре генә тотрыклы түгел. Көн саен булмаса да, ара-тирә чебен дулап тәрәзәмне ватмак була. Кичә кич белән генә белдем. Сөләйман, Газизәгә утырып, район үзәгенә барган, имеш, гаиләсенә банк аша акча салган. Ярый, салсын да ди, ләкин ни өчен Газизәгә утырып? Һәркөн почта машинасы да йөри, өстәвенә, Тәлгатьтә дә машина бар.

Газизәнең сүзе бер: «Утыртсаң, барыр идем, дигәч, утырттым инде». Район үзәге безгә 25 чакрым. 7 чакрым юл Теләпән каенлыгы аша уза. Юлда ни булмас та, кем нишләмәс. Шуннан соң ике көн үттеме, өчме, төнлә белән тышка чыгарга дип аска төшсәм, Газизә бүлмәсендәге ыңгырашуны ишетеп туктап калдым. Ачык ишетмәсәм дә, шуны аңладым: Газизә гарәпчә нидер сукалый, ә ир тавышы дога укыгандай гарәпчә җырлый. Бу инде, әлбәттә, бик тирәнгә яшерелгән конспирация иде. Ягъни ике гашыйкның бер-берләренә мәхәббәт хисләрен белдерү ысулы.

Нишләргә? Кинәт кереп, бер-берләренә беркетеп калдырыргамы? Әллә чыкканын көтеп торып фаш итәргәме? Анысына ни хакым бар? Ничә минут газапланганмындыр, берзаман «мырылдашу» тынгандай булды. Аларның гөнаһка керү мизгелләре иде бу. Теләсә ни булсын, тәвәккәлләп, ишекне шакыдым. Тынлык. Дәшүче юк. Keләсен суырмакчы булып, көч белән ишекне тартсам, ул, ачылып, башыма бәрелде. Түземлегем җитеп, бүлмәнең утын кабызсам, Газизә мендәрен каплап яткан, ә тегесе юк. Кай арада, ничек сызган? Балкон тәрәзәсе ашамы? Алай дисәң, Сөләйман бүлмәсенең тәрәзәсе юк. Кая яшеренергә мөмкинлеген Газизәдән сорарга дип, капланган мендәрен тартып алдым да иң хәлиткеч соравымны бирдем:

– Кая яшердең?

Газизә уянып җитмәгән иде.

«Ах-ух» итте дә:

– Яшермәдем, – дип, миңа Батулла тәфсирендәге Коръәнне сузды Алсаң – җиңелү була, алмасаң – гөнаһы зур.

– Сөләйманың кайда?

– Үзендә юкмыни? – дигән җавап ишетелде.

Тиз генә күрше бүлмә ишеген каерып ачсам, бүлмә буш, дивандагы әйберләр җәелмәгән. Бу хәл мине тәмам ярсытты. Димәк, простыняга простыня ялгап, тышка сикергән. Кабат Газизә янына кердем. Ә ул, берни булмагандай, тагын мендәренә капланып йокларга яткан. Бу юлы уятмадым, ышандырдым дип тынычлансын өчен, үз бүлмәмә күтәрелдем. Өстәлдә калган телефоныма күз салсам, анда кабул ителмәгән ике чакыру, Сөләйманныкы. Ни булса – шул, дип, үзем шалтыраттым:

– Мин бу. Нәрсә, әллә мактанасың килеп шалтыраткан идеңме миңа?

– Ясыйгъ намазыннан соң, детсад Фираяның буш бүлмәсендә генә кунып калуымны хозяйка Азизага төшеп әйтүеңне сорамакчы идем.

– Аның синдә, синең анда ни эшегез бар?

– Соң ул бит минем хозяйкам. Һәркайсыбызның бер-беренә эше дә, сүзе дә булу гаеп түгел. Әйе, гаеп түгел…

Шуның белән сүз өзелде. Газизәгә бу сөйләшү турында әйтүне кирәк тапмадым. Сөләйман шул калуыннан Газизә янына кайтмады. Күрәсең, сөйләшүләре телефон аша гына баргандыр.

Бер кичне сагыш басуга чыдый алмыйча, төн уртасында аның янына төштем. Ә ул тагын теге чактагыча сөяркәсе белән конспиратив телдә сөйләшеп ята. Кердем. Аптырамады Газизә.

– Тыңлыйсыңмы? Укып күрсәтәм, – диде дә моңлы бер көйгә дога укыды.

Мин, әлбәттә:

– Аңламадым, – дидем.

– Доганы аңлау түгел, тою кирәк, – диде Газизә. – Менә чагыштырып кара. Бу – Хаҗдан алып кайткан чын гарәп язуындагы дога. Тыңла.

Ул, диктофонына басып, ир кеше укуындагы доганы яңгыратты.

– Сөләйман түгелмени бу? – дидем.

– Мин аның исемен белмим, тавышы моңлы булуын гына ишетәм.

– Димәк, сиңа мәхәббәт түгел, ә моң гына кирәк.

– Миңа моңлы чын мәхәббәт кирәк.

– Ул синең каршыңда басып тора бит. Ник күрмисең?

– Мәхәббәт басып тормый, ул кешенең бөтен җанын, тәнен, холкын, акылын биләп ала да бөтенләй яңа кеше ясый.

– Мин яңа кеше түгелмени?

– Әгәр мин синдә яңа кеше күрсәм, мин үзем дә яңа кеше булыр идем. Тик мин әлегә искелекләрдән арына алмыйм. Яңалык тәвәккәллектән башланып, рәхмәт белән бетәдер ул.

– Тәвәккәллик соң...

– Мин инде бу юлда беренче адымымны ясадым. Бисмилла... Телефоныңда Җәүһәрия әбинең номерын җыеп, миңа бирсәңче.

– Нишләмәкче буласың?

– Мин, диктофонымны кабызып, сөйләшүебезне яздырып барам, китабыңны язганда кулланырсың, кулланмасаң, истәлеккә сакларбыз.

– Тиражы узган заем кәгазьләрен безнең әнкәй диварга беркетер иде. Җәүһәрия әбиең заем кәгазе дә түгел, лотерея билеты гына шул.

– Откан билет сакланмый, Җәүһәрия әбине отмаган билетка тиңләп булмый, ул синдә откан билет буларак сакланадыр.

– Сәясәтчеләр телендә сөйлисең, кызым, тәвәккәллегең шушы гына булса, мин өскә менәм.

– Өскә менәргә ашыгу тәвәккәллекнең башы булса да, менүе җиңелдән, төшүе кыен, диләр.

Телефонда Җәүһәриянең номерын җыеп, аны Газизәгә суздым.

– Алло, Җәүһәрия әби, синме бу? Вакытсыз шалтыратуыма гафу үтенеп, сине борчучы Әдип Гаязовичның фатир хуҗасы һәм хезмәттәше Газизә атлы 40 яшьлек тол хатын дип белерсез.

– Нигә тол дисез үзегезне? Әдип бабагызның яшь хатыны дисәгез дә, үпкәм юк.

– Ирең белән бергә яшәмәгәч, сине дә тол дип әйтеп булса да, мин чын тол һәм улын югалткан ана. Сүз минем турыда түгел, Әдип Гаязович хакында бара.

– Сүз буенча түгел, мин аны бергә яшәү тәҗрибәсе буенча беләм. Чын ир, сөелүгә лаек кеше ул. Аны рәнҗетергә ярамый.

– Ул үзе рәнҗетә шул, Җәүһәрия апа. Сәбәпсез көнләшүләре белән, урынсыз шикләнүләре, көтелмәгән гаепләүләре белән.

– Җилсез яфрак селкенми. Дөнья булгач, барысына да түзәсең, уздырасың инде, кызым.

– Уздыру авыр булганга, сиңа шалтыратырга булдым. Нишлим? Син килгәнче түзимме? Өзимме?

– Тилмертмә син аны, кызым, никах укытыгыз да бергә торыгыз.

– Миңа әле 40 та тулмаган, гәүдәм дә бала-чаганыкы кебек кенә. Ә ул бит… ул…

– Кибән астында тычкан үлми. Куркып торма, малай бүләк ит үзенә. Картлык көнебездә ул бала өчебезне дә бәхетле итәр. Мәрхүм улыбызның исемен кушарсыз. Вилдан дип.

– Аның миңа кызыгуы гына кушылырга сәбәп түгел бит, Җәүһәрия апа.

– Мин аңа бүген үк шалтыратып, никах укытуын үтенермен.

– Никах укыттык, ди. Ә син?

– Мин, Вилдан тугач, сезнең янга күчеп, дүртәүләп яшәрбез. Борынгыларча.

– Үз йорты өлгергәнче яшәп торырга коттеджымның иң зур бүлмәсен офис итсә дә, кунып калса да, риза булып аңа биргән идем. Бабаем соңгы вакытта минем бүлмәгә керүен ешайтты. Аның «керде дә ятты» холыклы түгеллеген сизенә идем. Шуңа күрә, сиңа шалтыратып, ачыктан-ачык сөйләшергә булдым.

– Мин инде, синнән дә уздырып, ачыктан-ачык әйттем. Тизрәк йортын төзетеп бетерергә ярдәм итегез. Бергә яшәргә кыенсынсагыз, мин шунда аерым яшәрмен. Балагызны, ягъни балабызны карармын.

– Нигә кыенсыныйк, ди, Җәүһәрия апа, көндәшем булсаң да, син миңа игелек фәрештәсе…

Элемтә шунда өзелде: пип-пип-пип…

Телефонымны бирүне көтеп торсам да, ул аны диктофон белән өстәл тартмасына салып бикләде.

– Нигә биклисең? – дидем.

– Һәрнәрсәдән шик эзләргә өйрәттең ич. Җуйдыруыңнан шикләнәм.

– Җуйдырмасам, кемгә һәм нигә кирәк булыр ул?

– Малаеңа.

– Минем малаем юк ич.

– Булмаса булыр. Бар, чишенеп, тәһарәт бүлмәсенә кер. Мин газны кабызып, суны җылыттым. Син, салкын су белән коенып, тынычлана тор.

– Син кушкач, Татлысуда коенырга да риза, Газизә, рәхмәт.

– Рәхмәтеңне Вилдан тугач әйтерсең.

– Аңа чаклы Татлысуның исеменә тиңләшерлек вакыт узуы кирәк шул әле.

– Алай димә, Әдип Гаязович, без вакыт коллары түгел, вакытны без үзебез ясыйбыз.

Шулчак Газизә өстендәге халатын тәненнән шудырып кына төшерде дә, анадан тума ялангач калгач, салкын душ астында коенып, мине дә үзенә таба тартты. Тартылгач ни булганын тасвирларга Мопассан теле кирәккә, моны мин укучының үзенә калдырам. Көче җитсә, ул үзе күңеле теләгәнчә хыялланыр, җитмәсә, салкын душ астында озаграк торып сүрелер. Безнең сүрелмәвебезне укучы күптән сизенгәндер инде. Әмма җомга көн кич белән мәрхүм улымның улы килеп керүе безне телсез калдырды.

– Ни булды, улым, әллә бабуляң белән бер-бер хәлме?

– Не знаю… Хәл ли это, или ЧП. Бабуля мине чакырып алды да менә шушы коробочканы монда китереп тапшырырга кушты. Срочно, никахларына кадәр өлгерергә кирәк, диде. Что это никах, не объяснила.

Мин бу кечкенә тартмада ни ятуын белә идем. Шулай да ачып карарга булдым. Газизәгә дә күрсәттем.

– Бу җәүһәрне миңа Пакистанда төпләнеп яшәүче мөселман татар эшмәкәре бүләк иткән иде. Никахлы хатыныңа, муенса ясап, үзең кидерерсең, диде. Мин, ярар, дип, вәгъдә бирдем. Вәгъдәмдә тордым. Бу – сирәк очрый торган Шри-Ланка диңгезендә табылган эре мәрҗәннәрдән җыелган муенса. Ул кемгә аталса, шунда булырга тиеш, улым. Һич кенә дә кыенсынмыйча аласың да, хуҗасына кайтарып бирәсең. Бабуляңа. Бабай, ягъни мин, картәтәң: «Җәүһәр Җәүһәриясендә булырга тиеш», – дип әйтте, диярсең. Онытма: Җәүһәр – Җәүһәриясенә! Шулаймы, Газизә?

– Сорап торасың тагы… Тагын шуны әйтсен: энҗе-мәрҗәннән дә кадерлерәк – Җәүһәрия апа үзе. Без аның үзен көтәбез. Әйтер шатлыгыбыз да булыр кебек.

– Бирсен Ходай, – дидем дә, оныгымны эшләрем белән таныштырып, чәй эчәргә өске катка менеп киттек.

Оныгыбызны, баш тартса да, тиешле күчтәнәчләр, чыгымнары өчен акча биреп озаткач, соңгы вакытта гаиләбездә булган һәм булачак үзгәрешләрне барларга булдык. Әмма ул үзгәрешләр бер утыруда гына санап бетерерлек түгел иде.

Үзгәрешләрнең куркынычы минем һөнәремә кагылышлы иде. Монда кайту алдыннан табигатьнең бозылып үзгәрүендә кеше гаепле булуны тасвирлаган әсәр язармын дигән ниятә идем. Йөри-йөри, күрә-күрә, утыра-тора яза торгач, ниятемдә яңалык юклык шиккә калдырды. Кем инде һәр җитешсезлектә кеше үзе гаепле булуны белми?! Юк, җәмәгать, табигать үзгәрмәде, табигатькә мөнәсәбәт кенә үзгәрде, кеше үзгәрде. Ә кеше үзгәрүнең сәбәпләрен ачу кәгазь-каләм алдың да яздың түгел. Дөньяда күпме кеше булса, шулкадәр холык. Һәр холык, тикшерә башласаң, үзе бер кыйсса, үзенә бер роман. Җәүһәриямне генә алыйк. Аның яшәве, тормышы үзе бер романлык. Газизәмә карыйк… Мин аңа белеп өйләнмәгәнмен икән. Асылда мин түгел, ә ул миңа өйләнгән. Аның язмаларымны укып, төзәтмәләр һәм өстәмәләр кертүе язмышымнан узарлык тәкъдимнәр иде.

Бу кыйссамны тәмамлауны Газизәгә тапшырырга булдым. Инде күп тапкырлар кабатланса да, тагын әйтми булмый: «Тәвәккәл таш яра», – диләр. Рәхим ит, Газизә, каләм синдә».

***

Укучыларга, кыйссаның автор язган кадерле вариантына өстәп, Газизәдән килгән хаттан өзекне дә тәкъдим итәбез.

«Кулыма каләмен тоттырса да, теләкхыялларын, ниятләрен яшермәсә дә, бер кеше башлаган көйне икенче кеше дәвам итә алмый. Һәр көйнең композиторы берәү генә була. Кыйсса да, хикәя яки роман да – бер кешенең күңелендә яралган көй ул. Безнең әдибебез Әдип Гаязович та бик зур күләмле симфония язып бүләк итмәкче иде. Авыл тормышы, андагы төрле вакыйгалар симфониянең өрлек баганалары булырга тиеш иде. Тик: «Человек предполагает, бог располагает», – диләр. Әдип агай күп эшләр эшләргә өлгерде. Татлысу елгасының суы хәзер инде чәй кайнатырга ярый. Тегермән буасы буылып, шлюзлары ябылып, чиста су мәчет күленә дә, Үлетатлысуга да тулып, чиста суда гына тереклек итүче тау фореле маймычларын җибәрүне көтә.

Улыбыз Вилдан инде чын авылча сөйләшә башлады. Җәүһәрия апаны, картый, дип, артыннан калмый ияреп йөри. Тик картыйсы гына бик бетереште. Әдип агайның яңа тегермәндә тарттырылган ак оннан тәбикмәк пешертеп ашыйсы килгән иде. Шул бодайны тарттырганда, әллә шатлыктан, әллә инде инсульттан… әллә картлыктан… вафат булды сүзен әйтәсе килми. Буага да, тегермәнгә дә «Әдип буасы», «Әдип тегермәне», «Әдип елгасы» диләр авылдашлар. Шул сүзләрне ишетүдән канәгатьлек табып, өчәүләп чәй эчәргә утырабыз, намаз укыйбыз, дога кылабыз һәм җирле үзидарә заказы белән коелырга һәм Тегермән тавына куелырга тиешле һәйкәлнең проекты экспертлар аша үтеп, сынчыларга җибәрелүен көтәбез. Әдип Гаязович каршы булган нәфел сәдакасы өчен куелган почта ящигы инде ике мәртәбә тулып, өченче мәртәбә куелган. Тәлгать абыйның әйтүенә ышанганда, һәйкәл өчен акчаны инвестор үзе күчерәчәк икән. Ул: «Әдип Гаязович васыятьләре үтәлергә тиеш», – дигән. Без, әлбәттә: «Амин, бирсен Ходай!» – дибез. Җәүһәрия апа гына, улыбыз Вилдан янына җирләнмәгәч, авылдашларга үпкәлим, дип елый. Тегермән үзе һәйкәл ич, урыны мәчет мәйданында булуны сорарга кирәк, ди.

Нишләмәк кирәк, үлем үкенечсез булмый. Әмма Әдип Гаязовичның эшләре үкенергә урын калдырмый.

Сез бастырып чыгарачак бу тәмамланмаган кыйссасы аңа дога булып ирешсә иде. Амин.

Җәүһәрия, Газизә, Вилдан». ■

Хаҗи Абдулла Дубин

Абдулла Дубин телевидениедә диктор булып эшләвен болай искә ала: «Татарстан телевидениесенең ачылуын 1959 елның 3 ноябре – Ш.Усманов урамындагы хәзерге телестудия тапшырулар алып бара башлаган көн белән бәйләп йөртәләр. Чынлыкта исә Казанда иң беренче ТВ тапшырулары 1955 елның 27 февралендә башланып киткән. Беренче ТВ студиясе Татарстан дәүләт музееның дүртенче катындагы бүлмәдә (янгыннан соң музейны ике катлы гына итеп реставрацияләделәр) булган. Күпмедер вакыт студия радиоҗиһазлар заводы бинасында да эшләп алган.

Мин – Әстерхан ягыннан. Гаиләдә ундүртенче бала булып дөньяга килгәнмен. Дикторлык хезмәтемне исә туган ягымда башлап җибәрдем. 1961 елда Әстерханда телевидение ачылган иде. Шул ук елны, укытучыларым – үзебездәге ТВ хезмәткәрләре тәкъдиме белән, Казан театр училищесына укырга килдем. Имтиханнар арасында Татарстан радио-телевидение комитетына да барып кайттым. Комитетның ул вакыттагы рәисе Михаил Филлипович Долгов һәм аның урынбасары Фәтхрахман Фазылҗан улы Фазылҗанов мине нәкъ 13 ноябрьдә эшкә чакырды.

Һәр тапшыру безнең өчен бер зур бәйрәм кебек булды. ТВ хезмәткәрләренең эш хакы аз булуга карамастан, монда чын энтузиастлар эшләде. Ул вакытта бары тик дикторның гына эфирга чыгарга хакы бар иде. Ә калганнар – журналистлар, хәбәрчеләр, техник хезмәткәрләр безнең өчен генә эшләгән кебек килеп чыга иде. Мин, мәсәлән, балалар өчен тапшыруны төгәлләгәч, музыкаль тапшыруларны башлап җибәрәм. Без ул елларда универсаль академия үттек, дисәм, һич арттыру булмастыр.

Хезмәтебез яңа булганлыктан, аны аңлаган кешеләрнең фикерләрен ишетү безнең өчен зур мәртәбә иде. Күренекле артистларыбыз Хәлил Әбҗәлилов, Николай Якушенко һәм Халит Кумысниковларга, эшчәнлегебезнең кимчелекләрен әйтүләрен үтенеп «бәйләнә» идек. Могтабәр режиссер Гали Хөсәеновның ярдәме зур булды. Безгә мактау кирәкми, бары тик үз киңәшләрен, тәкъдимнәрен генә әйтсеннәр, җитешсезлекләрне күрсәтсеннәр. Эшкә шулкадәр җитди караганбыз, күрәсең».

Заһид Фәйзи, *язучы:*

«Мәктәптә укыган елларында ук аның китаплары арасында төрле-төрле матур шәһәр күренешләрен, үзенчәлекле архитектуралы биналарны һәм корылмаларны чагылдырган фотолар, открыткалар туплана башлый. Тора-бара ул аларның эстетик яктан гына түгел, тарихны белү ягыннан да әһәмияткә ия булуын аңлап, бу мавыгуын җитди максатка әйләндереп, үзе туып-үскән Әстерхан һәм башкалабыз Казанга караган тарихи открыткаларны җыю эшенә керешә.

Тырышкан таш яра, дигәндәй, кырык еллап алып барган җентекле тырыш хезмәтнең җимешләре дә искитәрлек! Хәзер Абдулла Дубинның коллекциясендә башкалабыз Казанга, Әстерханга һәм Идел буена караган меңнән артык фото һәм открыткалар бар!

Халкыбызының рухын сафландыру буенча да изге гамәлләре байтак аның. Ул, хаҗи буларак, сүрәләрне тәфсилләп, матбугатта дини бәйрәмнәребез һәм истәлекле көннәр турында мөселман календарьлары төзеп чыгара. Шуларның барысын искә алып, Абдулла хаҗи Дубинны талантлы диктор һәм мәгърифәтче дә дияр идем мин».



Әстерхан шәһәре. ***Хаҗи Абдулла Дубин тупланмасыннан***

Редакциядән: *Даими авторыбыз Абдулла Ибраһим улы Дубинга 26 мартта 80 яшь тула. Аны гомер бәйрәме белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек һәм игелекле эшчәнлегендә уңышлар телибез!* ■

Безнең мирас №3 март 2021

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

Сеул. Базар күренеше. XX гасыр башы

Кореяда японнар

Японнар бүгенге көндә Кореяны инде үз җирләре иткәннәр. Бар җирен тимер юллар белән уратып алганнар. Сугыш елларында вакытлыча дип кенә бик кечкенә машиналар үтәрлек юллар ясалган булса да, сугыштан соң инде котчыккыч гаскәрне күчерерлек, искиткеч дәрәҗәдә нык юллар салганнар. Яр буйларында исә гаҗәеп дәрәҗәдә төзек портлар, шәһәрләрдә трамвайлар, телефоннар, телеграфлар, почталар шундый итеп тәртипкә салынган ки, Япониядә ничек булса, монда да шулай ук. Биредә тагын да төзегрәк, тагын да матурырактыр да әле. Гомумән, японнарның сәясәтләре шундый: эксплуатацияли торган җирләрен тагын да ныграк төзекләндерәләр.

Японнар Кореяда бик тырышып, биредә үз киләчәкләрен тәэмин итү өчен кирәк бөтен нәрсәне күздә тотып, ни таләп ителсә, шуны булдыралар, бар көчләрен, гайрәтләрен бу эшкә сарыф итәләр, рух күтәренкелеге белән көнне төнгә ялгап хезмәт итәләр, бар җирне төзекләндерәләр.

Инде Пусаннан Шинксор Анто дигән җиргә кадәр гаять киң һәм нык тимер юл сузылган, тиздән бу юл Мукден тимер юлына тоташачак. Әлегә Антоки белән Мукден арасында теге тар юл буйлап кечкенә машиналар йөреп тора. Юлны өч көндә үтәләр.

Бүгенге көнгә Япониядән Кореяга бер миллионга якын гаилә күчәргә тора икән.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

Кореяда чит ил халкы

Сәбәп нәрсәдәдер – төгәл генә әйтүе кыен, ләкин ни генә булса да, шул бик ачык күренә: Кореяда чит ил кешесе аз. (Чит ил кешесе аз, дигәндә, сәүдәгәр аз диюем, югыйсә ул хәшәрәт миссионерлар аз түгел.) Биредә җәелеп китеп сәүдә итү өчен мөмкинлек булмавы бик ихтимал. Булса да, японнар кулында. Кореяда Кытайдагы кебек чит ил сәүдәгәрләре юк яки бик аз.

Беренчедән, корея халкында бизәү, матурлау дигән нәрсә юк; икенчедән, Кореяда алынган уңыш аның үзен тәэмин итәргә җитә, менә шул сәбәпле, күрәсең, чит ил малына урын юк. Корея халкында ир-ат һәм хатын-кыз киеме ак төстәге батисттан тегелә. Башка төрдәге кием дә бар, ләкин бик сирәк очрый. Гел актан киенәләр. Өйләрдә-фәлән купшылык турында сүз дә булуы мөмкин түгел, бу яктан хәтта гади генә чыгымга батырчылык итү дә күренми. Кореяда гадилек халкының табигатеннән килә дип әйтер дәрәҗәдә ачык күренә. Болар японнардан да гадирәк. Японнар һичьюгы өйләрендә кайбер нәрсәләр тота, япон хатынының үз гомерендә һичьюгы бер-ике ефәк билбавы була, дәрәҗәле гаиләләрдә купшылыкка да бераз урын бирелә. Тик корея кешесенең өендә купшы-зиннәтле дип әйтерлек берни күрмәссең. Ул ак батисттан бер җөббә кебек нәрсә тегә дә берничә ел шуны кия, хатыннары да шулай. Һич булмаса, туйлары чыгымлыдыр, дисәгез, анысы да юк. Шулай булгач, чит ил тауары өчен базар юк. Агач сәүдәгәре төзелеш агачы алырга килергә мөмкин, әмма ул да бик сирәк. Зарури ихтыяҗлар өчен кирәкле бөтен нәрсәне японнар җитештерә һәм, гомумән, Кореяда чит ил малының япон малы белән көндәш була алмавы бик ачык аңлашыла. Шул рәвешле, биредә чит ил кешесенә файда китерерлек берни дә юк.

Капитал ияләре

Кореяда капиталга ия булган берәү дә юк, ди. Миллионер-фәләнне әйтәсе дә юк, һичьюгы берничә йөз меңгә ия булучылар да бармак белән генә санарлык, алары да төзелеш агачы белән сәүдә итүчеләр арасында икән.

Элек булмаган инде, хәзер дә юк, киләчәктә булуы да бик мөмкин кебек күренми. Моның сәбәбе: бераз тормышын яхшыртып, аның яхшы икәнлеген беленерлек итү боларда ямьсез күренеш санала. Корея кешесенең бер бик хикмәтле үзенчәлеге бар: эштән курыкмаулары. Болар сызланмас, уфтанмас, берәүгә дә иелеп рәхмәтләр укымас, теләнмәс.

Корея кешесе, тамагы тук булса, башка берни турында да уйланмый. Озаклап уйлану, гомумән, боларның табигатьләрендә юк бугай. Шул сәбәпле, бу милләттә капиталга ия кешеләрнең киләчәктә дә барлыкка килү ихтималы бик юк. Мин бу фикерне Сеулда бер япон кешесеннән ишеттем.

Әхлак

Бу яктан да корея милләте кирегә тәгәри, «начарлыкларның анасы» булган исерткеч эчемлек боларны бетергән. Бар яклап бетерә барып, әхлакларын да бозган. Элекке заманнарда корея кешесе һич кенә дә ялган сүз сөйләми торган булган. Хәтта шундый хәлләр дә очраган: берәрсенең ялганлавы фаш ителсә, атасы аннан ваз кичкән, баласы дип танымаган. Хәзерге вакытта ялганлауның тарала баруы турында үзләре үк аптырап сөйлиләр. Фахишәлек элек һич булмаган, соңгы ун ел

эчендә ул да барлыкка килгән һәм шактый таралган.

Мин Кореяда бик аз вакыт яшәдем, әхлак мәсьәләләрен ишеткәннәрем белән чагыштырып, тикшереп карый алмадым. Телләрен дә белмим. Шулай да Сеулда яшәүче японнар ярдәме белән бераз мәгълүмат туплый алдым. Сөйләүләренә карaганда, корея милләтенең киләчәге бик өметсез. Хәтта шул дәрәҗәдә ки, бер корея кешесе бөтен мәмләкәтен бер шешә аракыга сатарга, ягъни шулкадәр түбәнлеккә төшәргә мөмкин. Бөтен миссионерлар да корея кешеләрен христианлаштыру өчен шул исерткеч эчемлекне корал иткән. Бер миссионер беркөнне кичен берничә корея кешесен – ирен-хатынын бергә утыртып сыйлый, күпме теләсәләр, шулкадәр эчертә, барысын да исертә. Икенче көнне иртән баш авыртуыннан тилмергән бу кешеләргә бер тустаган эчемлек өчен христианлык тәкъдим итә. Риза булучының исемен шунда ук дәфтәренә терки дә бер тустаган аракы бирә.

Никадәр җиңел юл! Мондый хәлне бурятлар арасында йөргәндә дә ишеткән идем инде. Шунысы бар: бурятлар соңгы елларда бераз акылларын башларына җыйганнар, Русиядә хөррият игълан ителүгә үк, христианлыктан кире мәҗүсилеккә кайтканнар. Корея кешеләре исә, киресенчә, гел күпләп күчәләр генә. Ул гына да түгел, христианлыкны кабул итүгә, һәртөрле начарлыкларга да күнегәләр. Башында акылы калмаслык дәрәҗәдә эчеп исергән көннәре дә була икән.

Мин Корея илен бер атна гиздем. Бу милләтнең киләчәге белән бәйләнешле өмет тудырырлык берни дә күрмәдем. Бәлки, Корея ил атамасы булып сакланып та кала алмас, аның бер өлкә исеме булып кына калуы да мөмкин: Япониянең Корея өлкәсе. Гомумән, инде шулай булырга тора. Корея милләтенең мәнфәгате дә башка төрле була алмас, японнарга кушылсалар, аларның яклавында, ихтимал, әле тагын беркадәр яши алырлар. Мөстәкыйль булып калсалар, һәрвакыт куркыныч астында яшәячәкләр. Корея милләте өчен иң дөрес, иң инсафлы, иң якын һәм кечкенә дәүләт күз алдына китерергә мөмкин булса, бу – японнар, чөнки японнар корея милләтенең рухи халәтен шактый яхшы аңлыйлар, шул ук вакытта аларның шәхси мәнфәгатьләре өчен дә ярдәм итә алырлар, дин һәм раса уртаклыклары да бар.

Япониянең фикер иясе Принц Ито болай дигән: «Корея милләтенең яшәве японнар кулына әманәт ителгән. Японнарның вазыйфасы – әманәтне саклау белән бергә, Корея халкының яшәешен япон халкының яшәеше белән берләштерү, чөнки Кореяның булуы Япониянең киләчәген тәэмин итә».

Сеулда яшәгәндә, күпме генә тырышып эзләсәм дә, русча белгән бер генә корея кешесен дә тапмадым. Японча белүче бик күп кеше белән танышсам да, аларның күбесе Япония сәясәте яклы булганга, миңа биргән мәгълүматларының дөреслеккә туры килмәү ихтималы бар иде. Әйтергә теләгәнемне япон телендә бөтен нечкәлеге белән әйтеп бирә алмавым җанымны гел тырмап торды. Корея халкы арасында минем фикерләремне кабул итмәүче төркемнәр бармы-юкмы – менә шуны бик белергә тели идем, кызганыч, моңа ирешеп булмады.

Сеулдан китәм

Китәм, ләкин йөрәгем һаман Токиодагы тугры дусларыма бәйләнгән иде, аларның да миңа булган ихтыяҗлары һәм дуслыкларының кыйммәтен аңлап, мөнәсәбәтебезнең өзелмәвен, шайтан вәсвәсәсенә дучар булмавын теләп уйлана идем. Шул сәбәпле, тагын бер көнгә калып, аларга хат язып салырга һәм аннан соң юлга чыгарга карар бирдем.

Сеулдан Токиога

«Бер һәм бердәнбер Аллаһка хәмед, пәйгамбәрләрнең соңгысына (с.г.в.) дога һәм сәлам.

Кадерле кардәшем Мөхәммәд Бәрәкәтуллаһ Сахиб (Аллаһ аны сакласын һәм исәнлек бирсен)!

Инде безнең, кадерле кардәшем, бөтен эшләрдә дә пәйгамбәребезнең (с.г.в.) эзеннән тайпылмыйча баруыбыз шарт, чөнки ул барган юл – иң яхшы тәрбия бирүче, иң самими өйрәтүче юл. Үз кавемен хак юлга чакырганда, алдына чыккан каршылыклар һәм газапларга түзүе безгә матур үрнәк булып тора. Кадерле Ватанынннан һиҗрәт иткәнгә кадәр сабыр булып түзүе һәм: «Әгәр синең халкың мине чыгармаса, мин синнән чыкмас идем, сине калдырып китмәс идем, әй Мәккә!» – дип әйткән сүзләре безгә җитә. Нәкъ менә бу – мөселманнарның фикер дөньясының иң бөек тәрбиячесе. Бигрәк тә без ераклашкан рухларны җәлеп итү, төрле җәмгыятьләрнең калебләрен җылыту, аларны үзләреннән башкаларга карата бер йодрык итеп берләштерү һәм моңа охшаш тагын бик күп мөһим чаралар кабул итү, калебләре җылынганнарга дусларча мөгамәлә күрсәтү кебек эшләрнең башында торабыз.

Рәсүлуллаһ (с.г.в.) үз кавеме арасында кыюлыгы иң өстен булганы, алар белән бергә яшәүдә иң юмарты, күршелектә иң хәерлесе, җаһиллеккә каршы иң сабыры иде. Баштарак, хәтта айлар, еллар үтсә дә, Рәсүлуллаһ (с.г.в.) җыелышлар вакытында үз чакыруын бик ачып салмый иде. Мөселманнар арасыннан гыйбадәт кылырга теләгән кешеләр, Мәккәдәге берәр тау куышына барып, шунда яшерен гыйбадәт кылалар иде. Мөселманнарның саны артканга кадәр бу шулай дәвам итте. Аннан соң хаким һәм галим Аллаһ: «Әмер ителгәнне инде ачык ит!» (Һиҗр: 94) – дип, әмерен иңдерде. Пәйгамбәр (с.г.в.) дә моннан соң ачык итеп чыгышлар ясый башлады.

Кадерле кардәшем! Боларның берсе дә сез белмәгән нәрсәләр түгел. Мин сезгә белгән нәрсәләрегезне өйрәтергә дә җыенмыйм. Тик бөек шәхесегезгә (заты галиегезгә) калебемдә ни бар, шуны ачам: минем йөрәгем сездәге камиллек һәм акыл турысында тыныч һәм канәгать. Аеруча дөнья хәлләреннән һәм бүгенге сәясәттән киң хәбәрдар булуыгызны беләм. Сез калебләре җылынганчыга кадәр япон кардәшләребез белән ничек мөгамәлә кылырга икәнен яхшырак та беләсез, шулай эшләрсез дә. Шулай булмаса, халыкның онытуы бар.

Заты галиегездән хәер догаларыгызда безне онытмавыгызны сорыйм. Бөтен мөселман кардәшләребезгә сәламнәремне тапшырыгыз.

Габдерәшит Ибраһим.
Сеул, 6 җөмәдиел-ахыр[1]».

Сеулдан тагын бер хат

Биредә бу хатымны ничек язылган булса шулай бирә алмаячакмын, чөнки рус телендә язылган иде.

«Туганым Охара җәнапларына!

Мин сездән аерылганнан соң, Кобе, Симонасаки, Пусан юлы белән Сеулга килдем. Еракка киткән саен, йөрәгем сезгә тагын да якынайган кебек. Сезнең белән үткәргән көннәрне тагын да ешрак искә төшерәм. Ышанып әйтә алам: сез дә мине искә төшерәсез, чөнки пәйгамбәребез (с.г.в.): «Күңелдән күңелгә юл бар», – дигән.

---

[1] Гарәп телендә язылган һәм шул килеш әсәрнең төп басмасына да кертелгән бу хат китапның Әртугрул Өзалп тарафыннан хәзерге төрек теленә күчереп бастырылган басмасында төрек теленә тәрҗемә итеп бирелгән (Abdurreşit İbrahim. Alem-i İslam. Cild II. Sadeleştiren ve notlandıran Ertuğrul Özalp. Ankara: 2012, S. 36-37). Без шул тәрҗемәдән файдаландык (тәрҗ. иск.).

Мин сезгә бик җентекле хат язуның кирәген күрмим, бары тик шуны гына әйтәсем килә: беренчедән, вакыт бик аз булганга, икенчедән, тел белмәгәнгә, Корея-да тоткан юлыбызга туры килерлек әллә ни башкара алмадым. Корея халкы белән аралашып, аларны тугры юлга чакыра алмадым. Инде бу вазыйфаны җәмгыятебез ныгып урнашканнан һәм Токиода мәчетләребез эшли башлаганнан соң башкарырбыз.

Минем кадерле кардәшләрем Тойама, Инокай һәм башкаларның һәммәсенә сәлам җибәрәм. Пекинда сездән хат көтәчәгемне белдереп, хәзергә Аллаһка әманәт булыгыз.

Габдерәшит Ибраһим.
Сеул, 6 җөмәдиел-ахыр».

Япониядәге дусларыма шулай ике хат язганнан соң, бераз ял итеп алыйм, дигән идем, кинәт ишек шакыдылар. Карасам: бер укытучы килгән. Мин аның белән ике көн элек танышкан идем.

– Япониядән дүрт кеше килгән, сукырлар. Япониядәге Сукырлар мәктәбе мәнфәгате өчен концерт куясылар икән. Теләсәгез, әйдәгез, барыйк. Мин Сезне чакырырга килдем, – диде.

Мин, вакыт та үтәр, дип, риза булдым. Бардык, концерт карадык.

Концерт дигәч, Аурупада күнегелгән гаҗәеп нәрсә күз алдына килә. Тик Кореяның башкаласы булган Сеулда концерт дигәндә, әлбәттә инде, ул җирләргә туры килә торганрак концерт буласын уйлап, башта бераз икеләнгән идем. Нәтиҗәдә, бик канәгать калдым.

Без концертка бик үк вакытында барып җитә алмадык. Без килгәндә инде ул күптән башланган, хәтта тәмамланырга тора иде.

Гаскәриләр клубында, без залга кергәндә, уен коралларында уйныйлар иде. Тамашачы шактый күп иде. Без килеп күп тә үтмәде, концерт тәмам булды, тамашачылар таралды.

Юлдашым белән бергә концерт куйган сукыр кешеләр янына киттек. Кемнәр икәнен сораган идек, Авасаки сукырлар мәктәбенең элекке укучылары булуларын әйттеләр. Сукырлар шулай йөреп, концертлар бирәләр, мин бу хакта белә идем. Хәл-әхвәлләрен беләсем килеп, сораштым, менә шундый мәгълүмат алдым.

Ике ел элек, мәктәпне тәмамлаганнан соң өйләнгәннәр, сәяхәткә чыкканнар. Икесе дә хатыннары белән бөтен Японияне йөреп чыкканнар. Барган җирләрендә уен коралларында уйнап, концерт куйганнар, үзләре укыган мәктәп өчен акча җыйганнар.

14 ай эчендә Япониядә йөреп, концерт куеп, 684 йен акча җыя алганнар. Мин алардан:

– Сезне мәктәптән җибәрделәрме, әллә үзегез уйлап сәяхәткә чыктыгызмы? – дип сорадым.

Японнарның кыллы музыка уен коралы сямисян

– Мәктәп безгә сигез ел буе белем һәм тәрбия бирде, без бер тиен дә түләмәдек. Бүген вөҗданыбызны җаваплылыктан азат итү өчен, һич булмаса, без дә бер-ике ел мәктәп мәнфәгате өчен хезмәт куйыйк, дидек, – дип җавап бирделәр.

Менә бу – зәгыйфь кешеләрнең вөҗданы. Безнең күзле кешеләребезнең башларына берәр тапкыр шундый уй килгәне булдымы икән? Бу кешеләрнең шулай ил-җир гизеп, Ватан балалары өчен шундый фидакярлек эшләүләрен күрү, аңлау миңа бик нык тәэсир итте.

Мин биредә бу сукыр музыкантларның уен коралларын сүз белән генә булса да сурәтләп китәргә телим. Кырыйдагы хатынның кулындагы уен коралы «шимисика[2]» дип атала. Калган өчесендә кото дигән уен кораллары.

Мондый уен кораллары Аурупада юктыр дип уйлыйм. Бигрәк тә шул кото дигәннәре бик матур. Японнар үз музыка уен коралларының барысын да үзләре иҗат иткәннәр.

Әгәр дә без боларны игътибарга алып уйлансак, ул – безнең өчен гыйбрәт дәресе. Бу зәгыйфь кешеләрдәге гайрәтне күр: үзләренә белем-тәрбия биргән мәктәпнең мәнфәгате һәм яшәеше өчен, аңа үз кулларыннан килердәй ярдәм итәр өчен ике ел гомерләрен сарыф итсеннәр әле!

Японнарның музыка уен коралы кото

Боларны күз алдына китереп, японнарның 30 елда дөньяны шаккатырып, искиткеч дәрәҗәдә алга китүләренең серен аңлаган кебек буласың. Безнең хәтта күзле кешеләребезнең дә үз мәктәпләренә карата японнарның бу күзсез кешеләрендәге кадәр хис-тойгы юк...

Шул рәвешле, мин бу концерттан, бер яктан, бик көчле тәэсиргә бирелеп, икенче яктан, бик канәгать калып, кунакханәмә кире кайттым. Ятып йокларга теләгән идем, ләкин башымдагы уйларым ирек бирмәде. «Әгәр милләтнең алга китүе өчен шулай түбән катлам кешеләренең дә милләт язмышын уйлап фикер йөртә алулары таләп ителә икән, безнең «киләчәк» һәм «яшәү» дигән булып сөйләнүләребезнең берниндиі дә мәгънәсе юк», – дип, тәмам өметсезлеккә бирелеп бетә яздым.

Тик кинәт йөрәгем үзгәрде, фикерем үзгәрде. Үз-үземне гайрәтләндерергә теләп: «Зәгыйфь, сукыр кешеләр үз мәмләкәте, Ватаны өчен шул рәвешле фикер йөртә алганда, минем, әлхәмдүлилләһ, бөтен әгъзаларым сау, бернинди киртә дә юк, мин ни өчен милләтем өчен җанымны фида итмим», – дип, тирән уйларга талдым һәм, ниһаять, йоклап киткәнмен.

*Төрекчәдән **Асия Рәхимова** тәрҗемәсе.* ■

---

[2] Гарәп хәрефләре белән бу уен коралының исеме шемисика / шимисика рәвешендә язылган булса да, моның ялгыш ишетелеп язылган булуы да мөмкин, чөнки япон музыка уен кораллары арасында аңа охшаш исем табылмады. Күбесенчә атаклы сямисян һәм сякухати исемле уен кораллары искә алына (тәрҗ. иск.).

Безнең мирас №3 март 2021

«Тарихын белгән халык – тəп-тере бер милләттер»

Хатыйп Миңнегулов, филология фәннәре докторы

Дөресен генә әйткәндә, 50 яшемә кадәр минем бу шәхес хакында, гәрчә исемен, Төркиядә яшәгәнлеген сирәк-мирәк ишеткәләсәм дә, хәбәрдарлыгым юк иде. Бары 1990 елда Финляндиядәге өч айлык гыйльми командировка вакытында гына аның шигырьләре белән таныша башладым. Мөһаҗирлектәге татар басмаларында, аеруча Төркиядә 70 нче елларда нәшер ителгән «Kazan» журналында Ләбиб Каранга (Әхмәд Ләбиб Каран. 05.01.1887-30.07.1964) мөнәсәбәтле аерым мәгълүматларга тап булдым. Хельсинки университеты китапханәсендә, Суомидагы татарларның өйләрендә аның латин хәрефләре белән басылган, татарча язылган аерым мәҗмугаларын актарып чыгарга туры килде. Болар арасында мондыйлар хәтердә калган: «Татарларның төп чыгышы» (этногенезы. – **Х.М.**). – Истанбул: Әхмәд Сәйд матбагасы, 1962. – 96 б.; «Яшь вакытым җырлары». – Истанбул: М.Сиралар матбагасы, 1959. – 96 б.; «Шиһабеддин Мәрҗани: тормышы һәм әсәрләре». – Истанбул: «Таң» матбагасы, 1960. – 79 б.; «Төшенчәмнең җырлары». – Истанбул: Әхмәд Сәйд матбагасы, 1959. – 96 б. Шулай ук бу авторның «Сөембикә ханбикә», «Сөмсөремнең җырлары» исемле шигырь җыентыклары да билгеле. Шунысы мөһим: аның бу китаплары татар телендә язылган һәм басылган. Ләбиб Каранның тыйб буенча төрекчә «Pellagra» исемле хезмәтен кулыма тотып карый алмадым. Финляндиядәге милләттәшләребез дә Ләбиб Каранның китапларын бүләк иттеләр. Бераздан мин аларның кайберләрен Казандагы төп китапханәләргә, музейларга тапшырдым. Кызганыч ки, хәзер алдарак саналган басмаларның тик тәүге икесе генә кулымда калган. Шул сәбәпле бу мәкаләдә, нигездә, «Татарларның төп чыгышы» һәм «Яшь вакытым җырлары» хакында сүз барачак.

Соңгы чирек гасырда Ләбиб Каранны өйрәнүдә, аның мирасын асыл Ватанына кайтаруда мин бары бер-ике хезмәтне генә авыз тутырып әйтә алам. Ул да булса – танылган галимебез Әбрар Кәримуллинның «Доктор Әхмәд Ләбиб Каран һәм аның «Шиһабеддин Мәрҗани» язмасы» [Ул «Әдәби мирас» җыентыгының 4 нче китабында басылган (К.: Татар. кит. нәшр., 1997. – 33-91 б.)].

Ләбиб Каранның тәрҗемәи хәле хакында безнең күзаллаулар соңгы чирек гасыр эчендә бик үзгәрмәде, бары тик кайбер факт-мәгълүматлар белән тулылана гына төште. Тормышының хәтта кайбер мөһим сәхифәләре дә безгә һаман бик билгеле түгел.

Шагыйрьнең 1948 елда иҗат ителгән автобиографик характердагы «Каран» исемле парчасы бар. Ул шул исемдәге елга исемен йөрткән авылда туып-үсүен, шундагы

мәдрәсәдә укуын, әүвәл белемне әтисеннән алуын искәртә.

Милләттәшләребез яшәгән җирләрдә, аеруча Татарстанда, Башкортстанда, элеккеге Минзәлә һәм Бәләбәй өязләрендә Каран исемле шактый гына татар авыллары бар. Хәзерге Бүздәк һәм Сарман районнарында да алар берничә. Кайберәүләр Ләбиб Каранның туган авылын элеккеге Казан губернасына нисбәт итәләр. Ә.Кәримуллин аны хәтта «Казаннан 50 чакрым» ераклыкта дип конкретлап та куя («Әдәби мирас», 4 нче китап, 35 б.). Әмма документларда Татарстан башкаласы тирәсендә Каран исемле мәдрәсәле мондый карья күзгә ташланмый (бәлки, карый белмәгәнмендер?). Казан тирәсендә туган һәм яшәгән күп кенә танышларым да биредә мондый авылның булуын раслый алмадылар. Бәлкем, Ләбиб Каран Урал татарларыннандыр?.. Телендә «тулкын», «бидрә» кебек бу як сөйләшенә хас элементлар да очрый. Әдип икенче хатыныннан туган балаларына Идел һәм Дим исемнәре бирә. Бу да, мөгаен, юкка гына булмагандыр. Шулай да әле без хәзергә (бу мәсьәлә тәмам ачыкланганчы) булачак шагыйрь, табиб, галим Идел-йорттагы Каран исемле татар авылларының берсендә туган дип кенә әйтергә мәҗбүр булабыз.

Ләбиб Каран кайбер башка язмаларында да үзенең туган ягын, андагы «җыен»нарны, балалык һәм үсмер елларын искә төшерә. Мәсәлән, «Безнең умарталык» исемле шактый күләмле (10 битлек) шигырендә Каран тирәләренең матур табигате сурәтләнә, андагы күпләгән агач-үсемлекләрнең атамалары санала; әтисенең урмандагы умарталыгы, аңа барып-кайтулар, эшләү һәм кунулар, умарталарны ничек караулар, бал аертулар бик тә яратып, җентекләп тасвирлана. Бу әсәрдән авторның әле «унбиш яшьләрендә» дә туган авылында яшәве аңлашыла. Аннан Әхмәд Ләбибнең соңгы берничә елда кайларда булуы, укуы бик ачык түгел.

«Татар-башкорт шагыйре» исеме белән тарихка кереп калган Ш.Бабичның күпләргә мәгълүм эпиграмма-багышламаларында 1916 елда иҗат ителгән мондый икеюллык бар (Моны дустым Рәдиф Гаташ искә төшерде. Рәхмәт үзенә!):

Ул Ләбиб – кызгылт егет, лап-лоп басып, гайрәтләнеп,
Әй йөри торгандыр инде фәс киеп, дуракланып.

[Ш. Бабич. Зәңгәр җырлар / төзүче-редакторы – Галимҗан Гыйльманов (шагыйрьнең якташы-авылдашы. – **Х.М.**). – К.: Тат. кит. нәшр., 1990. – 280 б.]. Бу исемгә җыентыкның искәрмәләр өлешендә мондый аңлатма бирелә: «Ләбиб – Ләбиб Сәлимов – «Галия» мәдрәсәсе шәкерте. Аны тәмамлагач, Истанбулда укып йөри һәм шунда врач булып кала. Читтә торып, «Шура» журналында һәм «Вакыт» газетасында мәкаләләр бастыра» (502 б.).

Кызыклы факт-белешмә! Ләбибнең яшьтән үк «гайрәтле», актив табигатьле булуы билгеле. Истанбулда укып, табиб булуы да хак. «Сәлимов»ның башка кеше булу ихтималлыгы бик аз. Әмма шулай да шагыйрьнең ул фамилия белән йөртелүе, «Галия» мәдрәсәсендә укуы башка чыганакларда хәзергә күзгә ташланмый.

Аерым язмаларда Каран егетенең Петербургтагы бер гаскәри уку йортының курсанты булып алуы да телгә алына. Кайберәүләр, бигрәк тә интернетта Ләбиб Каранның Төркиягә килүен «Беренче бөтендөнья сугышыннан соң» дип карыйлар. Әмма мондый караш чынбарлыкка туры килми. Ләбиб Каран Истанбулга инде дөнья сугышы башлануга берничә ел кала ук килгән була. Аның «Яшь вакытым җырлары»ндагы берничә шигыренең Октябрь инкыйлабына кадәр үк Төркия башкаласында иҗат ителүе күрсәтелә.

Ләбиб Каранның инде 1909 елда ук Истанбулдагы Вафа лицеенда укуы мәгълүм. 1911 елда аның Балкан сугышында катнашуы телгә алына. 1912-1918 нче елларда ул Истанбул университетының медицина (тыйб) факультетында укый. Кәмал паша (Ататөрек) җитәкчелегендәге сугышларда Төркиянең азатлыгы өчен көрәштә гаскәри табиб буларак катнаша. Алга таба бу илнең Измир һәм кайбер башка төбәкләрендә хастаханәләрдә эшли. 20-30 нчы еллар аралыгында аның Алманиядә стажировка узуы, Берлинда хезмәт

куюы мәгълүм. Ләбиб Каран 1932 елда Төркиягә әйләнеп кайта. Бераз вакыт Конья, Бурса һәм кайбер башка калаларда табиб булып эшләгәч, бу шөгылен Истанбулда дәвам иттерә. XX гасырның урталарында Ләбиб Каран Төркиядә күренекле табиб, шагыйрь, галим һәм җәмәгать эшлеклесе буларак танылa. Үз белгечлеге буенча гыйльми хезмәтләре бар. Кайбер язмаларда аның «медицина фәннәре докторы булуы» да искәртелә (бәлки, «медицина докторы» гыйбарәсе шулай кабул ителгәндер?).

Г.Ибраһимовның яшьтәше, Г.Тукай, Ф.Әмирханнар белән «почти» бер елда туган Ләбиб Каран, күрәсең, башка чордашлары кебек үк, татар милли-азатлык хәрәкәтендә, иҗтимагый-мәдәни тормышта яшьтән үк катнаша, әдәби иҗат белән шөгыльләнә башлый. Октябрь инкыйлабына кадәр үк иҗат ителгән шигырьләре дә моны раслап тора. Чит илләргә киткәч, Каран егете үзенең иҗтимагый-иҗади эшчәнлеген тагын да көчәйтә. Аның күп кенә күренекле затлар белән аралашуы, аеруча Г.Исхакый белән дәвамлы мөнәсәбәтләре күп нәрсә хакында сөйли. Ул бөек әдип әсәрләрен, карашларын яхшы белә, 20 нче елларның урталарында ук аның белән ныклап аралаша башлый. Мәгълүм ки, Ләбиб Каран, беренче хатыны вафат булгач, кырымлы Рабига Вәли кызына өйләнә. Алар туенда Йосыф Акчура белән Гаяз Исхакый шаһитлар сыйфатында була. Алманиядә яшәү елларында ул «Инкыйраз», «Зөләйха» кебек мәшһүр әсәрләрнең авторы белән «Яңа юл» («Яңа милли юл») журналын чыгаруда турыдан-туры катнаша, анда язышa да*. 1939 елда Г.Исхакый кабат Төркиягә кайткач, бу ике зат даими диярлек аралашып тора, татар милли хәрәкәтенең үзәгендә кайный, аның белән җитәкчелек тә итә. Бөек әдипнең 14 нче томында тупланган материалларда Ләбиб Каран исеме, аның белән мөнәсәбәтләр еш телгә алына. Мәсәлән, Г.Исхакый Садрый Максудига 1929 елда язган бер хатында Ләбиб Каранның Берлинда «чалышуын» (эшләвен) хәбәр итә (32 б.). Кызы Сәгадәткә 1947 елның 14 декабрендә юллаган бер мәктүбендә Ләбибләрдә кунакта булуы, аның хатыны Рабига ханымның «бик тәмле пәрәмәчләр белән сыйлавы» телгә алына (167 б.). Ләбиб Каран да үзенең аерым язмаларында бөек әдипне ихтирамлы, абруйлы шәхес рәвешендә телгә ала, бу затның эшчәнлеген югары бәяли. Аның 1949 елның 20 апрелендә Гаяз Исхакыйга багышланган махсус шигыре-мәдхиясе дә бар. Бу язма безнең «Чит илләрдәге татар әдәбияты» монографиясендә (К., 2007.) басылган. Шуңа күрә биредә аның тәүге ике строфасын гына укучыларга тәкъдим итәбез:

Гаяз Исхакый – татарның бер олуг инсаныдыр,
Татар әдәбиятының таҗлы бер хаканыдыр.

Аның ак башы – платинадан үрелгән таҗыдыр,
Аны күреп кулын үпкәнләр гүя кем хаҗидыр... (143 б.)

Ләбиб Каранның ике мәртәбә өйләнүе инде алда телгә алынган иде. Аның беренче хатыны хакында мәгълүматыбыз юк. Әмма бу тәүге гаиләнең кызлары Лалә (Оралоглу) (15.08.(28.09) 1924, Измир – 15.01.2007, Истанбул) Каранңарны дөньяга таныта. (Икенче кызы – Чулпан.) Лалә Истанбулдагы атаклы француз һәм алман лицейларында, университетның инглиз бүлегендә укый. Ул төрек, татар, инглиз, француз, итальян телләрен камил белә, башкала консерваториясендә белем ала, шунда ук вокал һәм фортепиано курсларын алып бара. Лалә спортның төрле төрләре (ишкәк ишү, йөзү, сикерү...) буенча ил чемпионы була. Ул дистәләгән конкурсларда лауреат булган җырчы, күп кенә төп рольләрне башкарган, кино һәм театр артисткасы (аның 20 ел эчендә 62 спектакльдә, 38 фильмда уйнавын телгә алалар); өстәвенә, режиссер, продюссер; журналист, бик популяр «Кызым» исемле

* Ләбиб Каран, гомумән, үз гомерендә илдәге һәм чит мәмләкәтләрдәге газета-журналларда язышa.Аның «Вакыт»та, «Шура»да басылу ихтималы да зур. Әдипнең бу төр язмаларын ачыклау, өйрәнү дә билгеле бер бурыч булып тора.

детектив романның авторы да. 1961 елда Лалә Каран үзенең шәхси театрын да оештырып җибәрә, аны иренең исеме белән «Оралоглу» дип атый. Лалә Каран 2007 елның гыйнвар урталарында баш миенә кан савудан 83 яшендә гүр иясе булды. Бу бөек затның үлеме Төркия мәдәни тормышында зур матәм рәвешендә яңгыраш тапты.

Лалә Каран хакында төрле басмаларда, шулай ук интернетта шактый гына материаллар бар. Аларның бер өлеше Төркиядәге милләттәшебез Рушания Алтай тарафыннан әзерләнгән. Хәтерем ялгышмаса, аның «Сөембикә» журналында (2018, июль) «Сары гөлебез» дигән кызыклы гына язмасы да басылды.

Шунысын да искә төшереп үтим: бу язманы әзерләгәндә миңа элеккеге студентларым – хәзер Төркиядә журналист булып эшләүче Роза Корбан һәм Биектауда гомер кичерүче Айсылу Абдуллина, интернеттан, төрле чыганаклардан алып, шактый гына материаллар җибәрде (зур рәхмәтләр юллыйм үзләренә!). Күпчелеге Лалә Каран турында. Арада аның әтисенә кагылышлы мәгълүматлар да бар.

Гаяз Исхакый 1948 елның 6 ноябрендә кызы Сәгадәткә язган бер хатында Ләбибнең ике кызының да университетка укырга керүен яза: «Идел – биологиягә, Дим – химиягә» (14 нче том, 158 б.). Алдарак язып үтүенчә, болар Ләбиб Каранның икенче хатыныннан туган балалары булса кирәк.

Узган гасырның икенче чирегендә һәм аеруча урталарында чит илләрдә, бигрәк тә Төркиядә «төрекчелек» идеясе көчәеп китә. Бу, гомумән, начар күренеш түгел. Әмма, ни кызганыч, ул татар атамасыннан бөтенләй баш тарту хисабына үткәрелә башлады. Төркиядәге, Финляндиядәге кайбер милләттәшләребез дә төрекчелек агымына кушылып китте, хәтта аерым олуг шәхесләребез бу юнәлештә кирәгеннән артык активлык та күрсәттеләр. Шушындый шартларда башында Гаяз Исхакый торган татарчылык хәрәкәте милли яктан шактый гына җаваплы эш-гамәлләр кылды. Төрле чаралар уздырылды, газета-журналлар, китаплар чыгарылды. Ләбиб Каран, әйткәнебезчә, Төркиядәге татарчылык хәрәкәтенең үзәгендә кайнады. Җөмләдән ул «Сөембикә Культур җәмгыяте»нең (1957-1964) башында торды, тарау милләттәшләребезне туплауда, татар рухында тәрбияләүдә, дөньяга танытуда шактый гына игелекле эшләр башкарды. Мәсәлән, 1953 елның 12 апрелендә Тукайның үлеменә 40 ел тулу уңае белән Истанбулда үткәрелгән зур чара киң җәмәгатьчелек тарафыннан зур бер вакыйга рәвешендә кабул ителә. Ләбиб Каран өчен Сөембикә татарның бер символы кебек. Ул аны билгеле бер дәрәҗәдә илаһилаштыра да. Аерым истәлекләрдә Ләбиб Каранның үз балаларын, аеруча Laләсен шушы мәшһүр зат рухында тәрбияләргә омтылуы искәртелә. Ләбиб Каранның Казан ханбикәсе хакындагы китабы Сөембикәгә бер мәһабәт һәйкәл рәвешендә дә күзаллана. Шунысы гаҗәп: Ләбиб Каран үзе исән вакытта ук үзенең кабер ташына Сөембикә манарасы рәсемен ясатып куйдыра. Әйткәнебезчә, «Каран» шигырендә автор туган авылы зиратында җирләнү хакында хыяллана. Аның инде бу нияте 1917 елда Петербургта иҗат ителгән «Бер үтенеч» («Мәңгелек төшенчәсе») парчасында да гәүдәләнеш тапкан була:

Әгәр үлсәм дә, бер кабрем була калса,
Илдәшләрем җеназа намазын кылса,
Сөйгәннәрем баш очына бер таш салса,
Үтенер идем ул ташка шуларны язса... (61 б.)

Алга таба шагыйрь үзенең теләк-васыятьләрен, «татар берлеге»нең, «бәхетенең мәңгелек булачагын» искәртә.

Тормыш-яшәеш кырыс. Аның үз кануннары, тәртипләре бар. Туган илендә әти-әниләре белән бер зиратта җирләнергә теләгән шагыйрь ерак та, чит җирләрдә мәңгелеккә күзләрен йома һәм җәсәде Истанбулның «Feriköy Mezrarligi»да җиргә иңдерелә.

Ахыры киләсе санда ■

Безнең мирас №3 март 2021

КАРА ТӘКЪДИР

(Ачы язмышлы шәхесләр)



ВӘИСИ БАҺАВЕТДИН (1804-1893)

Баһаветдин Хәмзә улы Вәисев – язучы, ислам дине белгече, фәлсәфәче. Әтисе ягыннан пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вәссәлам нәселеннән. Казан губернасының Мулла Иле авылында (хәзерге Яшел Үзән районына керә) дин эшлеклесе гаиләсендә туган. Әнисе ягыннан Болгар илтәбәре Алмыш хан нәселеннән. Вәисевчелекнең максаты: Русиядәге исламның мөстәкыйльлеген, сафлыгын саклап калу. Баһаветдин хәзрәт – «Аллаһ гаскәре»н («Мусульманский Божий полк»ны) оештыручы.

1884 елда аны кулга алалар һәм, акылдан язган, дип, Казандагы акыл хасталыгы белән авыручылар хастаханәсенә ябалар. Тугыз ел дәвамында аны төрле зарарлы дарулар биреп җәзалыйлар, ләкин Вәиси үз максатыннан ваз кичми һәм хастаханәдә җан бирә. Кабере билгесез.

ВӘИСИ ГАЙНАНЕТДИН (1878-1918)

Гайнанетдин Баһаветдин улы Вәисев – сәясәтче. Казан губернасының Мулла Иле авылында (хәзерге Яшел Үзән районына керә) Баһаветдин мулла гаиләсендә туган. Татар-мөселман гаскәренең сәрдары. Ул әтисе башлаган эшне дәвам итә.

Аны кулга алалар һәм Себергә сөрәләр. Ул анда 7 ел интегә, Октябрь түнтәрелешеннән соң гына азат ителә. Иреккә чыккач, әтисе юлын дәвам итә. Вәиси Гайнанетдин – Болак арты Республикасын төзүчеләрнең берсе.

Гайнанетдин Вәисев Мөселман республикасына каршы бәрелештә махсус җибәрелгән җасус тарафыннан атып үтерелә.

Дәвамы. Башы журналның 10 нчы (2020) санында.

ВӘЛИДИ ӘХМӘТЗӘКИ (1890-1970)

Әхмәтзәки Әхмәтшаһ улы Вәлидов – сәясәтче, тарихчы-тюрколог. Уфа губернасының Эстәрлетамак өязендәге Көзән авылында татар дин эшлекләре гаиләсендә туган. Ленин белән Сталинның кан дошманы.

Эзәрлекләүләрдән качып, Әхмәтзәки Вәлиди чит илгә китә. Төркиядә җирләнгән.

ГАЗИЗ ГЫЙЛЬМЕТДИН (1910-1942)

Гыйльметдин Газиз улы Газизов – татар артисты. Татарстанның Әлмәт районындагы Биш Мунча авылында туган.

Фашистларга каршы сугышта һәлак булган.



ГАСПРАЛЫ ИСМӘГЫЙЛЬ (1851-1914)

Исмәгыйль Мостафа улы Гаспринский – мәгърифәтче, нашир, педагог, әдип, сәясәтче. Кырымдагы Улу Сала (Ачыкой) авылында хәрби хезмәткәр гаиләсендә туган. Бакчасарайда Зынҗырлы мәдрәсә янына җирләнгән.

Нахак яла ягып, кырым татарларын Ватаннарыннан кугач, бөек мәгърифәтченең кабере күчеп килгән вәхшиләр тарафыннан җимерелә. Татарлар Кырымга кайткач, Гаспралының шәкертләре, каберне төзекләндереп, мәрмәр таш куялар.

ГАТАУ МАКС (1913-1941)

Гайнетдин Зәйнетдин улы Гатауллин (Гатау Макс) – шагыйрь. Курган өлкәсенең Әлмән районындагы Тозау авылында туган.

Ул 1941 елның 20 ноябрендә Калинин өлкәсендәге Гаврилино авылы янындагы сугышта һәлак була һәм шундагы туганнар каберлегенә җирләнә.

ГАВРИЛОВ ПЕТР (1900-1979)

Петр Михаилович Гаврилов – гаскәри, майор. Советлар Берлеге Каһарманы (Советлар Союзы Герое) (1957). Татарстандагы Лаеш төбәгенең Әлбәдән авылында керәшен гаиләсендә туган.

Петр Гаврилов Брест ныгытмасы өчен барган канкойгыч сугышта, яраланып, әсирлеккә эләгә. Әсирлектән арынгач, Ватанына кайта һәм аны, сатлыкҗан, дип, ун елга зинданга утырталар. Ул 1956 елда аклана.

ГАЛӘҮ МӘХМҮТ (1886-1938)

Мәхмүт Галәветдин улы Мәрҗани – татар язучысы. Арча өязендәге Ташкичү авылында туган.

1937 елда аны һич гаепсезгә кулга алалар һәм төрмәдә атып үтерәләр.

Текстны басмага
***Рабит Батулла** әзерләде.* ■

Истә, һаман да истә!

Артист Наил Шәйхетдиновның тууына 80 ел

Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының халык артисты Наил Шәмсетдин улы Шәйхетдинов 1941 елның 1 мартында Татарстанның Чирмешән районындагы Лашман авылында туган.

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында 50 ел эшләү чорында Н.Шәйхетдинов 200дән артык төрле планда рольләрдә уйнады.

Ул башкарган кайбер рольләр: Гайфи («Гайфи бабай, өйлән давай!», Г.Зәйнашева), Гыйләҗ («Сакла, шартламасын!», К.Тинчурин), Юныс хаҗи («Хаҗи әфәнде өйләнә», Ш.Камал), Нариман («Үзебез сайлаган язмыш», Т.Миңнуллин), Хуҗа («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), Хәмзин («Сандугачлар килгән безгә», И.Юзеев), Бәйрәм («Туйлар узгач», Р.Батулла).

Н.Шәйхетдинов 2016 елның 25 гыйнварында Казанда вафат булды.

Язучы Афзал Шамовның тууына 120 ел



Күренекле язучы, 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Афзал Шиһабетдин улы Шамов 1901 елның 4 мартында хәзерге Татарстанның Яшел Үзән районындагы Татар Танае авылында туган.

Казанның «Касыймия» мәдрәсәсен тәмамлаган Афзал 1922-1925 нче елларда Казан дәүләт университеты рабфагында белем ала.

А.Шамовның кайбер китаплары: «Рәүфә» (1928), «Яңгырлы кичтә» (1965), «Бер мәхәббәт турында» (1976), «Буранлы төндә» (1981), «Соры мәче» (1990). Аның тарафыннан тәрҗемә ителгән кайбер әсәрләр: «Капитан кызы» (А.Пушкин), «Борынгы алпавытлар» (Н.Гоголь), «Корыч ничек чыныкты?» (Н.Островский), «Капитан Грант балалары» (Ж.Верн).

А.Шамов 1990 елның 19 гыйнварында Казанда вафат булды.

Артистка Сания Исмәгыйлеваның тууына 90 ел

ТАССРның халык артисткасы (1979) Сания Нургали кызы Исмәгыйлева 1931 елның 4 мартында Алексеевск районының Коры Көрнәле авылында туган.

1951 елда Казан театр училищесын тәмамлаганнан соң, ул Республика күчмә театрына эшкә килә һәм биредә 1986 елга кадәр эшли.

С.Исмәгыйлева иҗат иткән 70ләп рольнең кайберләре: Галимә («Кара йөзләр», М.Гафури), Рәйхан («Рәйхан», Н.Исәнбәт), Мөршидә («Сакла, шартламасын!», К.Тинчурин), Сара («Сулган чәчәкләр», Җ.Җаббарлы), Зиннәтбану («Хәзрәт үгетләргә килде», З.Шаһиморатов).

С.Исмәгыйлева 2015 елның 25 июнендә вафат булды.

Шагыйрь
Рөстәм Акъегетнең
тууына 70 ел

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1987), Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты (2007), 1991 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь һәм журналист Рөстәм Габдрахман улы Фәйзуллин (әдәби тәхәллүсе – Акъегет) 1951 елның 5 мартында Татарстанның Балык Бистәсе районындагы Балтач авылында туган.

Басылып чыккан кайбер китаплары: «Ак болыт шәүләсе» (1987), «Төнге сулар» (1991), «Янды бер шәм таңнарда...» (2001), «Карусели осени» (рус телендә, 2006). Ул шулай ук каләмдәшләре З.Насыйбуллин һәм Р.Юныс турындагы әдәби тәнкыйть мәкаләләре авторы да.

Р.Фәйзуллин 2020 елның 19 июлендә Казанда вафат булды.

Язучы
Госман Бакировның
тууына 125 ел

Язучы, 1955 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Госман Фәтхулла улы Бакиров 1896 елның 12 мартында хәзерге Арча районының Югары Курса авылында туган.

Ул, 1915 елда Беренче бөтендөнья сугышына алынып, Украинада Австрия-Венгрия гаскәрләренә каршы сугышларда, аерым алганда, Тернополь шәһәрен азат итүдә катнаша. 1942 елда Г.Бакиров үзе теләп фронтка китә һәм аңа янә Тернополь каласын азат итүдә, Берлинны алу сугышларында катнашырга туры килә.

Г.Бакировның кайбер китаплары: «Сиртмәле кое» (1949), «Партизан малай» (1953), «Классташлар» (1955), «Укытучым» (1964), «Утлы тегермән» (1966), «Укытучы апам» (1976), «Бормалы юллар» (1982).

Г.Бакиров 1982 елның 12 мартында Казанда вафат булды.

Артистка
Гөлсем Камскаяның
тууына 120 ел

РСФСРның атказанган һәм Татарстанның халык артисткасы Гөлсем Сәйфулла кызы Камская (Ильясова) 1901 елның 25 мартында Казан шәһәрендә туган.

Г.Камскаяның сәхнә эшчәнлеге 1919 елда башлана. Әүвәл ул Казан, Әстерхан һәм Мәскәү театрларында эшли. 1933 елдан ул – Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисткасы.

Г.Камская башкарган кайбер рольләр: Нәгыймә («Банкрот», Г.Камал), Галчиха («Гаепсездән гаеплеләр», А.Островский), Мәһинур («Миңлекамал», М.Әмир), Гөлниса («Шомлы көннәр», Т.Гыйззәт), Сәхилә («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт).

Г.Камская 1975 елның 8 декабрендә вафат булды.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №3 март 2021

Затлы дәвам фестивале

«Ак калфак» ансамбле. 2007 ел, март

...Алдагы елларда, йөзләгән хат язып, фестивальгә яңа иганәчеләр эзләдем. Әмма таба алмадым. Җырчы кешегә акча сорап йөрү түбәнчелек, килешми торган гамәл кебек тоелды. Учагын сүндермәс өчен, Казанда үз көчем белән дүрт тапкыр фестиваль үткәрдем. Йомгаклау концертлары ике тапкыр Кәрим Тинчурин театрында, бер тапкыр Вячеслав Менжинский исемендәге мәдәният сараенда узды. Дүртенчесе Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет академия театрында «Каһарман җырлар» исеме белән үткәрелде. Беренче көндә үземнең концертны оештырып, шуннан кергән акчага фестиваль уздырыла иде (Кырымнан, Дагстаннан, Хакасиядән килгән лауреатларның юл, яшәү һәм ашау хакларын үз өстемә ала килдем).

2010 елда мәдәният министры Зилә Вәлиевага бер милли депутатыбыз хат язды: «Соңгы елларда Кырымда «Сөембикә варислары» фестивале уздырылмый башлады, аның урынына «Алтын тәхет варислары» дип аталган яңа чара уздырырга финанс ярдәме күрсәтсәгез иде...» Шундый ук хат Кырымнан, мәдәният министры урынбасарыннан да килеп төшкән. Аларны үз күзләрем белән күргәч, өнсез калдым. Шунда ук Зилә ханым янына кердем. Хатлар турында белүемне әйттем. Ул елны фестивальне үткәрү планга кертелмәгән булса да: «Мин быел «Сөембикә варислары»н Кырымда үткәрәчәкмен, миңа ничек тә ярдәм итегезче», –

Ахыры. Башы журналның 2 нче (2021) санында.

дидем. Министр: «Бер урында ике фестиваль үткәрелә алмый, мин «Сөембикә варислары»н хуплаячакмын, ул Кырымда бик популяр бит», – диде. Һәм, әйтергә кирәк, сүзендә торды. Фестиваль ул ел бюджетында каралмаган булса да, кулыннан килгән кадәр ярдәм күрсәтте. Ләкин бу гына аз иде... Фестивальне тиешле дәрәҗәдә оештырып, уздырып җибәрер өчен, миңа тавыш яздыру студиямне сатып җибәрергә туры килде.

Ул фестиваль искиткеч булды. Анда «Татар кызы» һәм «Татар егете» бәйгеләре, Сабан туе, «Мин татарча сөйләшәм» акциясе, композиторыбыз Сара Садыйкова иҗатына багышланган кичә, татар халкының күренекле шәхесләре, тарихчылар, музыка-сәнгать белгечләре, язучылар, галимнәребез белән очрашулар, кичке уеннар гөрләп барды. Артем Пискунов, Резеда Сәлахова, Илфак Хафизов, Лия Вильданова (Кәрим Тинчурин театры артистлары), концертлар алып бару белән генә чикләнмичә, төрле чараларда да катнашып, чыгышлар ясап, балаларның кәефен күтәрде, үзләре дә күңел ачты. Фестиваль эченнән «үсеп чыккан» әйдаманнар миңа зур таяныч булды. Күп чараларны балалар үзләре оештырды. Аллаһы Тәгалә юлыбызга яхшы кешеләрне дә чыгарып торды, шөкер. Бик авыр вакытта татар эшмәкәрләре Фәрит Мифтахов, Исмәгыйль Шәнгәрәев ярдәм кулы сузды. Безнең шундый намуслы, иманлы егетләребез бар, Аллага шөкер! Аңа өстәп, әлбәттә, студиямдә дөнья күргән аудио һәм видеоязмалардан кергән табыш та иш янына куш булды. Татар конгрессының, «Ялкын» һәм «Сөембикә» журналларының затлы бүләкләре дә тамашачыларның йөрәкләрен яулап алган катнашучыларга барып иреште.

Бер елны журналист, «Казанские ведомости» газетасының баш мөхәррире Венера Якупова «Крымские татары или Привет от Сталина» исемле китап нәшер итте. Фестивальгә барса да, әлеге китапны чик аша уздыра алмаячагын әйтте. «Бирегез, үзем алып барам», – дидем. Берничә йөз китапны балаларның кофрларына (костюм сала торган капчык яисә савыт) тутырып, Кырымга чыгардык. Бер генә китапны да

конфискацияләтмәдек. Венера ханым үзе дә килеп, балалар һәм өлкәннәр белән очрашу үткәрде. Ул китапта Кырым татарларының моңарчы әйтелмәгән, дөньяга чыкмаган яшерен тарихы, ачы язмышы ярылып ята иде. Китап алар өчен әйтеп бетергесез зур бүләк булды. Бүген дә кырым татарлары Венера ханымга рәхмәт укыйлар, аны онытмыйлар.

...«Сөембикә варислары» – халык фестивале ул! Талантлы балаларның юл һәм яшәү хакын, нигездә, ата-аналар, эшмәкәрләр, җитәкчеләр үз өсләренә ала иде. Югыйсә балалар шулай эшләп, ял итеп кайта алыр идеме?!. Форсаттан файдаланып, барысына да рәхмәтемне җиткерәм! И газиз халкым! Уңган да, булган да, мәрхәмәтле дә, ярдәмчел дә син! Кирәк чакта усал да була беләсең. Бөтенләй җебеп төшмәс өчен, анысы да кирәк. Телебезне, моңыбызны, җырларыбызны, тарихыбызны саклыйсы, яшәтәсе бар бит әле! Нык булыйк! Нәкъ җырымдагыча:

Зур дәүләтләр корган халык без,
Җир тетрәткән батыр алып без;
Туган илгә яулар килгәндә,
Җан аямый торган халык без!..

...Шушы егерме ел эчендә фестивалебезнең үз иҗат төркеме барлыкка килде, ул композиторлардан, музыкантлардан, җырчылардан, балетмейстерлардан, ана телебезнең нечкәлекләрен белгән сөйләм осталарыннан, дирижерлардан, хор җитәкчеләреннән һәм гамәли сәнгать осталарыннан тупланды. Һәр ел саен өстәлеп, яңарып торды. Бу фидакяр затлар балалар хакына җаннарын аямады. Шуларның берничәсен атап үтәсем килә.

1999 елдан башлап музыкант, фольклорчы галим Геннадий Макаров, Алсу Еникеева, «Ак калфак», «Җомга көн» һәм «Дәште Кыпчак» фольклор ансамбльләре белән, фестивалебезнең җыр сәнгатенә, халык иҗатына караган өлешен нығытты. «Ләйсән» ансамбле җитәкчесе Венера Гатауллина, күпме халык җырларын балаларга өйрәтеп, халкыбызның иҗатына мәхәббәт тәрбияләде. Мәскәүдән яшьләр вокал ансамбле белән Роза Хәбибуллина, «Шатлык» ансамбле җитәкчесе Зәмзәмия Сәхәбетдинова фестивальнең аерылгысыз дуслары булды. Әлеге ансамбльләр, уңышлы чыгышлар ясап, күп тапкыр лауреат исемен алуга ирešте. Балаларга, яшьләргә ана телебездә җырлар өйрәтте, фидакярлек күрсәтте.

Түбән Кама шәһәреннән «Нәүрүз» (бүгенге «Нардуган») ансамбле җитәкчесе Наил Мосыйфуллин, Кырымда һәм Казанда үткәрелгән фестивальләрдә остазлыкның иң югары дәрәҗәсен күрсәтеп, залларны таң калдырды. Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театры балетмейстерлары Сәлимә һәм Илдус Габдрахмановлар фестиваль өчен махсус «Казан шәкертләре» биюен сәхнәгә куйды, Кырым тамашачыларын аягүрә бастырды. Нурбәк Батулланың ярсу энергетикасы «аркасында» бу бию мәшһүрлек казанды һәм бүген дә сәхнәләрне «ду китерә».

Казакъстанның Сәмәй (Җидепулат) шәһәреннән татар, казакъ балаларын, гармуннарын, төрле уен коралларын «төяп», Габделхак Ахунҗанов килеп җитә иде. Фидакяр җанлы татар егетебез ул якларда бүген дә зур эшләр башкара. Татар дөньясын берләштереп, милли мәдәниятебез, гореф-гадәтләребез сагында торучы батыр ул! Чит җирдә татар музыка мәктәбе ачып, татар һәм башка милләт балаларына белем бирә, татар җырларын өйрәтә. Ул, репертуар туплап, укучыларын милли киемнәргә киендереп, юл газабын үтеп, Кырым фестивалена килеп җитә иде. Соңыннан үзе дә «Иртеш моңнары» исемле фестиваль оештырды, милли яшәешебезне, сәнгатебезне

алга сөрде. «Иртеш моңнары»нда миңа да жюри эшендә катнашып, Габделхакның эшчәнлеген үз күзләрем белән күреп кайтырга туры килде. Ул бөтен дин әһелләре белән элемтәдә, зиратлар – аның өчен үзе бер тарих, татар тарихы, мөселман тарихы. Күпме акыл иясе, күпме ишан анда күмелгән – һәммәсенең дә исемен, чыгышын белә. Габделхак – тере тарих сакчысы! Горурланам! Габделхакның укучысы Диаз Мөсәлимов анда, «Мин – джазмен» җырын башкарып, лауреат булган иде, хәзерге вакытта ул Нью-Йорк университетында вокал укыта, профессор. Диаз, казакъ спортчылары җиңү яулаганнан соң, татар композиторы Латыйф Хәмиди язган казакъ дәүләт гимнын Америкада башкарып, төрки дөньяның данын, мәдәниятен мәгъриб илләренә танытты. Афәрин аңа!

...Чүпрәле районыннан килгән «Умырзая» халык уен кораллары ансамбле турында да әйтми калып булмый. 2010 елгы фестивальнең гала-концертын алар 2000 кеше сыешлы залда Салих Сәйдәшев маршы белән ачып җибәрде. Җитәкчеләре Руслан Шәрәфетдинов (үзе дә баянчы) әзер фонограммасыз килгән балаларга аккомпаниатор да булды.

Кырым татарлары турында аерым китап язарлык. Алар безнең фестивальне искиткеч баетты! Сабыйлары милли тәрбия алып үсә. Бигрәк тә бию ансамбльләренең фидакяр хезмәте ихтирамга лаек. Балалар, ансамбльләргә 4-5 чакрым ераклыктагы авыллардан шәһәргә йөреп, җырларга, биергә өйрәнә. Безнең фестивальдә генә дә алар меңәрләп катнашкандыр. «Гүлдесте» кызлар ансамбле (җитәкчесе – Таҗикстанның атказанган артисты Эльзара Әсәнова), «Тиселли» җыр-бию ансамбле (җитәкчесе – Украинаның атказанган артисты Мөнир Аблаев), «Учан-су» (җитәкчесе – Кырым Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Али Алимов), «Җәмилә» (җитәкчесе – Украинаның атказанган мәдәният хезмәткәре, Кырым Республикасының атказанган артисты Җәмилә Османова) – болар барысы да, төрле елларда катнашып, фестивальнең лауреатлары булды. Алар Төркиягә,

Европа илләренә еш гастрольләргә чыга, төрле халыкара чараларда катнаша. Кырым балалары шушы ансамбльләрдә сәнгать мәктәбе үтә, чыныгу ала, матурлыкны күрергә өйрәнә. Менә ни өчен аларның аркалары төз, куллары очар кошлар сыман биектә, үзләренә ышанычлары зур. Кырым татарларының ошбу остазларына бүген үк һәйкәл куярлык!

Элек, без үскәндә, мәктәптә хор белән җырлау бар иде. Шунда сәхнә һәм тавыш күнекмәләре аласың, кыюлыкка өйрәнәсең, кеше арасына чыккач, югалып калмыйсың... Кызганыч, алар бүген популяр түгел. Бию дә шулай – балаларны үзләрен иркен, гәүдәләрен, киемнәрен матур тотарга өйрәтә.

Хәзер безгә мәктәпләрдә, матур язу дәресләре кебек, матур сөйләм дәресләре дә кертергә иде. Югыйсә балаларыбыз (аеруча авыл балалары) авызларын ачып, сүзләрен әйтергә куркып тора бит! Бу безгә бик кирәк. Оныгым Амар шушы юнәлешне башлап, яшьләр арасында дебатлар үткәрергә алынгач, бик сөенгән идем. Ул шактый балаларга, яшьләргә ораторлык осталыгы серләрен өйрәтте.

Нәфис сүз жанры өлкәсендә озак еллар буе армый-талмый хезмәт итүче остазыбыз Наилә Бижанова (Алабуга) хакында аерым әйтәсем килә. Ул –күпме балаларга ана телендә дөрес сөйләм күнекмәләрен өйрәтеп, күпме фестивальләрдә катнашып, күпме баланы лауреат иткән ханым! Әти-әнисе өйрәтә алмаган телнең матурлыгын, татлылыгын, егәрен балаларның йөрәкләренә салган фидакяр зат! Мең рәхмәтләр яусын аңа!

1999 елдан башлап фестивальләрнең берсен дә калдырмаган Әминә Мостафаева «Сөембикә варислары»ның символына әверелде. Урта Азиядән әтисе Сәрвәр, әнисе Лилия белән Ватаннарына – Симферопольгә кайтып, анда кечкенә, бернинди уңайлыклары булмаган тулай торакта яшәп, зур сәнгатькә хезмәт итүче җырчы һәм остаз булып үсеп җитте ул. Институт тәмамлады, укыганда ук Кырым татар җыр-бию ансамблендә эшләде. Хәзер үзе укыган институтта яшьләргә белем бирә, нәни балалардан торган ансамбльне җитәкли. 2019 елда, туй көнендә, аңа «Татарстанның атказанган артисты» исеме бирелде. Әминәнең төп таянычы, әлбәттә, әтисе булды. Ул аны, уңга-сулга тайпылдырмыйча, туры юлдан, олы сәнгать юлыннан алып барды, ныклы белем алырга ярдәм итте. Сәрвәр үзе дә композитор, җырлар яза, музыкант, халыкара фестивальләр лауреаты. Әминәнең энесе Әнвәр дә, фестивалебездә катнашып, бик матур чыгыш ясады, Ватан турында халык җыры җырлап, лауреат булды. Сәрвәр миңа Кырымда татар балаларын барларга ярдәм итте, фестивальгә әзерлекле катнашучыларны китерү өчен күп көч куйды. Кырымда ике Сәрвәрем бар: берсе – Какура, икенчесе – Мостафа. Ике канатым!

Кызым Резеда (галимә, филология фәннәре кандидаты), оныкларым Амар белән Ширин фестивальне әзерләүдә һәм оештыруда төп ярдәмчеләремнән булды. Амар тавыш операторы да, Сабан туйлары, төрле чаралар үткәрүдә төп оештыручы да иде. Кунакларны каршы алу һәм озату – барысы да аның өстенә йөкләнде. Ширинем, исемлекләр төзеп, компьютерда эшләнә торган барлык эшләрне башкарды, программалар әзерләде, кичке уеннар үткәрергә булышты. Боларның барысына да кеше ялласаң, шактый акча кирәк булыр иде, үземнекеләр исә бушлай эшләде. Миңа теләнеп йөрергә туры килмәгәч, кайбер фестивальләр турында рәсми затлар белми дә кала иде. Без реклама ясап, эш күрсәтеп, мактанып йөрмәдек. Эшләдек тә эшләдек кенә. Иң мөһиме – фестиваль утын сүндермәү иде.

...Бер дә хәтеремнән чыкмый: зур автобус, 200гә якын бала, Тукай-Кырлайга барабыз. Юлга чыгар алдыннан Сөембикә манарасы янында галим Габделбәр абый

Фәйзрахманов балаларга ачы тарихыбызны сөйли. Сабыйларның күзендә яшь... Дога кылабыз. Тукай-Кырлайга кузгалабыз. Балалар юл буе сорау яудырып бара. Авыл музеенда, мәктәптә булганнан соң, клубта концерт куйдык. Апрель ае иде. Чәчәкләр шытарга иртә әле. Шунда бер апа өендәге гөлен (чүлмәге белән!) күтәреп чыгып, балаларга бүләк итте.

Мондый сәяхәтләрдә күп йөрелде: Бакчасарайга, музейларга, Кырымның һәм Казаныбызның тарихи урыннарына, Болгарга... Балалар тирән тарих белән танышып, үзләренең кем, нинди милләт вәкиле булуын аңлап, горурлык хисләре кичереп, дуслашып, яңадан күрешергә сүзләр куешып, рәхәтләнеп ана телебездә аралашып, елашып аерылышалар иде.

Берсендә, 25 лауреатны гына туплап, самолетка «төяп», бөтендөнья балалар фестивалена Төркиягә алып бардым. Анда меңләгән халык алдында – стадионда һәм төрле мәйданнарда – чыгыш ясадык. Алар төрек гаиләләренә урнашып, аларның яшәү рәвеше белән таныштылар, дуслаштылар. Алар, Төркиянең берничә шәһәрендә, шул исәптән Кәмал Ататөрек мавзолеенда да булып, рухи яңарыш кичерде.

Җырчы Марат Фәйрушин белән Илнара Хуҗиеваны сәхнәдән төшермәделәр, чәчәк бәйләмнәренә күмделәр. Анкара, Иске шәһәр, Истанбул урамнары буйлап Татарстан байрагын җилфердәтеп, татар җырларын җырлап, татар биюләрен биеп, туган җиребезнең данын якладык. Сәнгатебез, үз-үзебезне тотышыбыз аша газиз Ватаныбызның, халкыбызның бөеклеген исбатладык. Гала-концертлар кырым татарларының «Гүзәл Кырым» җыры белән тәмамлана иде.

Татарстан төбәкләре арасында иң күп катнашучылар Түбән Кама шәһәреннән булды. Наил Мосыйфуллин җитәкчелегендәге «Нәүрүз» ансамбле татар халкының төрле биюләре, милли киемнәрнең зәвыклылыгы аша игътибарны үзенә җәлеп итеп торды, бөтен күз аларда иде. Наил әфәнденең үзен, яшь кенә егетне дә, балалар бик яратты, ихтирам итте. Ул җитәкләгән ансамбль хәзер «Нардуган» дип атала («Нардуган» һәм «Нәүрүз» ансамбльләренең тупланмасы).

Хаҗитарханнан (Әстерханнан) килгән Дәүләт Үмәров җитәкчелегендәге «Мирас» ансамбле биючеләр арасына үзенә бер яңа дулкын булып килеп керде. Ул, шул җирлектәге татар-нугай биюләрен башкарып, бию сәнгатенә яңа сулыш өрде. Дәүләт хәзер Казанга кайтты, монда да менә дигән «Мирас» ансамблен оештырды; балаларга, яшьләргә белем бирә, аларга бию серләрен өйрәтә. Хезмәтләрен исәпкә алып, аңа «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» исеме бирелде. Котлыйбыз! Гыйлеме дә, тәҗрибәсе дә җитәрлек, Аллаһ аңа саулык бирсен, ул безгә бик кирәк.

Әстерханнан Миңнура Ялаева һәр елны фестивалебезгә «Нур» ансамблен алып килә иде. Алар күп иде – җырчылар да, биючеләр дә. Сөембикә турында композицияләр ясап, күккә ашкан калфаклары белән безне борынгы заманнарга, ханбикәле чорларга алып китәләр иде. Ансамбльне, һәр елны, юл һәм яшәү чыгымнарын, җаваплылыкны үз өстенә алып, җирле татар иҗтимагый үзәге рәисе Әнвәр Ибраһим улы Алмаев җибәрә иде. Ни кызганыч, Миңнурабыз безнең арадан китте, урыны җәннәттә булсын…

Фестивальдә бик матур вокал ансамбльләре дә катнашты. Алда әйтелгән «Ләйсән», «Шатлык», Роза Хәбибуллина җитәкләгән кызлар ансамбльләре фестивалебезнең күрке булды. Чаллыдан бертуган Айгөл һәм Рамил Закировлар, «Баяным» дигән җырны җырлап, биеп, үзенә бер спектакль-тамаша ясады.

Нәфис сүз жанрында өч шәп егет истә калган. Булат Садретдинов – үзе шагыйрь, берничә китабы дөнья күрде. Байбулат тавышы, энергетикасы белән бөтен Кырымны шаккатыра иде. Алабугадан Булат Сәхәбиев, Габдулла Тукайның «Китмибез!» шигырен сөйләп, ачык дикция, тавыш аһәңенең көчле һәм матур булуы белән күңелләребезне яулады. Өчесенең дә өстендә Тукайча костюмнар иде. Онытым Морат та алардан калышмаска тырышты, 6 яшендә Рөстәм Мингалим шигырен сөйләп, сәхнәне дер селкетте:

Атланырмын, ат бирсәң!
Атта йөргән малай мин!
Кылыч бирсәң, алырмын!
Кылыч күргән малай мин!
...Бабаларым канында
Яуга кергән малай мин!..

Нурбәк Батулла белән бергә хореография училищесында укып, балет сәнгате серләрен үзләштергән Әминә Имашева фестивалебезнең асыл кошы булды. Аның балет алымнарын кулланып биегән «Аккош» биюе үзенә бер могҗиза, тамашачыларны әкият дөньясына алып китә иде. Әминә үзе дә гүя шул дөньядан чыккан нәфис зат иде. Әнисе җырчы Фатыйма һәм әтисе җырчы-композитор Мәсгут Имашевлар, үзләрендә булган иҗат рухын бу балага күчереп, аны олы сәнгатькә хезмәт итәр өчен үстергән, күрәсең.

«Сөембикә варислары» фестивалендә фольклор ансамбльләре беренчеләрдән булып мөнәҗәтләр һәм бәетләр белән чыгыш ясады. «Ак калфак» ансамбле турында аерым әйтәсе килә. Җитәкчеләре – Геннадий Макаров һәм Алсу Еникеева. Геннадий, фольклорчы галим булу өстенә, музыкант, педагог та, балаларга мөнәҗәтләр, бәетләр өйрәтеп, ансамбльләр төзеде. Ул фестивалебездә балаларга мастер-класслар оештырды, аларны татар халкының музыка уен кораллары белән таныштырды. Алсу Еникеева – мәдәният институты педагогы, студентлары арасында «Җомга

көн», «Дәште Кыпчак» ансамбльләре оештырып, күп фестивальләрдә катнашып, борынгыдан килгән моңнарыбызны халык арасында пропагандалады. Күпме татар баласына борынгы моңнарыбызны сеңдерде алар! Шушы башлангычның дәвамы булып, «Илаһи моң» фестивале туды. Аны, Казан (Идел буе) федераль университеты һәм Россия ислам институты ярдәме белән, галимә, исламият белгече, кызым Резеда Сафиуллина җитәкләде. «Илаһи моң» фестивалендә дә мөнәҗәтләр, бәетләр, халык җырлары башкаручы ансамбльләр катнашып, тагын бер баскычка күтәрелдек.

Геннадий Макаров белән Алсу Еникеева балаларны олы сәхнәгә борынгы милли киемнәрдән киендереп алып чыкты. Алардан күреп, татарлар яшәгән бик күп төбәкләрдә фольклор ансамбльләре оешты һәм бүгенгәчә эшләп килә. Быелгы юбилей концертында да берничәсен күрү мөмкинлеге булыр, Аллаһ боерса. Чуашстаннан Фәрит Гыйбатдинов: «Мин, һичшиксез, юбилей концертында ансамблем белән катнашачакмын! Илнар Хисамов җитәкчелегендә «Тамчы» балалар фольклор ансамбле төзедек бит», – дип куандырган иде. Күрегез, дөньялар нишләде... Халкыбызга үзен аямыйча ихлас хезмәт иткән бөек шәхесләр китеп бара... Сүзләребез рухларына дога булып ирешсен!

Фестивальнең тагын бер номинациясе – гамәли сәнгать. Балалар төрле темаларга бик күп рәсемнәр, курчаклар, сувенирлар алып килә иде. Бу күңел бизәкләре төрле чараларда катнашучыларга бүләк рәвешендә таралып бетә торды. Фойеда мастер-класс оештыручы ханымның (ни кызганыч, исеме хәтеремдә калмаган) 5 минут эчендә төрле чүпрәкләрдән матур курчаклар ясарга өйрәтүе һаман да истә. Кызларның күзендә күпме куаныч-шатлык иде, әйтеп бетерерлек түгел!

Араларында, әлбәттә, иң бәхетлесе мин идем. Фестиваль тәгәрмәче без дигәнчә тәгәри! Аллаһ кушканча, хакыйкый юлдан барабыз! Миңа да үз гыйлемемне, тәҗрибәмне, энергиямне балаларга бирергә насыйп булды. Шул бәхет түгелмени?! «Сөембикә варислары» бүген дә яши, милләткә хезмәт итә, матур гаиләләр корырга этәрә, татарның генофонды байый! Без моңа, шөкер, үз өлешебезне керттек. Аллаһ кабул итсен! Яшь агачлар яфрак ярды, чәчәккә бөреләнде инде, таза, матур җимешләр дә бирер, иншәАллаһ! Телебез, динебез яшәсен! Ватаныбыз сау булсын! Алдагы көндә Аллаһы Тәгаләгә, үзебезгә ышанычыбыз артсын! Дошманнар безне алдап, хәйләләп, туры юлдан яздыра алмасын. Хакыйкый гыйлем аша асылыбызны табарга Аллаһ ярдәм итсен. Шул чагында тел дә, дин дә, Ватан да, без дә яшәрбез! Газиз туфрагыбызны, туган җиребезне саклыйк, бер-беребезне сатмыйк, бабаларыбызның ышанычын аклыйк, шушы юлда Аллаһы Тәгалә үзе таянычыбыз булса иде. Әмин!

2021 ел Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителде. Быел халык санын алу да узачак. Кызганыч, соңгы ханбикәбез Сөембикәнең тууына 500 ел тулуны зурлап уздыра алмадык... Аны да яд итү кирәк. Үземнең дә 75 яшьлек юбилеем. Барысын да берләштереп, фестивальнең 22 еллыгын зурлап үткәрергә җыенабыз. Президентыбызга Казанда юбилей концертын уздыру өчен матди ярдәм сорап берничә хат язган идем. Җавап юк. Хатлар аңа барып җитмәгән, күрәсең. Президент белән ике арада, Кытай стенасы кебек, түрә-кара тора. Аларны үтеп булса, Президентыбыз, һичшиксез, безне ташламас дигән өметтә калам.

Гөлзадә Сафиуллина,
Татарстан Республикасының халык артисты,
Муса Җәлил исемендәге премия лауреаты,
Кырым Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе ■

Чал тарихка бер караш

Марат Хәбибуллин, Татарстанның атказанган артисты

Театр коллективының иң әүвәлге фотоларыннан берсе. 1924 ел

Беренче уңыш Әтнә артистларының күңелен күтәреп җибәрә һәм алар, бик тырышып, шул ук Фазылҗан бай йортында Г.Камалның «Беренче театр» комедиясен уйныйлар.

«Хөррият үзенекен эшләде. Халык көннән-көн театрларга күбрәк йөри башлады, – дип яза 1958 елның 30 ноябрендә район газетасына юллаган хатында Әтнәнең беренче артистларыннан булган Габделхәй Шакиров (ул вакытка инде пенсионер укытучы). – *Театр уйнарга да яңа көчләр өстәлә, арта барды: Каюм Фәтхуллин, Тофах Шакирова, Борхан Минхаҗетдинов, Сара Шәмсетдинова, Габделхак Әмиров, Разия Мөхәммәдиева, Габдрахман Сабирҗанов, Юныс Фарсин, Камал Хисамов һ.б. Элегрәк сәхнәгә кирәк әйберләрне җыешып, сәхнә корышып йөргән малай – Котдус Баязитов соңга таба чын артист һәм оештыручы булып китте».* Бу чорда үзешчән труппага өстәлгән артистлардан Фатыйма Шаһиәхмәтова, Гөлсем Сәхиева, Габдулла Ширинский, Мостафа Гәлләмовларны да искә алырга кирәк.

Партия оешмасы һәм ярлылар комитеты, шулай ук волость баш-

Дәвамы. Башы журналның 2 нче (2021) санында.

карма комитеты һәвәскәр артистларга һәр яктан ярдәм итәләр һәм, ниһаять, 1919 елда, шул ук милиция начальнигы Кленцов башлангычы белән, волость башкарма комитеты бинасының 300 кеше сыйдырышлы зур залы клуб итеп үзгәртелә, аңа Ленин исеме бирелә, ул заманына күрә яхшы гына җиһазландырыла. Кече Әтнә балта осталары Фәйзрахман Ибраһимов, Насретдин Камалиев, Мифтахетдин Камалиев бинаны театр өчен яраклаштыралар, моңарчы үзләре ишетеп тә белмәгән «сәхнә» дигән әйберне күргән кешеләрнең бармак белән аңлатуларына таянып эшлиләр. Төзелеш барганда берәү: «Сәхнә өлгердеме инде, кай җирен эшләдегез, Мифтахи абзый?» – дип сораган. «Сәхнә дигәннең идәнен җәеп бетереп, Тофах тәмугын ясап куйдык», – дигән балта остасы. Аның «тәмуг» дигәне суфлер будкасы икән, ә Тофах күп вакытта суфлерлык итә торган булган.

«

«...Пөхтә генә театр бинасы оештырылды. Урындагы оешмаларның булышлыгы белән декорацияләр хәзерләнде, театр драматурглары Г.Камал һәм К.Тинчурин иптәшләрнең ярдәме белән Казаннан сәхнә әсәрләре, париклар һ.б. кайтарылды, – дип яза үзенең истәлекләрендә Мөхәммәт Парсин. – Шулай итеп, үзенең эшен кечкенә генә комедиядән башлап җибәргән коллектив көннән-көн үсте. Соңга таба сәхнәгә зуррак әсәрләр дә куела башлады... Театр үзенең эшен Әтнәдә алып бару белән генә чикләнмәде, бәлки, башка авыллар белән дә нык элемтәдә торды, аларда еш кына спектакльләр куйды. Шунлыктан, Бәрәзә, Бәрәскә, Өшкәтә, Мәңгәр авыллары укытучылары да театр эшенә якыннан торып катнаштылар. Хәтта аларның пычрак, салкын көннәрдә дә җәяүләп Әтнәгә килгән вакытлары күп булды...»

Артистлар, клуб ачылгач, кош тоткан шикелле булалар, тагын да кыюрак эшли башлыйлар. 1919-1925 нче елларда Галиәсгар Камалның «Бүләк өчен», «Яшьләр алдатмыйлар», «Дәҗҗал», Кәрим Тинчуринның «Революция», Фәтхи Бурнашның «Таһир-Зөһрә», «Яшь йөрәкләр», Сәгыйть Рәмиевнең «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин» һәм башка шундый пьесаларны уңышлы гына куялар. 1925-1926 нчы елларда коллектив «Галиябану», «Банкрот», «Зәңгәр шәл», «Биш меңле Гайнетдин», «Бәхетсез егет» әсәрләрен сәхнәләштереп, Әтнәдә һәм кайбер күрше авылларда уйный. Шулай ук бу чорда «Көндәш», «Кайнеш», «Бүз егет», «Асылъяр» һәм башка спектакльләр куелу турында да мәгълүматлар бар.

Юныс Фарсин истәлекләреннән:

«Мин Әтнәдә 1923 елда булдым. Ул вакытта Әтнә сәхнәсендә (элекке Волисполком бинасында) «Таһир-Зөһрә» һәм «Асылъяр» әсәрләрен кую минем нык хәтеремдә калган. «Таһир-Зөһрә»дә мин Таһирны уйнаган идем. Ә Зөһрәне исә ул вакытта хатын-кызлар тавышы белән сөйләшүче Камал

уйнады. Анда хәзер Тәкәнештә яшәүче Габдрахман Сабирҗанов, Әтнә укытучысы Каюм Фәтхуллин, Әтнәдә яшәгән Котдус, Кече Әтнәдән Габделхәй Шакиров, Тофах Шакирова (аның апасымы, сеңлесеме) катнаштылар. «Асылъяр»да мин Шәрәфне уйнадым».

Авыл халкы спектакльләрне карарга бик яратып йөри башлый. Ә Әтнә халкы ул ни җитди генә түгел! Театрны түгел, заманында авыл үзәгендәге баганага радио элеп урнаштыргач та, баштарак ул яңалыкны шик белән кабул иткән әтнәлеләр.

...1924-1925 нче елларда клуб өчен тагын да уңайлырак бина булдырыла. Ә 1925 елда коллективка яшь җитәкче, профессиональ артист Җәлəл Камалов килә. Үзешчән театр коллективы аның җитәкчелегендә үзенең эшен тагын да яхшырта. Яшь режиссер Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану»ын, Галиәсгар Камалның «Банкрот»ын һәм «Бәхетсез егет»ен куя. Спектакльләр куюдан җыйналган акчаларга акрынлап клуб җиһазландырыла. Бу чорда коллектив Хәким Шакиров, Котдус Баязитов, Галимә Сибгатуллина кебек сәләтле яшьләр исәбенә зурая, ныгый.

Әтнә үзешчән коллективының Татар дәүләт академия театры белән күпләрне көнләштерерлек эчкерсез дуслыгы да тамырлары белән шушы елларга барып тоташа. Академия театры артистларының һәвәскәр сәнгатьтәшләренә ярдәме зур була, драматурглар Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчурин тырышлыгы белән Казаннан сәхнә әсәрләре, париклар, грим һәм башка сәхнә кирәк-яраклары кайтарыла.

Авылның, илнең өстен аска китергән колхозлаштыру чоры башлана. Сәнгатьнең партиячел вакыты, Әтнә үзешчән театры да илдәге хәрәкәттән читтә кала алмый. Авыл кулакларының янауларына һәм һөҗүмнәренә карамастан, театр коллективы сәхнә аша

Галимә Сибгатуллина

кулакларны, руханиларны фаш итә, крестьяннарны күмәк хезмәткә тупланырга чакыра. Бу чорда эчтәлеге белән коллективлаштыруга карата язылган «Булат бабай семьясы», «Акбаш вакыйгасы», «Серләр чишелде» пьесалары райком күрсәтмәсе нигезендә районның барлык авылларында да куела.

1930-1931 нче елларда халык арасында: «Колхозларда сыерлар да, каз-тавыклар да берләштерелә икән», – дигән хәбәр тарала. Нәтиҗәдә, колхозга кергән крестьяннарның кайберләре колхоздан чыга башлый. Менә шушы вакытта «Серләр чишелде» пьесасының әһәмияте бик зур була.

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Галимә Сибгатуллина театр тарихында якты эз калдыра.

23 яшен тутырган крестьян кызы Галимә 1926 елда Габдулла Сибгатуллинга кияүгә чыга. Тормыш иптәше мәдәният хезмәткәре булганга, Галимә дә спектакльләр карарга еш йөри башлый. Яшь хатынның сәхнәгә тартылуын тоеп (яшереп буламыни ул сәхнә лампалары яктысында театрга карата уянып килгән гомерлек

мәхәббәт белән янган күзләрнең нурын!), һәвәскәр артистлар Җәләл Камалов һәм Котдус Баязитов Галимәне коллективка кушылырга өнди башлый. Тик сәнгатьне ихтирам белән караса да, үзе шуңа хезмәт итсә дә, Габдулла агай Галимәнең сәхнәгә омтылышын шунда ук кабул итми. 1928 елны гына Галимә беренче тапкыр репетициягә чакырыла. «Йөзәргә өйрәнүнең бер генә ысулы бар: елга уртасына тотып ату: батмаса, өйрәнер» – театрның ул вакыттагы җитәкчеләре шулайрак фикер йөрткәннәрдер, ахры. Галимәгә килә-килешкә «Галиябану»да төп рольне тапшыралар. Булдыра алмам, дип әйтми театр «җене» кагылып өлгергән хатын.

Үзе ул заманны болай дип искә ала:

«Ирем Абдулла колхозлашу елларында Кызыл почмакта эшли иде. Аңа театр эшен җанландырып җибәрергә кушалар. Спектакль бик куясы килә, тик уйнарга хатын-кызлар юк. Ул елларда хатын-кызның сәхнәдә уйнавы гөнаһ санала иде. Беркөн өйгә кайтты да:

– «Галиябану»ны куярга җыенабыз, әйдә, төп рольгә алын әле. Бәлки, шуннан соң башка хатын-кызлар да килер, – диде.

Сүзен тыңлап киттем. 15 көн репетициягә йөрдек (ул чакта айлар буе өйрәнү юк иде әле). Аннан инде авылларга йөри башладык. Укытучылар Гөлсем белән Хәят тә безгә кушылдылар. Менә шушы вакыттан бирле мин сәхнәдән төшмәдем».

Репетиция башлана. Галимәнең дебюты искиткеч була. Габдулла ага сөенеченнән, тормыш иптәше белән горурланудан нишләргә белми. Ниһаять премьера көне җитә. Әтнәдә, күрше авылларда афишалар язылып эленә. Халык спектакльгә бик күп килә. Галимәнең уйнавы тамашачыларны таң калдыра, спектакль тәмамлангач та, аны көчле алкышлар белән озаталар. Беренче уңыш яшь артистны канатландырып җибәрә. Галимә Сибгатуллина шул көннән бирле сәхнәдән төшми, бик күп искиткеч бай образлар иҗат итә: «Зәңгәр шәл»дә – Заһирә, ә олыгайгач – ишанның беренче хатыны, «Яшь йөрәкләр»дә – Сәрви, «Казан сөлгесе»ндә – ишан хатыны, «Банкрот»та – Гөлҗамал, «Уракчы кыз»да – Мәрьям... Әмма беренче роле гомерлеккә йөрәк түрендә кала аның: кайсы гына драма артисткасы сәхнәдә беренче адымын Галиябанудан башларга теләми икән!.. Бик сирәкләргә эләгә бу бәхет.

1966 елда «Уракчы кыз» спектаклен караганнан соң, режиссер Ширияздан Сарымсаков Галимә апа турында: «Әгәр ул профессиональ сәхнәгә күчәргә теләсә, берсүзсез кабул ителәр иде», – ди. Ә ул вакытта Камал театрының директоры булып эшләгән Рәшидә апа Җиһаншина тагы да турырак итеп: «Бүген үк театрга артистка итеп алыр идем үзен, ләкин ул, килмим, авылымнан беркая да китә алмыйм, дип әйтә», – дип сөйләгән.

Колхозлашу елларында коллектив үзенең эшен агитбригада формасында да алып бара, райком белән берлектә зур маршрутлар төзеп, авылларда йөри, спектакльләр куя, агитация эше белән шөгыльләнә.

Әтнә театры коллективы. Икенче рәттә уртада – Җәлəл Камалов. 1928 ел

Ул чорда һәр атнаның җомга көнендә спектакль куелган. Кәшиф Хәсәнов, Галия Хәсәнова, Гарифулла Төхфәтуллин, Мөнәвәрә Төхфәтуллина, Гадел Сафиуллин һәм башка һәвәскәр артистлар җаннары-тәннәре белән театрга бирелеп эшләгәннәр. Олы Әтнәнең үзендә дә, авылларда да, спектакль уйналганнан соң, һәвәскәр артистлар таралырга ашыкмыйлар – яшьләр белән аралашалар, уеннар уйнаталар.

1932 елның көзендә Әтнәгә Казаннан академия театры килә. Танылган сәхнә осталары «Булат бабай семьясы» спектаклен куялар. Академия артистлары һәвәскәр артистларның эшләре белән якыннан танышалар һәм һәр яклап ярдәм итәләр. Бигрәк тә 1919 елдан алып Оренбург, Уфа, Әндиҗан һәм Казан театрларында эшләгән профессиональ актер, Татарстанның атказанган артисты Мәҗит Илдарның булышлыгы зур була. Ул Әтнәдә шактый тора һәм Әтнә үзешчән театр коллективын «Колхоз-совхоз күчмә театры» итеп оештыруда бик зур көч куя, матди ярдәм оештыра. Мәҗит Илдарның тырышлыгы белән шул ук «Булат бабай семьясы»н куеп, Әтнә театры профессиональ коллективка әйләнә. Театр район мәгариф бүлеге карамагына тапшырыла, хозрасчетка күчә. Статус белән бергә, сәхнә культурасы да үсә: коллектив суфлерсыз уйный башлый. Кайчандыр Кече Әтнә балта осталары «тәмуг» дип атаган суфлер будкасы сүтелә. Күчмә театрның режиссеры итеп – 1920-1921 нче еллардан клуб мөдире булып эшләгән Җәләл Камалов, администраторы итеп – Бәрәскә авылы кешесе Г.Хөсәенов, гармунчы итеп Шакир Галимҗанов билгеләнә. *«Район мәгариф бүлеге тарафыннан районның авылларына аерым кешеләр җибәрелеп, авылларда спектакль уйнауда яхшырак башкаручыларны күчмә театрга бару өчен өндәделәр»,* – дип искә төшерә Хәйдәр Гатауллин. Утыздан артык кеше сынауда булып, шулардан тугызы – Галимә Сибгатуллина, Котдус Баязитов, Хәким Шакиров, Хәйдәр Гатауллин, Әминә Баязитова, Хәдичә Сабирова, Гәрәй Хәбибуллин,

Ольга Котельникова, Габделхәй Сабиров әлеге сынауны үтәләр. Зур сәхнә әсәрләре куйганда спектакльләрдә Рәшидә Гарипова, Шакир Галимҗанов, Әхми Хисамов, Гәрәй Хәбибуллин, Фатыйх Басыйров, Вәли Әхмәтов, Җәүһәр Шакирова, Фатыйма Гайнуллина, Каюм Баязитов, Валентина Валидова һәм башкалар катнаша. *«Куелган спектакльләр суфлерсыз башкарылдылар»,* – дип искә ала артист Хәйдәр Гатауллин (театр дәүләтнеке булудан туктагач, ул озак еллар Күәм авылында клуб мөдире булып эшләгән).

Театрның беренче рәссамының, кызганыч, исеме генә билгеле: Фазыл атлы кеше булган ул. Тик Әтнәдә борынгы заманнардан кешене, фамилиясеннән бигрәк, кушаматыннан танырга күнеккән халык. Сәхнә бизәү остасы, рәссам Фазылның да «Тукый»лар нәселеннән икәне мәгълүм. Реквизит әзерләүдә, декорацияләр ясауда Фазылга балта остасы Мөхәммәтҗан Әскәров ярдәм иткән.

Күчмә театр 1936 елга кадәр эшли. Әтнә, Арча, Балтач, Чүриле, Кенәр, Дөбьяз һәм Саба районнары авылларында «Яшь йөрәкләр», «Зәңгәр шәл», «Чаткылар», «Банкрот», «Ил күчкәндә», «Ике көч» һәм башка күп кенә пьесаларны бик яхшы хәзерлек белән куя. Язгы чәчү, урып-җыю чорларында артистлар авылларда бер пәрдәлек пьеса һәм концерт белән йөриләр.

Шулай ук Әхми Хисамов, Габделхәй һәм Гадел Сафиуллиннар, Фатыйх Басыйров, Әхмәдулла һәм Габделхәй Гайнуллиннар, Габделхәй Хәкимов, Разия Хәбибуллина, Мөбарәк Хәсәнов, Әминә Хәкимова, Евгений Котельников, Марзия Лебедева, Гөлсем Хәйруллина, Самат Әмиров, Мансур Әхмәтҗанов, Зәкия Галимҗанова, Маһинур Хәнәфиева, Бари Зарипов, Мөнәвәрә Мифтахова, Габдулла Тимершин, Валентина Валидова, … Җәгъфәров, Нәсимә Мөхәммәтгалиева, Мөнәвәрә Төхфәтуллина, Гариф Төхфәтуллин, Назира Галимҗанова, Әбрар Шәмсиев, Сәлах Хисамов, Гомәр Әхмәтов, Әминә Шамакова катнашында 1932-1940 нчы елларда «Галиябану», «Чаткылар», «Ташкыннар», «Биш бүләк», «Зәңгәр шәл», «Ике көч», «Акбашкай вакыйгалары», «Ил күчкәндә», «Урман кызы», «Сүнгән йолдызлар», Ак калфак», «Асылъяр», «Җәмилә», «Гөлзадә» һәм башка шундый зур пьесалар уңышлы гына куела. *«Спектакльләр бик уңышлы бара иде. Мәсәлән, «Биш бүләк» белән «Гөлзадә»не тамашачыларның сораулары буенча өч көн рәттән куярга туры килде»,* – дип искә алалар ул елларны сәхнә ветераннары.

Шушы чорда коллектив ике тапкыр: 1936 елда Кави Нәҗминең «Булат бабай семьясы» һәм 1939 елда Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» драмасы белән үзешчән коллективларның районара смотрында Арчада катнаша. Әтнәлеләр бу смотрларда оста уйнаулары белән башка район драма коллективларыннан күпкә өстен булуларын күрсәтәләр, беренче урынны алалар, грамоталар һәм кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнәләр.

Шунысы кызык, 1938 елда район клубы каршындагы үзешчән театр коллективы йогынтысында Әтнәдә икенче драмколлектив оештырыла. Киров исемендәге колхоз башлангыч комсомол оешмасы комитеты башлангычы белән колхозчы яшьләрдән драма коллективы төзелә. Ул елларда Киров исемендәге колхоз комсомол комитеты секретаре булган Асия Әхмәтҗанова истәлекләреннән: *«Коллектив 23 кешедән тора иде. Район клубы каршындагы драмколлективта хезмәткәрләр генә булса, безнең драмтүгәрәктә колхозчылар гына иде». Колхозчы яшьләр: «Без район клубы артистлары кадәр уйный алмыйбызмыни?!»* – дип, бу эшкә бик кыю тотыналар, хәтта район клубы коллек-

тивын ярышка да чакыралар. Кемнең җиңүче булуы турында мәгълүматлар юк, әмма «өлкән иптәшләр» Котдус Баязитов, Галимә Сибгатуллина һәм Разия Хәбибуллинаның колхозчы яшьләрне сәхнә тәртипләренә чын күңелдән өйрәтүләре, һәр яклап булышулары мәгълүм.

Яшьләр башта кечкенәрәк пьесаларны куялар, соңга таба, осталыклары үскәч, «Кызыл йолдыз», «Гөлзадә», «Акбашкай», «Ут» кебек зур әсәрләрне район клубында һәм колхоз клубында уңышлы гына уйныйлар. Халык спектакльләргә ратып йөри. Бу спектакльләрдә Әхми Фазлыйәхмәтов, Зариф Вәлиуллин, Мөхәммәтхан Сабиров, Хәлиулла Хәйруллин (дүртесе дә Бөек Ватан сугышы кырларында башларын салалар), Гариф Төхфәтуллин, Рәхим Сабиров, Мөнәвәрә Галимҗанова, Маһинур Хәнәфиева, Асия Әхмәтҗанова, Нәсимә Гарипова һәм башкалар катнашалар.

Шулай итеп, Әтнәдә 1938-1940 нчы елларда ике драмколлектив эшли. Сугыш булмаса, әтнәлеләр нинди уңышларга ирешкән булырлар иде дә бит…

Сугыш башлангач, күп кенә һәвәскәр артистлар Ватан азатлыгы өчен көрәшчеләр сафына баса. Үзешчән артистлар Котдус Баязитов, Җәлән Камалов, Габделхәй Хәкимов, Әхмәдулла Гайнуллин, Бари Зарипов һәм М.Хөсәенов яу кырында ятып калалар. Әмма алар киткәч тә сәхнә буш калмый. Театрга җитәкчелек итү Галимә Сибгатуллина өстенә төшә. *«Ничек итсәк иттек, әмма коллективны таркатмадык. Ирләр югында хатын-кызларны ирләр итеп киендереп сәхнәгә чыккан вакытлар күп булды»,* – дип искә ала Галимә апа. Баштарак зур күләмле әсәсрләргә тотынырга көч булмаса да, артистлар кыска жанрны корал итеп алалар. Дошманга нәфрәт уяталар, сугыш авырлыгыннан боега

Виуль Мөхәммәтшин

төшкән күңелләрне җылыталар. Авыр эштән соң үзләренең ял вакытларын кешеләребезнең күңелен күтәрүгә корбан иткән алар. Мең рәхмәт әлеге шәхесләргә!

Галимә Сибгатуллина, Разия Хәбибуллина, Мөнәвәрә Төхфәтуллина, Асия Әхмәтҗанова, Зәкия Галимҗанова, Әминә Шамакова, Әхәт Маликов, Мансур Борһанов, Булат Бәширов, Әнәс Хәбибуллин, Зәйнәп Хәкимова, 1943 елдан Әтнә клубы мөдире булган Мөнирә Хәйруллина, клубның сәнгать җитәкчесе Зәйнәп Әхмәрова, һәм, фронтка киткәнче, Маһинур Хәнәфиева, Вәли Хәкимов, Мөбарәк Сабиров, Виуль Мөхәммәтшиннарның актив катнашында, «Беренче театр», «Бүләк өчен», «Яшьләр алдатмыйлар», «Җәмилә», «Таң», «Киез итек вакыйгасы», «Кайту», «Йолдызкай», «Люба Кузнецова» һәм башка шундый сәхнә әсәрләрен куялар. Яшьләрне сәхнә осталыгына өйрәтүгә өлкәнрәк артист Фәхретдин Хөснетдинов зур өлеш кертә.

Коллектив бу авыр елларда да авылларга чыга. Гомумән, сугыш чорында сәнгать тормышын нининдидер бер кара полоса итеп күз алдына китерү дөрес

түгел, ул чорда да үзешчән сәнгать яшәгән, хәтта смотрлар да уздырылган. Нигездә, театр артистларыннан торган Әтнә үзешчәннәре коллективы, Разия Хәбибуллина җитәкчелегендә, 1945 елның мартында республика смотрында «Салкын чишмә» әдәбисәнгатьле монтаж, заманча әйтсәк, театральләштерелгән тамаша күрсәтеп, беренче урын ала һәм грамота белән бүләкләнә.

Сугыштан соң совет кешеләренең көндәлек тормышын чагылдырган күп кенә пьесалар куела. Мәсәлән, 1945-1950 нче елларда «Дуслык», «Изге әманәт», «Күңел дәфтәре», «Кайту», «Наилә», «Чын мәхәббәт», «Ялкын», «Бүләк», «Төнге сигнал», «Паркта», «Тормыш җыры», «Галиябану», «Югалган кыз», «Ак калфак», «Кунак егет» һәм башка әсәрләр сәхнәгә менә.

1946 – беренче тыныч елда гына да К.Шамилнең «Җәмилә»се, М.Әмирнең «Тун ачуы», Т.Гыйззәтнең «Чаткылар»ы, Ф.Хөснинең «Урманда», Ш.Мәҗитнең «Сөеклеләр»е зур уңыш белән сәхнәләштерелә. Ул заманда мәдәният хезмәткәрләренең, үзешчән артистларының ничек эшләгәннәрен архивта сакланган бик кызыклы документ – Олы Әтнә район мәдәният йортының 1946 елдагы эшчәнлеге буенча отчет күрсәтә. Ел дәвамында 192 киносеансны 17 600 тамашачы караган, читтән чакырылган профессиональ артистлар тарафыннан 14 спектакль һәм концерт куелып, аларда 4200 тамашачы булган, үзешчәннәр көче белән хәзерләнгән 22 спектакль һәм концертны 6600 кеше тамаша кылган. Шуның өстенә, 38 лекция, 27 бию һәм уеннар кичәсе, 24 балалар өчен чара. Кино карарга уртача туксанышар кеше йөрсә, спектакль-концертларда өчәр йөз тамашачы булган. 250 кеше сыйдырышлы залда бит бу! Өстәмә урындыклар алып килеп, бер урынга икешәрләп утырып караганнар ул вакытта спектакльләрне! «Приписка», – дияргә һич ашыкмагыз, клубның гөрләп эшләгәнен һәм югарыдагы саннар хак булуын еллык финанс күрсәткечләре дәлилли. Ел дәвамында 38 086 сум 37 тиен акча кергән мәдәният йортына. Шуның төгәл 20 мең сумы – бюджеттан, ә калган 18 086 сум 37 тиене – түләүле чаралардан кергән акча, тиешле салымнарын, авторлык гонорарларын күчергәннән соң «кулда» калганы. Сүз уңаеннан, авторлык хокуклары үтәлешен кырыс күзәткәннәр Сталин заманында. Тулы җыемнан 5 процент авторга түләнгән. Аз сумма түгел! Мәсәлән, шул 1946 елның октябрь-декабрь айларында уйналган «Җәмилә», «Тун ачуы» һәм «Чаткылар» спектакльләреннән авторлар – Касыйм Шамилгә – 111 сум 10 тиен, Мирсәй Әмиргә – 42 сум 5 тиен, Таҗи Гыйззәткә 76 сум 85 тиен күчерелгән.

Инде хәзер күз алдына китерегез: чыгымнарның яртысын диярлек (төгәллек таләп итсәгез – 47,5 процентын) мәдәният хезмәткәрләре үзләре эшләп тапкан! Кайсы дәүләт театры – мәдәният сарайларын, клубларны әйткән дә юк инде – мактана ала бүген мондый финанс күрсәткечләре белән?! Әле шуны да истән чыгармаска кирәк: ул чорда колхозчы «таякка» гына эшләгән, акчалата хезмәт хакы алмаган, колхозчыга пенсияләр дә юк әле. Акча белән хезмәткәрләргә генә түләгәннәр, ә колхозчы шәхси хуҗалыгында җитештергәнне сатып кына акча күргән, әле ул акчадан салымнар (налоглар) түләргә, киенергә, балаларны үстерергә кирәк (урта мәктәп тә түләүле). Авыл кешесе хәтта шуннан соң да спектакль, концерт билетына хәләл акчасын кызганмаган! А-у-у, кайда сез зиннәтле машинага утырып та, затлы кием киеп тә, театрга, мәдәният йортына барырга иренгән егерме беренче гасыр кешеләре?!.

...1947 елда республика үзешчән сәнгать смотры уздырыла. Әтнәлеләр,

«Кайнеш» (Г.Камал) спектакленнән бер күренеш. 1925-1927 нче еллар

театр сәнгатенә тугры калып, бу юлы да «Туган ил» дип исемләнгән «сәнгатьле монтаж» – театральләштерелгән тамаша әзерләп, март аенда Казанда чыгыш ясыйлар һәм Татарстанда беренче урын яулап, ТАССР Министрлар Советы карары нигезендә, рояль белән бүләкләнәләр.

1949 елда авыл драма коллективларының республика смотрында коллектив районда беренче урынны ала, район Советы башкарма комитеты тарафыннан гармун белән бүләкләнә. Шул ук елны Арчада республика смотрының районара ярышы уздырыла. Әтнә үзешчән драма коллективы анда Гамир Насрыйның «Күңел дәфтәре» исемле комедиясе буенча Гариф Төхфәтуллин тарафыннан куелган спектакль белән катнаша һәм җиңү яулый, Почет грамотасы һәм бер мең сум акча белән бүләкләнә. Һәвәскәр артистлар Зәкия Хәсәновага – 200 сум, Галимә Сибгатуллина һәм Мансур Шакировка – 400әр сум акчалата премия, Виуль Мөхәммәтшин белән Әхәт Маликовка Мактау грамоталары бирелә. Смотрны бәяләргә Мәскәүнең үзеннән (илебез әле сугыш яраларыннан тулысынча арынып та өлгермәгән бу чорда дәүләт үзешчән театр сәнгатенә нинди әһәмият биргәнен генә күз алдыгызга китерегез!), РСФСР Мәдәният министрлыгыннан килгән вәкил, Гыйльмениса ролен башкарган Галимә Сибгатуллинаның уенына сокланып: «Чын, йомшак күңелле ана», – дип бәяли.

Гомәр ага Мәрдәновның архивында 1958 елда тупланган «Үзешчән театр тарихы турындагы материаллар белән» дип исемләнгән папкада рус телендә бастырылган билгесез бер журналның 11 нче бите саклана. Биткә кулдан «4/VIII. 1949 г.» датасы куелган. Язмада сүз Әтнә район мәдәният йорты эшчәнлеге турында бара. Анда болай дип язылган (тәрҗемәсез генә бирәбез):

«Художественная самодеятельность Дома культуры пользуется у населения большой популярностью и любовью.

Коллектив художественной самодеятельности занял одно из первых мест на республиканском и Всероссийском смотрах прошлого года. Активными

участниками являются не только молодежь, но и интеллигенция, служащие, домохозяйки. В Доме культуры в один из вечеров ставилась пьеса «Кайту» («Возвращение») Р.Ишмуратова. Активная участница драмкружка, домохозяйка т.Сибгатуллина играла в ней роль матери. После постановки спектакля состоялось обсуждение. Исполнение роли матери т.Сибгатуллиной получило высокую оценку. Поделившись опытом работы над ролью, т.Сибгатуллина сказала: «Мне уже 45 лет, но я принимаю активное участие в художественной самодеятельности. Первый мой выход на сцену был еще в 1928 году. Тогда я исполняла роль Галиябану в пьесе М.Файзи. С 1940 года – времени создания Дома культуры – я – постоянный член драмкружка. Это мое любимое занятие. С 1947 года я работаю в совете Дома культуры, помогаю руководителю кружка в подборе репертуара, в оформлении сцены, в воспитании молодых кружковцев».

...Сугыштан соңгы елларда коллективка район комсомол комитетының ярдәме зур була. Райкомол хезмәткәрләреннән Сөембикә Хөсәенова, Сергей Котельников, Кәүсәрия Миңлекаева һәм Раушания Мөхәммәтҗановалар башлап йөриләр. Шулай ук сугыштан соңгы елларда коллективның җитәкчесе Вәли Әхмәтов, үзешчән артистлар Виуль Мөхәммәтшин, Гариф Төхфәтуллин, Әхәт Маликов спектакльләр кую эшендә аеруча актив катнашалар.

«Заманы шундый булган», – дияргә мөмкин, әмма ул еллардагы коллективтагы дисциплина турында берничә сүз әйтми узу ярамас. *«Бүген кич сәгать 8дә РДК кызыл почмагында драмкружок җыелышы була. Түбәндәге иптәшләрнең килүләре сорала...»; «Бүген, 7 ноябрь көнне, көндез сәгать 2дә генеральный репетиция була. Түбәндә күрсәтелгән иптәшләрнең килүләрен сорыйбыз...»* Һәм исемлек – исем-фамилия, эш урыны, имзасы. Иң аста – район культура йорты директоры һәм художество эшләре җитәкчесе имзалары. «Бара алмыйм, кич эшлибез», – дип, вак энҗедәй почеркы белән язып куйган Бөек Ватан сугышы фронтларын кичкән Маһинур Хәнәфиева. «Мин член түгел бит», – дип кулын куйган Асия Әхмәтҗанова – 30 нчы еллар азагында Киров исемендәге колхоз яшьләреннән аерым драма коллективы төзеп, колхоз-совхоз күчмә театрында уйнаган профессионалларны ярышка чакырган, сугыш елларында Галимә Сибгатуллина белән иңне-иңгә куеп Әтнә театрын үргә тарткан Асия бу! Коллективның үсешенә шулкадәр өлеш кerткән шәхес тә «мин член түгел бит» дип язарлык булгач, күрәсең, «Әтнә драма түгәрәге әгъзасы» дигән исем бик дәрәҗәле һәм кадерле булган ул заманда, документлар театр архивында 1949 елдан сакланган. Хәзерге яшьләр: «Бюрократия, кәгазь боткасы!» – дияргә мөмкин. Ә төптәнрәк уйласаң, бу бит һәвәскәр сәнгатькә, төп эштән соң башкарган, яраткан булса да, авыр сәхнә хезмәтенә профессиональ дәрәҗәдә җаваплы караш билгесе. Кешене сәхнәгә мәҗбүри менгезергә була, тик берәүдән дә мәҗбүри рәвештә артист ясап булмый. Театр күрсәтмәләргә буйсынмый, театр – иркле иҗат җимеше. Дәвалап булмый торган сәхнә «чире» йокмаган кешене үлсәң дә спектакль уйната алмыйсың, ә инде театр «җене» кагылганны сәхнәдән кыйнап кусаң да төшереп булмый. Бернинди «кәгазь боткасы» да, имза куйдыру да түгел – бары тик һәвәскәр артистларның сәнгатькә эчкерсез мәхәббәтләре генә. Әйтик, бер 1952 елда гына да ун пьесаны сәхнәләштереп, Олы Әтнәдә һәм авылларда һәр атнаны илле өч спектакль куела. ■

ТАТАР ҖЫРЧЫЛАРЫ. КАДЕРЛЕ МИЗГЕЛЛӘР

Татарстанның халык артисты Рәсим Низамов – якташым. Туган авылларыбыз арасы, күп булса, 10 чакрымдыр. 90 нчы еллар башында бер концерт төркемендә дә бергә эшләдек – Рәсим анда җырчы да, гармунчы да иде. Бик күп юллар йөрдек ул чакта. Милләттәшләребезне сөендерәбез, дип, Төньяк боз океаны янындагы калага җитәргә дә бераз гына калган иде. Юлны беләсез, кешене иң шәп сыный торган җир – шул. Ул чакта әле студент булган Рәсимне дә сынадык: тәрбияле, олылардан узып сүз сөйләми – башта тыңлап тора, йөгең авыр булса, күтәрешә, табынга утыргач та, ризыкка олылардан узып үрелми.

Аны кеше буларак ачкан бер вакыйга турында да сөйлим әле. Бервакыт, Себердә гастроль тәмамланып, төркем җитәкчесе эшләгән өчен акчаларны бүлеп өләшкәч, Рәсим аны, сөйләшәсе иде, дип, читкәрәк чакырды. Акчаны азсынган дип уйладык. Алай булып чыкмады. «Минем монда акча килешенгәннән күбрәк. Ялгыш санадыгызмы, белеп санадыгызмы?» – ди икән Рәсим. «Син җырладың да, баянда да уйнадың, шуңа күбрәк түләдем», – дигән төркем башлыгы. «Юк, без бит алай сөйләшмәдек», – дип, артык дип санаган акчаны кире кайтарган егетебез.

«Гармунга тартылу, бәлки, әни ягыннан килгәндер, ул якта гармунчылар бар. Миңа 4 яшьләр тирәсе иде бугай, чормада яткан иске гармунны алып төштем дә, көй чыгарам дип, шуны шыңгырдата башладым. Ул шыңгырдаулар бераз көйгә охшый башлагач, гел яңа гармун сорадым инде. Алып кайттылар. Мәктәпкә кергәч тә, бәйрәмнәр булганда, шул хромканы күтәреп бара, концертларда уйный идем. Тәнәфес вакытларында күмәкләп бию оештырган чаклар да була иде. Әле дә исән әле ул гармун, уйный».

«Казан педагогика институтына укырга җырчы булам дип түгел, укытучы булам дип килдем. Ләкин өлкәннәрнең гел әйтә торган «артист булыр инде бу» дигән сүзләре бар иде, шул фәрештәләрнең «амин» дигән сәгатенә туры килде. Җырчы буларак, шагыйрьләр белән еш очрашам. Бу фотода мин шагыйрь Ләбиб Лерон белән».

«Татар җыр сәхнәсендә җырчылар күп. Бөекләр бар, бик популяр, танылган җырчылар бар, уртакуллар, сәхнәгә вакытлыча килгәннәр дә аз түгел. Татар җырчыларына барлык күзәнәкләргә үтеп җырларга, сәхнәдә үзеңне дөрес итеп тотарга өйрәнер өчен эталон – халкыбызның бөек җырчысы Илһам ага Шакиров ул. Җырчылар өчен өлге булган өлкән коллегаларыма мин бик рәхмәтле. Алардан мин күп нәрсәгә өйрәнә алдым, әле һаман да өйрәнәм».

«Фәнис абый Яруллин сүзләренә җырларым бар минем, аның иҗат, юбилей кичәләрендә дә катнашканым булды. Ә бу фото шагыйрьнең вафатына кадәр ярты еллап вакыт калгач, аның өендә төшерелгән. Бик хөрмәт иткән шәхесем иде. Аның белән аралашып, бергә иҗат итеп калуым белән горурланам».

Рәсим инде күптән эстрада сәхнәсендә нык басып торган җырчы булып формалашты, үз төркемен туплады, мактаулы исемнәргә лаек булды. Аның тавыш төсмерләрен, октава мөмкинлекләрен, репертуарының байлыгын һәм шәплеген тасвирлап иҗат портретын да яза алыр идем кебек. Бер язармын да. Яхшы кешенең портретын язу авыр түгел ул.

Журналга ***Зимфира Гыйльметдинова*** *әзерләде.* ■

Җуелмас хәзинә

«Галиябану» җыры

«Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр».

Габдулла Тукай

Галиябану

(Татар халык җыры)

Тәртип радиосы

Тәрәзәдән карыйсың ла,
Карап кемне таныйсың?
Карап күзең талдырганчы,
Галиябану, сылуым иркәм,
Ник чакырып алмыйсың?

Тәрәзәңне ачып куеп,
Кемгә күлмәк кистең син?
Кара кашым, карлыгачым,
Галиябану, сылуым иркәм,
Кем бәхетенә үстең син?

Тәрәзә төбем каты бал,
Ашыйсың килсә, ватып ал;
Сөюләрең чыннан булса,
Галиябану, сылуым иркәм,
Тәрәзәдән тартып ал.

Халык иҗатының матур үрнәкләрен туплау һәм җыю буенча Г.Тукай традициясен дәвам иттерүчеләрнең иң олысы – драматург Мирхәйдәр Фәйзи. Ул гади халыкның, аерым алганда, авыл халкының тормышын тирәнтен өйрәнә, халык авыз иҗатын туплый, җырларны анализлый һәм аларны әсәрләренә кертә.

М.Фәйзи, халык көйләренә нигезләнеп, музыкаль сәхнә әсәрләре язу традициясен башлап җибәрә: «Галиябану», «Асылъяр», «Ак калфак» – әнә шундыйлардан.

Сәхнә шедевры булган «Галиябану» музыкаль драмасы 1916 елда языла һәм автор бу әсәре белән татар әдәбиятында музыкаль драмага нигез сала.

1916 елның җәендә драматург Орск өязенең Дүрткүл авылында «Сәгадәтбану» исемле яңа җыр ишетә. Бу җыр аның күңеленә бик хуш килә һәм ул: «Мин бу җыр турында бер әсәр язачакмын», – ди. Шул ук җәйдә хәзерге Балтач районының Шода авылына кайта һәм авыл яшьләре белән аралаша. Аларның чишмә буйларында-

гы уеннарын, җыр-биюләрен күреп соклана. «Сәгадәтбану» көенә сәхнә әсәре язу фикере тагын да ныгый һәм, озакламый, драматург бу әсәрен яза.

Драма 1917 елда Оренбургта куелырга тиеш була. Сәхнәгә куючы режиссер Вәли Мортазин-Иманский әсәрнең исемен «Галиябану» дип үзгәртергә киңәш итә. Чөнки Сәгадәт бәхет дигән мәгънәне аңлата. Ә драма героинясының мәхәббәте фаҗига белән тәмамлана. Сөйгәнен мәңгелеккә югалткан кыз бәхетле була аламы? Ни өчен Галиябану? Гали – бөек мәгънәсенә ия. Чыннан да, Галиябану үзенең керсез, саф мәхәббәте, сөйгәненә мәңгегә тугры калуы белән мәхәббәтнең бөеклеген раслый.

Галиябану (Марзия Миңлебаева) белән Хәлил (Гыйльметдин Газизов)

Драмада «Галиябану» көен әсәрнең төп образы Галиябану үзе чыгарган итеп күрсәтелә: *«Ай, шушы көй өзә бит минем үзәкне. Беркөн кайдан, күкрәгемнең кайсы җиреннән алып кына җырладым икән соң мин бу көйне? Инде менә үз исемемне кушып җырлый башладылар. Мин аны үземнең сөйгәнем өчен генә җырлаган идем; ул каршымда булган вакытта гына җырлый алган идем бит»,* – ди ул. Әмма көйнең драмадан алданрак чыгуын, аның беренче исеме «Сәгадәтбану» булып, М.Фәйзи әсәре буенча киң популярлык казануын онытмаска кирәк.

(Сәхифә «Тәртип» радиосында яңгыраган «Саф вә раушан көзге» тапшыруы материаллары нигезендә әзерләнде. Тапшыруның авторы һәм алып баручысы – Гөлфия Мөхәммәтгәрәева.) ■

Безнең мирас №3 март 2021

Көлке куа килә...



Марат Кәримов

Марат Кәримов (1930)

Туган тел

(Пародия)

...Әйтергә тиеш мин бу урында
Солдат турында.
...Әйтәсем килә бу урында...
Башымда –
Җавап көткән уч тулы сорау.
...Менә мин –
Яшәдем,
Ягъни үземчә мин көн күрдем...
«Европа уртасыннан репортаж»
Шамил Мәхмүтов

Әйтергә тиеш мин бу урында
Үзем турында.
Әйтик,
Менә мин –
Язам,
Ягъни шөгыльләнәм иң яхшы эш
белән.
Рәсми даирәләр таныш
Минем иң алга барышлы һәм
Шуңа бәрабәр иң яңгыравыклы
Тавыш белән.
Башымда –
Бер уч сорау,
Ягъни үз-үземә шик.
Нигә?
Ни өчен?
Ник?
Язуым нинди телдә?
Җавабым:
Бүгенге көндә,
Ягъни башкортча да, татарча да.
Һәрвакыт, һәр җирдә
Туган телем –
Тик
Подстрочник!

Туфан Миңнуллин (1935-2012)

Рабит Батуллага

Батулланың беләм төрле чагын:
(Бергә булдык囗 эштә, табында.)
Бәйдән ычкынганын күргәнем бар,
Мулла мәчеседәй чагын да.

Язганнарын тәнкыйтьләп тә була
Һәм дә була: «Шәп!»– дип мактарга.
Бәхәссез бер егетлеге аның –
Ике татар бирде татарга.


Батулла.
Л.Лерон шаржы, 1994

Афзал Шамов (1901-1990)

Бабай

Шагыйрь Мәҗит Гафури илле дүрт яшендә вафат булды. Карт түгел иде әле. Иҗатының ташып торган чагы. Шуңа карамастан, татар матбугаты инде аны күптән карт шагыйрь дип атап йөртә иде. Кем белә, бәлки, әле картлыгы өчен түгел, ә ул заманда иң өлкән язучыларның берсе булганга олылап, ихтирам итеп шулай атаганнардыр. Ничек кенә булмасын, Мәҗит ага үзен карт яисә бабай дип әйттерергә теләмәгән, күрәсең.

Берзаман шулай, егерменче елның азагында булса кирәк, Мәҗит ага шагыйрь Сәйфи Кудаш белән бергә Уфаның текә ярыннан Агыйделгә сокланып карап тора икән. Көн матур, кояшлы, җылы. Астан, пристань ягыннан, кешеләр агылып менә: атлылар, җәяүлеләр... Шунда шактый авыр капчык күтәргән бер егет, Мәҗит ага янына җиткәч, аңардан:

– Бабай, Аксаков урамына ничек барырга икән? – дип сорый.

Мәҗит аганың йөзе кинәт караңгыланып китә. Берничә секунд чамасы ни дип җавап бирергә дә белмичә тора. Аннары кинәт, кулы белән кире якка күрсәтеп:

– Аксаков урамымы?.. Аста ул, түбәндә, энекәш, – ди. – Төшкәч, сул якта.

Егет, авыр капчыгын күтәреп, түбәнгә, Агыйделгә таба китә. Сәйфи Кудаш, бик гаҗәпләнеп, М.Гафурига карый:

– Нишләвегез бу, Мәҗит ага? Аксаков урамы анда түгел ич.

– Булмаса соң, нигә ул миңа бабай дип эндәшә? – ди шагыйрь. – Кирәкмәгәнгә картайтмасын кешене!

Күпмедер вакыт уза – секундлармы, минутлармы, Мәҗит ага кинәт Сәйфи Кудашны ашыктыра:

– Бар әле, йөгер әле шул егет артыннан. Аксаков урамының кайда икәнен әйт! Капчыгын да күтәрешеп мен!

Сәйфи Кудаш теге егет артыннан йөгереп төшеп китә.



Зәет Мәҗитов (1927-2000)

Тилгән

Тавышын тыңлап, уйлыйсың:
 – И мескен, мескен...
Чебешең алгач, әйтәсең:
 – Башлары бетсен!.. ■

Сәхифәне ***Ләбиб Лерон*** *азерләде.*

ФЕВРАЛЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында



● Ошбу елның башында Татарстан Республикасының халык, Россиянең атказанган артисты Айдар Садретдин улы Хафизовка нисбәтле «Эзләп тапкан бәхет» дигән китап (автор-төзүче – Ю.Сафиуллин, «Ак Бүре» нәшрияты) дөнья күрде.

● 1 февральдә «ТАТМЕДИА»да Татарстанның халык шагыйре Ркаил Зәйдулланың «Сунар» китабын тәкъдим итү чарасы булды.



● Февраль башында Татарстанның халык артисты Габделфәрт Шәрәфиев турында «Сәхнә өчен туган» дигән истәлекләр китабы (автор – Г.Шәрәфиевнең кызы Гүзәл Габдуллина) басылып чыкты.

● 15 февральдә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевкә «Хәрби туганлык» Бөтенроссия оешмасының мактаулы әгъзасы» дигән исем бирелүен раслаган күкрәк билгесе һәм таныклык тапшырды.

● 17 февральдә фольклорчы галим һәм язучы, РФнең атказанган мәдәният хезмәткәре (1983), Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1989), 2004 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Хуҗиәхмәт Шаһиәхмәт улы Мәхмүтов вафат булды.

● 18 февральдә Казандагы 116 нчы лицейда (директоры – Гөлсирень Дүсәмбәк кызы Мөхәммәтҗанова) балалар язучысы, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон белән очрашу булып узды.

● Февральдә табиб һәм язучы Нәкыйп Каштанның үз туган авылы тарихын өйрәнеп язган «Кыр Бикшегем» дигән китабы басылып чыкты. Җыентыкта шулай ук Кыр Бикшеге тумасы, татар әдәбияты классигы Фәтхи Бурнашка кагылышлы язмаларга да киң урын бирелгән.

● 19 февральдә язучы һәм «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон Казандагы 30 нчы мәктәп (директоры – Рөстәм Флүс улы Бәхтиев) укучылары белән очрашты.

● 20 февральдә Казан кооператив институтында күренекле драматург, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллинны (1935-2012) искә алу кичәсе булды. Әлеге институтның Татар мәдәнияте үзәге (җитәкчесе – Ф.Абдуллина), Бөтенроссия «Татар гаиләсе» фонды (директоры – М.Гайфуллина) һәм Әлки районы «Якташлык» җәмгыяте (җитәкчесе – Казан кооператив институты ректоры А.Нәбиева) белән берлектә уздырылган ошбу күркәм чарада, Т.Миңнуллинның кызы Ә.Миңнуллина-Юнысова, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Д.Шакиров, республиканың әдәбият-сәнгать әһелләре һәм журналистлар белән бергә, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Л.Лерон да катнашты һәм чыгыш ясады.

● 22 февральдә Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә «Татар сүзе» бәйгесенең гала-концерты булды.

● Февральдә күренекле шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановка багышланган «Татлы сагыш, рәхәт сагыну...» дигән китап (төзүчеләре – Сания Фәйзрахманова һәм Марат Фәйзрахманов, «Рухият» нәшрияты) дөнья күрде.



● 22 февральдә Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә узган «Татар сүзе» гала-концерты вакытында ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары Марат Әхмәтов Филармония директоры Кадим Назыйр улы Нуруллинга «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемнең таныклыгын һәм күкрәк билгесен тапшырды.

● 22 февральдә фольклорчы галим, филология фәннәре докторы (1989), Татарстанның атказанган фән эшлеклесе (1996), 1977 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Фатих Ибраһим улы Урманчеев вафат булды. ■

МИРАСВОРД

- Мылтык чакмасы
- Туку станогында буй җепне күтәрү-төшерү өчен махсус кыса
- Очкыч
- Фатих Әмирхан повесте
- Әйләнә (диал.)
- М.Мәһдиевнең «Без кырык беренче ел балалары» повесте герое
- Соры корт (диал.)
- Шар сугу уены (диал.)
- «... вә Димнә» ядкяре
- Борынгы Скандинавия халыкларында: шигъри риваять
- Ана эт
- Өчпочмаклы яулык (иск.)
- «... килде» драмасы (Шәриф Хөсәенов)
- Сугышчы (иск.)
- Ун мең кешелек гаскәр (бор.)
- Эре сырлы игәү
- Гарәп артикле
- Совет кинорежиссеры
- Әрем тәме
- Шагыйрь Зиннур Мансуровның 1988 елда чыккан китабы
- Орчыктан махсус агачка сарып, бәйләм итеп уралган җеп
- Борынгы Шәрык илләрендә күрәзәлек белән шөгыльләнүче дин башлыгы
- Грузия акчасы
- Борынгы Мисыр мифологиясендә күк Алласы
- Металл акчаның бәясен күрсәткән цифрлы ягы
- Зыя ... (татар мәгърифәтчесе, дин эшлеклесе, мөгаллим)
- Джордж Байрон поэмасы
- ... Камал (урта гасыр төрки-татар шагыйре)
- Урта, Түбән, Югары ... (Пенза өлкәсендәге татар авыллары)
- Чәч толымына кушып үрелә торган, тасмага тагылган тәңкә
- Габдулла Тукайның 1911 елда язган шигыре
- ... Нәҗми
- ... Исаев (рус шагыйре)
- Николай Гоголь повесте
- Каз ...се
- Телсез (диал.)
- Кириллица хәрефе
- Бу авыл Кайбыч районында да, Арчада да бар
- Монарх яки зур түрәләрнең хезмәтче малае
- Мөдәррис Әгъләмнең кушаматы
- Карел-фин эпосы



Раис Габдулла төзеде.

2 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: Фәиз, «Өмид», Наил, Латыйп, Зәйни, Поло, тити, Физули, дәл, аса, Идрис, куык, Мин, зурна, Чыңгыз, Даутов, үтеч, Нури, Таҗи, корык, Ван, туй, Буа.
Өстән аска: фал, Үтәй, апис, чыпта, тозак, тәҗе, «Көлсылу», чи, «Йолдызым», фин, куз, задә, «Зиндан», Зөлфәт, Ахунов, Милий, Тураб, әсир, орыну, илд, Ивик.

«Безнең мирас»

елъязмасы / март

Ташкент, иске шәһәр. 1920 нче еллар

785 ел элек (1236)

Хәзерге Казакъстан һәм Үзәк Азия җирләрендә, Хулагулар дәүләте белән янәшә Җучи Олысы барлыкка килә.

675 ел элек (1346)

Алтын Урданың Гөлстан каласына, үзара солых төзү өчен, Венеция сенаты илчеләре килә. Татар дәүләте җитештергән тауарлардан тамга (таможня) салымы алмаска килешенә.

660 ел элек (1361)

Алтын Урда дәүләте икегә аерыла – уң һәм сул канатка. Иделдән көнчыгыштагы җирләр сул канатка керсә, көнбатыштагылары исә уң канатны тәшкил итә. Уртада – Идел елгасы. Бер якта гел алышынып торган Сарай ханнары булса, аргы якта, – Сарайны кулга төшереп, үз ханын тәхеткә утыртырга омтылган гайрәтле Мамай морза...

140 ел элек (1881)

Казан университеты һәм Петербург Фәннәр академиясе басмаханәләрендә эшләп зур тәҗрибә туплаган хәреф җыючы Шаһингәрәй Биккулов Ташкентка чакырыла. Ул биредә җирле милләт вәкилләрен типография һөнәрләренә өйрәтүне җайга салып җибәрә. Милләттәшләребезнең мәгърифәт таратуы Төркестан җәмәгатьчелеге тарафыннан югары бәяләнә: Шаһингәрәй Биккуловка, 1918 елда Төркестанда беренче булып, Хезмәт Батыры исеме бирелә.

100 ел элек (1921)

Һади Такташ Ташкент каласында нәшер ителүче «Белем йорты» журналында җаваплы сәркатип булып эшли башлый. Ошбу вазыйфасыннан гайре, шагыйрь Төркестан эшче-диһкан коммунистик университетында татар теленнән сабак бирә, гаскәри отрядта җирле милләт егетләрен укырга-язарга өйрәтә. Ул Ташкенттагы татар әдәби көчләре белән шигърият кичәләре дә оештыра. Шундый кичәләрнең берсе Габдулла Тукайга багышлана һәм анда үзбәк совет әдәбиятына нигез салучы Хәмзә дә катнаша.

30 ел элек (1991)

15 мартта Татарстан язучыларының чираттан тыш съезды (корылтае) уздырыла. ■

Журналга ***Марат Закир*** *әзерләде.*

Содержание. Март 2021

Мы – татары!: Г.Тукай, Р.Фахруддин, Г.Исхаки, Ф.Амирхан, Дэрдменд, Н.Фаттах.

2021 год – Год родных языков и народного единства: Минтимер Шаймиев: «Каждый может внести свой бесценный вклад в сохранение языка».

Историческое наследие: «Татары в башкиро-мещерякских войсках». Р.Аминов; «События Первой мировой войны в Актаныше». Л.Габдрафикова; «Страшный голод». Р.Шарафиева и Л.Губайдуллин.

Татарский мир: «Мензелинский говор». О.Хисамов.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

В глубинах памяти: «В памяти, до сих пор в памяти!»

Художественное наследие: «Татарские певцы. Дорогие мгновения». З.Гильмутдинова.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Алхәбәр:

- **Г.Тукай хатының төзәтелгән нөсхәсе.**
  Себастьян Цвиклински
- **Үтәмеш: мәчетләр тарихы.**
  Нияз Исхаков, Резеда Исхакова
- **«Минем кулым түгел, Гайшә-Фатыйма кулы...»**
  Гүзәлия Хаҗиева
- **Мөслим бабай варислары.**
  Роза Хәбибуллина
- **Адәм башыниләр күрми.**
  Сәмига Сәүбанова
- **Зәйтүнәдән хәбәр бар.**
  Фатиһ Кутлу

СВИДѢТЕЛЬСТВО.

Настоящее свидѣтельство, съ приложеніемъ надлѣжащей печати, отъ Симбирскаго Городского трехклассного училища выдано крестьянину Симбирской губерніи Буин-скаго уѣзда Янтугановской волости деревни Янтугановой [illegible]

№ [illegible]

въ удостовѣреніе того, что онъ успѣшно выдержалъ испытаніе въ знаніи русскаго языка, установленное для кандидатовъ на должность сельскаго муллы.

г. Симбирскъ 7 октября 1910 года.

При семъ фотографическая карточка.

...иссіи

...оръ [signature]

Члены [signatures]

Печ. въ Симб. губ. тип.

Сембер губернасының Янтуган авылы крестьяны Мөхәммәтгариф Хөснетдин улының Сембердәге 3 класслы шәһәр училищесында рус теленнән имтихан бирүе турындагы таныклык. 1910 ел

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

15 гыйнварда Актанышта тарихчы һәм төбәкчеләрнең «Көнчыгыш Кама аръягының тарихи-мәдәни мирасы һәм бүгенгесе» төбәкара фәнни-гамәли конференциясе узды.

Салават Камалетдинов һәм Ленар Гобәйдуллин фотолары

«ИДЕЛ БИТ УЛ, КИҢ БИТ УЛ...»

Идел елгасының фотолары хаҗи ***Абдулла Дубин*** *тупланмасыннан алынды.*

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:

- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә электрон версия

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 51), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.